ЯҢӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

№ 6 (342)
ИЮНЬ 2020

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ISSN 0130-2418

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ

ӨЗДЕРЕП ГАРМУН УЙНЫЙЛАР НАЛАСА АВЫЛЫНДА...

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасарлары:
Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Алсу Дәүләтшина
Чыгарылыш мөхәррире:
Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре:
Олеся Бондаревская, Ольга Туманская, Руфия Фазылова
Веб-редактор: Алсу Дәүләтшина
Авторлар: Ольга Благодарова, Мөршидә Кыямова,
Луиза Шарова, Юрий Николаев
Фотографлар: Александр Ефремов,
Дизайн-макет: Леонид Гобәйдуллин
Вёрстка: Игорь Глушков, Леонид Гобәйдуллин
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Ләйсән Һадиева
Тышлыкта: Арча районы Наласа авылы гармунчылары – әтиле-уллы Мөнир һәм Рөстәм Сабировлар.
Лилилана Вәлитова фотосы

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1977 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
1 150 данә

Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми.

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә басылды: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ № А-1369
Басарга кул куелды: 10.06.2020
Басмадан чыкты: 17.06.2020

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева,
milyaushanb@tatmedia.com

Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе:
Алсу Троицкая, alsu_1970@list.ru
тел.: (843) 222-09-79

Коммерция директоры:
Юлия Фәсәхова, 89272483384_pr@mail.ru
тел.: (843) 222-09-76, +7-9272-483-384

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

ЯШӘ МӘҢГЕ, ЯШЬ ЙӨЗЬЯШӘР РЕСПУБЛИКАБЫЗ!

Бу номерда без республиканың 100 еллык юбилеен билгеләүне дәвам итәбез. Бик тә эшлекле режимда, чөнки куркыныч вирус китереп чыгарган чикләүләр әлегә тулысынча гамәлдән чыгарылмады. Төп бәйрәм вакыйгалары да безне әле алда көтәчәк, димәк.

Узган санда сез «Буыннар» махсус проектының беренче өлешен укыдыгыз. Бүген без бәянебезне дәвам итәбез.

Зур төзелешләр гамәлгә ашырылган булуына да карамастан, «торгынлык чоры» дип мөһер сугылган 70 нче еллар турында укырсыз. Бала чагыбыз, яшьлегез узган 80 нче елларга тукталмый кала алмыйбыз. «Давыллы» 90 нчы еллар – үзләре бер әсәр. Һәм инде, ниһаять, Татарстанга дөньякүләм спорт шөһрәтен алып килгән, төбәкне туристлар өчен билгеле иткән, җир шарында яшәүче бар халыкка таныткан 2000 нче еллар.

Болардан тыш, номерда дөнья буйлап таралучы вирус, шуларның берсе – COVID-19 турында да тәфсилле язма белән очрашырсыз. Без хәзер барыбыз да бу өлкәдә чын мәгънәсендә «экспертлар» булып җитештек, ә менә чын белгеч фикерен ишетү комачауламас, дип уйладык. Җитмәсә, ул вируслар белән турыдан-туры эш итә, димәк безнең укучыларны бимазалаган сорауларга да җавап бирә ала.

Традицион «Кече ватан патриотлары» сәхифәсендә күренекле татар галиме, искиткеч киңкырлы шәхес Әбрар Кәримуллинны искә алдык.

Арча районының Наласа авылына сәяхәт итеп кайттык, анда яшәгән гаҗәеп кызыклы, эш сөючән кешеләр күп гасырлар буена саклап килгән традицияләре белән уртаклашты. Бу авыл актив яшәеше, ташып торган көче, дәрте белән таң калдырды. Наласа кешеләрен белеп алгач, татар халкын билгеләүче мәдәни кодның сүздә генә түгел икәнлегенә янә бер инанасың. Нәкъ менә шушыннан ул код зур шәһәрләргә дә күчеп килә, күпмилләтле республиканың нигезен тәшкил итә, аңа көч-кодрәт өсти.

Безнең мәңге яшь республикабыз турында рәхәтләнеп укыгыз!

СЕЗНЕҢ КЫЗЫКСЫНУЧАН РЕДАКЦИЯГЕЗ

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фарит Рафкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйлевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
САЛАХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче:
«ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә
Ярты елга язылу бәясе: **933 сум 00 тиен**

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

Лотфулла Фәттахов, «Сабантуй», 1957 ел

WWW.PROTATARSTAN.RU

Сабантуй – татар халкының борынгыдан килгән милли бәйрәме. Ул гадәттә язгы кыр эшләре тәмамлангач үткәрелә. Авыл хезмәтчәннәре быел да чәчү эшләрен уңышлы тәмамлады. Пандемия милли бәйрәмебезне вакытында үткәрергә комачауласа да, без тәкъдим иткән «Сабан туе» картинасы сезгә хезмәт бәйрәме мизгелләрен хәтерләтер. Рәсемдә табигатебезнең матурлыгы, халыкның дулкынлануы, мәйдан ыгы-зыгысы төгәл итеп сурәтләнә. Картинаны 1957 елда атаклы рәссам Лотфулла Фәттахов яза. Картина халкыбызның матур гадәтләренең бүгенге көнгә кадәр саклануын күрсәтә. Аңа бернинди дә пандемияләр комачаулый алмас…

© «Татарстан» журналы

ЭЧТӘЛЕК

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

4. ЭМЕРДЖЕНТ ИНФЕКЦИЯЛӘР.
Табиб фикере

8. ПИКЕДАН ЧЫГУ ЫСУЛЫ.
Кече бизнес

12. КОВИД ЧОРЫНЫҢ ОФЛАЙНЫ.
Ярдәм күрсәтүчеләр тәҗрибәсе

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

18. КЕЧЕ ВАТАН ПАТРИОТЛАРЫ.
Әбрар Кәримуллин: китап һәм милләт сагында

22. КИТАП КИШТӘСЕ.
2020 елгы китапларга күзәтү

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

ТАССР 100 ЛЕТ ЕЛ

27. ТАССРНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА.
«Буыннар» проектының дәвамы

28. 1970–1980. ТОРГЫНЛЫКНЫ СИЗМӘГӘН БУЫН.
Беренче миллиард тонна нефть ничек табыла

40. 1980–1990. ДИСКО БУЫНЫ.
Мәдәнияттә нинди яңалыклар була

54. 1990–2000. ДАВЫЛЛЫ 90нчы ЕЛЛАР БУЫНЫ.
Газлаштыру, тузган тороктан котылу ничек барды

66. 2000–2010. НУЛЕНЧЕ ЕЛЛАР БУЫНЫ.
Яңа гасыр ничек башланды

78. 2010–2020. ЦИФРЛЫ БУЫН.
Татарстанда нинди халыкара вакыйгалар үтте

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

27.05

Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Республикасы Президенты, – ТР Дәүләт Советының ТАССРның 100 еллыгына багышланган тантаналы утырышында ясаган чыгышында:

– Пандемия безнең планнарга бераз төзәтмәләр кертте, әмма без әлеге истәлекле датага багышланган төп чараларны тантаналы рәвештә уткәрү мөмкинлеген табачакбыз... Без республика үсешенә саллы өлеш керткән татарстанлыларның барлык буыннарына рәхмәтле.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

04.06

Ирада Әюпова, ТР мәдәният министры, – журналистлар белән традицион очрашу вакытында:

– Татар әдәбиятының киләчәгенә килгәндә, безгә Татарстан аудиториясе белән генә чикләнмәскә иде. Кызганыч, әдәби җәмәгатьчелек ягыннан аңлау юк, миңа фикердәшләр һәм булышчылар җитми – без татар контентын Татарстан чикләреннән чыгара алмыйбыз... Бу юнәлештә эшлибез. Могҗиза булмый, ләкин эш бара. Өстенлекле төп юнәлешебез – телне саклау һәм халкыбызның әдәби мирасын дөньяга чыгару.

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

04.06

Камил хәзрәт Сәмигуллин, Татарстан мөфтие, – мәчетләр ачылу уңаеннан республика өммәтенә һәм имамнарга мөрәҗәгатендә:

– Кызганыч ки, мәчетләрдә әлегә берьюлы 100дән артык кеше җыелу тыелган, ләкин дистанцияне саклаган килеш намазны мәчет яны территориясендә укырга мөмкинлек бар. Моннан тыш, без иммунитеты какшаган һәм сәламәтлегенә зыян килүдән курыккан, шулай ук 65 яшьтән өлкән булган дин кардәшләргә мәчет һәм җомга намазларына килүдән тыелып торырга тәкъдим итәбез.

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Эмерджент инфекцияләр **НӘРСӘ** ул

Үзизоляциядә эшкуарлар **НИНДИ** ысуллар белән эшләделәр

Пандемия вакытында **КЕМНӘР** нишләде

«ЯҢА ИНФЕКЦИЯЛӘР КИЛӘЧӘКТӘ КАБАТЛАНЫП ТОРАЧАК»

COVID-19 диюгә, күпләр колакларын томалый: «Җитте инде, күпме «чәйнәргә» була», янәсе. Әйе, өч ай дәвамында туктаусыз шул хакта сөйләп торып, бу тема туйдырды гына түгел, тәмам гарык итте кебек. Шулай да «Татарстан» журналы хакыйкатьнең төбенә төшәргә тырышты: без бүген эмерджент инфекциянең нәрсә икәнен белгечләр белән бергә ачыкларбыз. Әлеге дә баягы җелегебезгә үткән коронавирус та шулар рәтенә керә...

Автор:
Руфия Фазылова

Редакциябезнең кунагы – тәҗрибәле табиб, Казан дәүләт медицина академиясенең педиатрия һәм неонатология кафедрасы доценты, Казан шәһәре 1 нче балалар хастаханәсенең педиатрия бүлеге мөдире Илдус Җәүдәт улы Лотфуллин.

– Илдус Җәүдәтович, сез, беренче чиратта, педиатр. Шулай булгач, сүзне балалардан башлыйк: 1 июньгә республика буенча ничә балага коронавирус диагнозы куелды һәм аларның хәле ничек?

– Чынлап та, пандемия Татарстанга килеп җитү белән берничә хастаханә провизор госпитальгә әйләндерелде, шуларнын берсе – Казан шәһәренең 1 нче балалар хастаханәсе. Ул Казан белән Казан тирәсендәге 19 районга хезмәт күрсәтә. Провизор госпитальләр сәламәтлек саклау системасында фильтр ролен үти: кискен инфекция симптомнары булган балалар безгә килеп, 1–2 тәүлек эчендә тулы тикшеренү уза. COVID-19 исбатланса, алар бездә кала, юк икән – башка хастаханәләргә озатыла.

Саннарга килсәк, бөтен Татарстан өчен тулаем җавап бирә алмыйм. Ә безнең хастаханәдә, 7 апрельдән башлап санасак, йөзгә якын балада COVID-19 булуы ачыкланды. Күпчелек бала әлеге чирне җиңел һәм уртача авыр формада кичерә. Авыр формалар хроник авырулары булган балалар өчен генә хас, андый очраклар бездә берничә генә булды. Мондый вазгыять дөньяда алып барылган фәнни статистикага туры килә: COVID-19 белән авырган балаларның 3–5 проценты гына аны авыр формада кичерә.

– Балаларда COVID-19 ның җиңелрәк узуы нәрсә белән бәйле?

– Моңа төгәл җавап әлегә билгеле булмаса да, дөрескә охшаган берничә теория бар. Шуларның беренчесе: вирусларның организмга эләгүе ул әле эшнең яртысы гына, ул күзәнәкнең эченә дә үтеп керергә тиеш. Кешегә йогышлы һәр вирус моның өчен үз юлын таба. COVID-19 ны китереп чыгара торган вирус (аның дөрес атамасы – SARS-CoV-2) моның өчен АСЕ дип аталган ферментка караган аксымнарны куллана. Һәм шулар аркылы күзәнәкнең эченә эләгеп, үрчи башлый. Беренчедән, балаларда АСЕ аксымнары зурларга караганда азрак. Икенчедән, аларның структурасы да башка – вирусның күзәнәк эченә эләгүенә, аның үрчүенә киртә булып тора бу. Ә менә кан басымы югары булган кешеләрдә, хроник үпкә авыруларында, киресенчә, АСЕ аксымнары вируска җиңелрәк бирелә. Шуңа бу кешеләрдә COVID-19 ның авыр формалары еш була да.

Кечкенәләр белән өлкәннәр организмын чагыштырып карасак, бүтән ягы да бар: балаларның иммунитеты зурларга караганда башкача эшли. Гади генә итеп аңлатканда болайрак: балаларның иммунитеты яңа инфекцияләр белән эшләргә күнеккән. Ул билгеле булмаган вирусларга каршы көрәшергә һәрвакыт әзер, тиз эшли. Зурларның исә иммунитетлары яңа инфекция белән очрашырга әзер түгел. «Мин кырык-илле ел эчендә бар булган инфекцияләрне күреп бетердем» дип «саный» ул. Аеруча олы яшьтәге кешеләрдә карый бу. Тагын балаларның җиңел авыруын аларга гел вакцина ясап тору белән дә бәйлиләр. Бу иммунитетны тонуста тотып тора бит.

Шуны да искәртеп узасым килә: «балалар җиңелрәк авырый», дигәндә, «уртача алганда», дип өстәп куярга кирәк. Авырлары да бар, билгеле, хәтта үлем очраклары да.

– Балалар инфекцияне йоктыручы булмый, диләр. Бу чынлап та шулаймы?

– Әйе, кечкенәләр, өлкәннәргә COVID-19 ны сирәк йоктыра. Табиблар мондый нәтиҗәгә берничә атна элек кенә килде.

Гомумән әйткәндә, әлеге инфекциянең төп чыганагы булып җиңел

Фото Илдус Лотфуллинның шәхси архивыннан

һәм симптомсыз формада авыручы кешеләр санала. Колакка бик үк ятышлы булмаган «инфекция резервуары» дигән эпидемиологик термин бар. Менә бу кешеләрне COVID-19 авыруының резервуары дип атыйлар. Үзләре каты авырмаганга яисә бөтенләй сәламәт күренгәнгә, аларга диагноз куелмый. Диагноз куелмагач, изоляция дә юк бит инде! Ковид белән катырак авырган саен, чирле кеше аны башкаларга азрак йоктыра, дигән фараз бар. Мисал өчен, Көньяк Кореянең, Германиянең пандемиягә уңышлы каршы тора алуының сәбәбен шуның белән аңлаталар. Авыру тарала башлаганда, массакүләм тестлар ясап, симптомсыз авырганнарны эзләп таба алганнар. Көньяк Кореяда һәр теләгән кеше, үзенең идентификацион мәгълүматын калдырып, урамда, машинадан чыкмыйча гына да, анализ бирә алган, диләр. Хәер, кореялыларның инфекцияләр белән көрәшүдә ачы тәҗрибәләре бар: 2015 елда Көньяк Кореяга бүгенге коронавирусның «өлкән абыйсы» – «MERS–CoV» дип аталган вирус килеп эләккәч, барлык хаталарны ясап чыкты инде алар.

– Нинди хаталар ул? Аңлатыбрак китсәгез иде…

– Бу хаталарны быел Иранда, АКШта, Италиядә, өлешчә Мәскәүдә күрдек без: изоляцияне соң кертү, анализлар алу җитмәү, пандемия башлангач, аңа «үзе бетәр әле» дип, кул селтәү… Хастаханәләрнең инфекция кластерына әйләнүе тагын бер куркыныч хата: саклану чаралары җитмәгәнгә күрә, табиблар белән шәфкать туташлары, үзләренә COVID-19 йоктырып, инфекцияне башкаларга тарата башлый. Нәтиҗәдә, COVID-19 белән авырмаган кеше, хастаханәгә ярдәм эзләп килгәч, шуннан авырып кайта. Дөньяның күп почмакларында мондый хәл күзәтелде.

– Ә безнең республикада саклану чаралары белән хәл ничек? Ялгышмасам, сез эшләгән Казан шәһәренең 1 нче балалар хастаханәсендә табибларга махсус комплектлар юк, дип ишеткән идем…

– Эшли башлаганчы, безне иң борчыган сорауларның берсе шушы иде. Аңлашыла: берәүнең дә авырыйсы, үзенең туганнарына инфекция йоктырасы килми. Монысы бер. Икенчедән, кешеләргә ярдәм итү урынына, инфекция чыганагы булып йөрү тагын да куркынычрак нәрсә.

Әйе, башта безне азрак дулкынландырып алдылар: саклану чаралары белән COVID-19 йоктырган авырулар белән эшли башлаган көннең иртәсендә генә тәэмин иттеләр. Шулай да, беренче көннән башлап, бүгенгегә чаклы саклану чаралары җитәрлек бездә. Тәүлегенә утызга якын комплект кулланабыз. Әле бер тапкыр да бер үк комплектны икешәр тапкыр кию, тулы комплектсыз киенү кебек проблемаларга юлыкмадык. Безне шулай өзлексез тәэмин итеп торучыларга без бик рәхмәтле.

– Сез COVID-19 га охшаш вируслар берничә ел элек тә булып алган иде, дидегез. Димәк, коронавирус бөтенләй яңа проблема түгел?

– Бик дөрес сорау бирдегез. Яңа коронавирус бер дә көтелмәгән, ишетелмәгән проблема түгел. 2000 нче еллар башында ук дөньяның әле бер, әле икенче төбәгендә яңа инфекцияләр килеп чыгу ешая башлады. Эпидемиологлар бу феноменга «эмерджент инфекцияләр» (яңа, моңа чаклы билгеле булмаган) дигән исем бирде. Вирусология, эпидемиология белән якыннан таныш булмаган кешегә коронавирус өр-яңа бер проблема булып күренергә мөмкин. Тик Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы, 2000 нче еллар башыннан һәр ике ел саен 3 яңа инфекция килеп чыга, дип хәбәр итә иде. Бу инфекцияләрнең яңа коронавирус кебек бөтен дөньяга таралмавы эмерджент инфекцияләрнең кешедән кешегә аз йогышлы булуы белән бәйле. Мәсәлән, мин алда искә төшереп алган коронавирус семьялыгына караган – MERS–CoV бик зәһәр. Утыз процент очракта үлемгә китерсә дә, кешедән кешегә бик аз йогышлы булганга күрә, үзеннән-үзе юкка чыкты. COVID-19 исә йогышлы чир, ул алай җиңел генә юкка чыкмаячак. Яңа коронавирусның йогышлы булуы, кешедән кешегә җиңел күчүе аны башка эмерджент инфекцияләрдән аерып тора. Мондый инфекциянең килеп чыгу ихтималын галимнәр 2015 елда ук фаразлап куйганнар иде.

– Нишләп хәзер генә килеп чыкты соң ул? Теләсәң, теләмәсәң дә, бу яңа авырулар, ясалма юл белән килеп чыкмаганмы, дип уйлый башлыйсың...

– Юк, бу феноменны «теория заговора» белән аңлатырга кирәк түгел. Эмерджент инфекцияләр күп, аларның бөтенесен дә уйлап чыгарып бетереп булмый бит инде! Бу инфекцияләрнең килеп чыгуы, кешелекнең яшәү рәвеше үзгәрүе, глобальләшү белән бәйле. Бер мисал: 100 ел элек безнең яклардан Мәккәгә яисә Европага барып кайта алган кешеләр бармак белән генә санарлык иде. Сәяхәтләре атналар буе дәвам итә. Бүгенге көндә исә һәр теләгән кеше берничә сәгать эчендә дөньяның иң ерак почмагына барып житә ала. Ә сәяхәткә чыкканда без үзебез белән берничә миллиард микроорганизм да «эләктереп» алып барабыз. Бу процесска глобаль күзлектән чыгып карасак, глобальләшү кешеләргә генә түгел, микроорганизмнарга да кагылды, дип әйтергә була. Соңгы елларда вирусларның, бактерияләрнең эволюциясе күпкә тизләште.

Эмерджент инфекцияләр килеп чыгуның тагын бер сәбәбе – хайваннар белән кешеләрнең контактлары тыгызлашуы. Фәнни тикшеренүләргә караганда, кешеләрнең кыргый хайваннар, йорт хайваннары белән дә контактлары елдан-ел тыгызлаша. Әле 2000 нче елларда ук, дөнья буйлап санаганда, кеше якынча 40 мең маймылны, 640 меңнән артык рептилияне, берничә миллион кошны үзенә якын иярләштергән. Хайваннар өчен хас авыруларны «зооноз» дип атыйлар. Авыру хайван, кеше белән тыгыз контактка кергәндә, зооноз китереп чыгара торган микроблар мутациягә бирелеп, кеше өчен йогышлы формага әйләнә ала. Белгәнебезчә, яңа коронавирус Кытайның Ухань шәһәрендәге кыргый хайваннарны ризык итеп сатучы базарда нәкъ шушы юл белән килеп чыккан да. Әбием без кечкенә чагында: «Песи-этләрне кулыңа алма, сулышы тияр», – дия иде. Ә хәзер аларны кочаклап йоклыйлар...

– Бу куркыныч вируслы авырулар таралуның башка сәбәпләре дә бармы? Бу инде хәзер бүтәннәре дә килеп чыгачак дигән сүзме?

– Без әле тирәнтен белеп бетермәгән сәбәпләре дә бар инде аларның. Климатның глобаль җылынуы, төньяктагы мәңгелек бозлыкларның эрүе белән дә бәйлиләр аларны. Тагын башка теорияләр дә бар. Ничек кенә булмасын, эмерджент инфекцияләр – глобаль дөньяның тренды, үзенә күрә бер тенденциясе булып тора. COVID-19 да сәбәпсез генә килеп чыкмады, әлбәттә, тормышыбызның үзгәреше нәтиҗәсе бу. Яңа инфекцияләр киләчәктә кабатланып торачак. Моңа әзер булырга кирәк.

Шулай да бу проблемага оптимистик күзлектән карарга киңәш итәм. Минемчә, коронавирусны табигатьнең яки илаһи көчләрнең искәртүе дип санарга да кирәк. COVID-19 бик көчле, коточкыч леталь авыру булмаса да, проблеманың житдилеген күрсәтә. Бу пандемия безгә бик күп сабак бирде: монда шәхси гигиенаның мөһимлеге дә, биологик куркынычсызлыкның яңа таләпләре дә, халыкара сәяхәтләрнең тиешле дәрәҗәдә булырга тиешлеге дә, сәламәтлек системасын камилләштерү дә һәм кыргый хайваннарны газапларга, ризык итәргә ярамаганлыгы да күренде. «Кисәтелгән кеше – коралланган» ди бит бик тә популяр булган бер мәкаль. Күрәсең, бәлаказалар юкка гына килми...

– Бүген мәҗбүри булган битлек, перчаткалар ни дәрәҗәдә коронавирустан саклый? Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы битлекләрнең файдасы турында шик белдерде...

– Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы кул юуны һәм социаль дистанция саклауны профилактиканың төп чарасы дип саный. Коронавирус кулда озак саклана. Чисталык өчен антисептик та, гап-гади сабын да кулланырга ярый – әмма кулларны дөрес итеп, 20-40 секунд юу тиеш.

Битлек белән перчаткалар кешене үз битенә, күзенә, борынына кагылудан тыя. Тик ул чын медицина битлеге булырга тиеш, теләсә нинди шартларда тегелгән, чәчәк төшерелгән тукымадан ясалган битлек ярамый. Битлекне еш алмаштырып тормасаң, аны дөрес киепсалу кагыйдәләрен үтәмәсәң, ул, киресенчә, инфекция чыганагына әйләнә.

– Илдус Җәүдәтович, укучыларыбызга COVID-19 дан саклану өчен нинди киңәш бирер идегез?

– Төп киңәшем шул: игътибарлыгыгызны җуймагыз. Пандемия бетмәде әле. Коронавирус темасыннан туйган булсак та, проблема чишелмәде. Инфекция үзебезгә эләксә, аның нинди формада үтәчәген алдан әйтеп булмый, сак булу кирәк.

БӨТЕНДӨНЬЯ СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ ОЕШМАСЫ КИҢӘШЛӘРЕ:

1. Кулыңны чиста тот, сабын белән ешрак ю яисә антисептик белән эшкәрт.
2. Социаль дистанцияне сакла. Кеше күп булган урыннарга кермә.
3. Күзеңә, борыныңа, авызыңа кул белән кагылма.
4. Төчкергәндә, йөткергәндә борын һәм авызыңны бер кат кулланылышлы кульяулык белән капла.
5. ОРВИ симптомнары булганда, өйдән чыкма, өйгә табиб чакырт.
6. Дөрес, ышанычлы мәгълүмат чыганакларын карап бар. Медицина хезмәткәрләре биргән киңәшләрне тот.

ПИКЕДАН ЧЫГУ ЫСУЛЫ.
КЕЧЕ БИЗНЕС ТӘҖРИБӘСЕ

Әзерләде:
Катерина Котова

Фотолар геройларның шәхси архивыннан алынды

«Пациент ярымүле, ярымтере» – пандемиянең кызган мәлендә, кече бизнес турында сүз чыкса, аналитиклар шундый нәтиҗә ясый иде. «Эшкуар. Бүген бу сүз үлемгә китерә торган диагноз кебек яңгырый», – дип кушылып китә иде эшмәкәрләр үзләре дә. Ә менә котылгысыз статистика мондый төсмер алды: апрельдә кече һәм урта бизнес әйләнеше узган елның шул чоры белән чагыштырганда ике тапкырдан артыгракка кимегән. Мәсәлән, фитнес-үзәкләр кереме 90 процентка, кием-салым кибетләренеке – 88 процентка, матурлык салоннарыныкы – 85 процентка... Шул ук вакытта пандемиядән кече бизнесның барлык сегментлары да диярлек зыян күргән.

Ярар, пессимизм шуның белән җитеп торыр. Ничек кенә аяныч яңгырамасын, әмма еш кына зыян күрүчеләрне коткару аларның үзләреннән тора. Әлеге коткару эшендә нинди алымнар, нинди гайре табигый карарлар нәтиҗәле булыр иде – бу турыда без, бернигә дә карамастан, кәсепләрен саклап кала алучылардан сораштык.

«БЕЗ ИНДЕ ЭЛЕККЕГЕ КЕБЕК БУЛМАЯЧАКБЫЗ»

Александр Семенюта, җиһаз кибетләре челтәрен оештыручы һәм аның җитәкчесе:

– Пандемиягә кадәр без Россиядә каркассыз мебель кибетләре челтәрен үстерә идек. Үзизоляция башлангач очраган беренче кыенлык – студияләребезнең бер өлеше урнашкан молларның эштән туктавы. Товар калдыклары – шунда, аренда белән проблемалар башланды. Иң башта, хәтта ябык килеш тә, зур сәүдә үзәкләре ташламалар ясаудан баш тартты. Хосусый милек хуҗалары белән хәл әйбәтрәк иде – үзара яхшы мөнәсәбәтләр кризис чорында ташламалар буенча тиз арада килешү мөмкинлеген бирде.

Шоу-румнарга куелган барлык җиһазларны без үзебез ясыйбыз. Әмма кайбер сәүдә үзәкләре ябылгач, аларга ихтыяҗ кискен кимеде. Мондый вазгыятьтә җитештерүне ничек саклап калырга? Хәлне бәяләү, дөрес юнәлешне билгеләү өчен безгә тайм-аут кирәк булды. Күп тапкыр киелә торган саклагыч битлекләргә зур ихтыяҗ шул тайм-аутны алу мөмкинлеген бирде – эшләре туктатылмаган оешма һәм предприятиеләр үз хезмәткәрләрен битлек белән тәэмин итәргә тиеш иде. Алар миллионга якын битлеккә заказ бирергә әзер иде! Нәтиҗәдә безнең цех ике сменалап эшли башлады. Хәтта тагын эшчеләр ялларга туры килде. Күп тегү фабрикалары туктап калды бит, шунлыктан кадрлар җитәрлек иде.

Битлек теккән арада шул аңлашылды: үзизоляция режимы гамәлдә чакта безнең офлайн-сәүдә бөтенләй туктап калачак. Нәрсәнедер үзгәртергә кирәк! Элек без «тереләй» сату яклы идек. Хәтта клиент безнең турындагы мәгълүматны интернет челтәреннән тапса да, җиһазны үз күзе белән күрсен, тотып, ятып, утырып карасын, үлчәмен һәм тукымасын сайлап алсын өчен аны студиягә чакырырга тырыштык... Әмма инде бу вазгыятьтә интернет аша сәүдә итүгә күчү зарурлыгы ачык иде. Һәм менә биредә безгә маркетплейслар – электрон сәүдә зур онлайн-кибетләре бик булышты. Соңгы елларда алар гел популярлаша барды, тик без нигәдер алар белән танышырга ашыкмаган идек. Бу исә бик шәп юл булып чыкты! Нәтиҗәдә безнең барлык предприятиеләр дә онлайн-сатуга күчте, үзләренең социаль челтәрләрәнә күбрәк игътибар бирә, интернет-рекламадан күбрәк файдалана башлады... Гомумән алганда, без апрель ае планын үтәдек.

Минемчә, бу яңа юнәлеш безгә хәтта сезонлылык проблемасын хәл итәргә дә булышыр әле. Эш шунда ки, җәен гадәттә җиһазга ихтыяҗ кими. Ул чакта без B2C эшчәнлегеннән B2B эшчәнлегенә, ягъни хосусый клиенттан «бизнес өчен бизнеска» күчәбез. Көннәр җылыткач, ачык һавада зур чаралар үткәрелә, һәм без аларны оештыручыларга мебельне арендага биреп торабыз. Әмма быел бу юнәлеш туктар кебек. Шул ук вакытта кешеләр, өйдә утырырга мәҗбүр ителгәч, үз торакларын тагын да матурайтырга тырышачак, димәк, интернет-сәүдә артачак. Әлбәттә, безнең клиентларның сатып алу мөмкинлеге бераз кимеде. Алар акчаны санап тота, арзанрак модельләрне сайлый башлады. Без дә ассортиментны карап чыгарга, суперэконом җиһазлар линейкасы ясарга мәҗбүр булдык. Әйе, безнең урта чек кимеде, әмма, мондый стратегия нәтиҗәсендә, заказлар саны кимемәде.

Сүз дә юк, үзизоляция режимы тәгәлләнәчәк. Әмма бизнес инде элеккечә булмаячак. Форматлар алышыначак, өстенлекләр үзгәрәчәк. Инде бүген үк күпләр аңлады: кабинетларда озак киңәшүләрнең мәгънәсе юк, эшнең бер өлешен бик рәхәтләнеп ерактан торып та башкарып була, сәүдәне онлайн алып бару файдалырак. Үзизоляциядәге берничә атна мине дә инандырды: киләчәк – маркетплейсларда. Өстәвенә, алар пәйда булу белән кирәкле товарны табу һәм сатып алу бик мәшәкатьле булган кечкенә интернет-кибетләр чоры тәгәлләнәчәк. Электрон коммерциянең эре платформаларында сайланган һәм акчасы түләнгән товарны югалту куркынычы юк диярлек, ә сатып алучылар биргән бәяләмәләр һәм товарларның сатучылар күрсәткән идеаль сурәтләрдән шактый аерылып торган чын фотолары онлайн-базардагы көндәшлекне тагын да көчәйтәчәк.

> **Гадәт егерме бер көндә формалаша, диләр. Үзизоляция инде моннан озагракка сузылды. Кешеләрнең үз-үзен тотышының психологик моделе үзгәрде инде, хәзер ул ныгый гына. Шунлыктан онлайн-формат киләчәктә дә калачак!**

«ЯҢА ГАДӘТЛӘР ФОРМАЛАШТЫ!»

Азат Нәҗметдинев, заманча татар ашлары рестораннары челтәрен оештыручы:

– Без үзизоляция режимына ахыр чиккә кадәр ышанмадык – әлеге хәл безне читләтеп узар, дип уйладык. Тик шулай да аңа якынча ике атна кала чикләү чаралары керткән очракка берничә сценарийны эшли башладык. Әйе, хәзер безнең кунакларыбыз юк, заллар буенча бер тиен дә керем алынмый. Бу барлык рестораннарга хас проблема. Кемдер тиз арада вазгыятькә төшенеп, эшен үзгәртеп кора алды, кемдер исә аптырап калды. Бәхеткә, без өлгердек.

Элек без ризыкны өйгә кадәр илтеп бирми идек. Әмма коронавирус мәҗбүр итте! Алай гына да түгел, без аны берьюлы ике линиядә башларга булдык! Беренчедән, безнең рестораннарда әзерләнгән кайнар ризыкларны өйләргә таратуны оештырдык. Икенчедән, туңдырылган ярымфабрикатлар җитештерә башладык. Бу безнең өчен яңалык иде. Җитештерүне элек рестораннарыбыз өчен кирәкле эшләнмәләр ясау белән шөгыльләнгән үзебезнең фабрикада җайладык.

Бүген әлеге ике юнәлеш тә безнең өчен бертигез, аларның һәркайсы үзенең максатчан аудиториясенә исәпләнгән. Кызганыч, кешеләрнең сатып алу мөмкинлеге кимеде, һәм клиентларыбызның күбесе ризыкны өйдә әзерләүгә күчте. Өч балалы гаиләгә төшке аш әзерләүнең нәрсә икәнен шәхсән мин үзем бик яхшы күзаллыйм! Биредә ризыкның мул булуы һәм җиңел әзерләнүе мөһим. Без нәкъ менә шул ихтыяҗны канәгатьләндерергә булдык та инде.

Бизнесны тулысынча яңадан кору, әлбәттә инде, штатка да үзгәрешләр кертергә мәҗбүр итте. Функционал буенча рокировкалар котылгысыз иде: кунаклар юк, залда эш юк, керем аз – яңа чынбарлыкка һәм бизнесның яңа схемасына яраклашу таләп ителде. Безнең беркемне дә югалтасыбыз килмәде, шунлыктан бөтен төп составыбыз – компаниябезнең белемен һәм тәҗрибәсен саклаучылар – бүген яңа бурычлар башкара. Пешекчедән курьерлыкка күчеп, автомобильләрендә ризык ташучыларыбыз бар. Шалтыратуларны кабул итү өчен колл-үзәк булдырдык – анда элек кассада торган, матур сөйләшә, ризыкларны тәкъдим итә һәм сайларга булыша алган кайбер бүлекчә җитәкчеләре һәм сату буенча менеджерлар күчте. Кемнедер заказларны җыю-төрүгә, кемнедер туңдырылган ярымфабрикатлар җитештерү фабрикасына күчердек. Хезмәткәрләребезнең барысы белән дә аерым-аерым утырып сөйләштек. Һәм барысы да безнең белән ризалашты. Асылда, безнең алда ике генә юл иде бит. Йә безнең команда бербөтенгә туплана һәм башка форматта, әмма барыбер бергә эшли башлый. Йә без эшсез калып бетәбез. Без беренче юлны сайладык, һәм бүген, күп рестораннар бөтенләй ябылганда, әкренләп үз әйләнешебезгә кайтып барабыз.

Гадәт егерме бер көндә формалаша, диләр. Үзизоляция инде моннан озагракка сузылды. Кешеләрнең үз-үзен тотышының психологик моделе үзгәрде инде, хәзер ул ныгый гына. Шунлыктан онлайн-формат киләчәктә дә калачак! Ризыкны өйләргә илтеп бирү дә дәвам итәчәк. Әлеге системаны автоматлаштыру буенча без бик зур хезмәт куйдык. Колл-үзәккә килгән заказ шунда ук рестораннарга һәм курьерларга бүленә, нәрсә әзерләргә кирәклеге аш бүлмәсендә дә шунда ук күренә. Туңдырылган ярымфабрикатлар җитештерүдән дә баш тартырга җыенмыйбыз – өйдә тукланырга күнеккән кешеләр саны артачак бит.

Әлбәттә, чикләүләр бетерелгәч, халыкның ресторанга йөри башлау ихтималы да бар. Алар, тәрәзә каршында утырып, күңел ачуга, аралашуга, дуслары белән бер чынаяк кәһвә эчүгә булса да сусаган. Әмма бу озакка бармас, дип уйлыйм. Күп кешегә акчаны санап кына тотарга туры киләчәк бит. Кризис безнең алга яңа маркетинг һәм технологик бурычлар куя. Әмма бу, асылда, кызыклы этәргеч. Уйлап табуны, тикшерүне, тиешле дәрәҗәгә чыгуны дәвам итәчәкбез.

“ Бүген асылрак кыйммәтләрне күрсәтү мөһим. Мәсәлән, санитария кагыйдәләрен төгәл үтәү, югары сыйфатлы продуктлардан сәламәтлеккә файдалы һәм иммунитетны ныгытырлык ризыклар әзерләү, илтеп тапшырганда бик игътибарлы, әдәпле булу...



«БУ – БАШКА ЧЫНБАРЛЫК»

Максим Шаргородский, бизнес мәктәбен оештыручы һәм аның җитәкчесе:

– Иманым камил, кризис чорында эшкуар өчен ике генә вариант бар. Беренчесе – вазгыятькә үлеп баручы аккош күзлегеннән карау: стресска бирешү, әмма дәүләттән ниндидер тиеннәр теләнә-теләнә, яшәргә маташу... Икенчесе – мөмкинлекләрне чамалап, нәрсә булса да эшләргә тырышу. Үзебезнең шуңа көч табуыбызга без бик шат.

Безнең тармакка беренчеләрдән булып зыян килде: коронавирус аркасында барлык гавами чаралар тыелды. Бизнес-тренинглар базарында без инде җиде ел эшлибез, шулай да көйләнгән эшкә тиз арада төзәтмәләр кертергә туры килде. Элегрәк без онлайн эшкә әллә ни игътибар бирми идек – ничарадан бичара хәлгә калгач, нәкъ менә шуның белән шөгыльләнер чак җитте.

Бер атна эчендә диярлек без маркетинг, реклама, сатуның барысын да үзгәрттек. Элегрәк планлаштырылган чараларда эшләүдән баш тартмадык. Әйе, бер яктан без күпмедер вакытка Татарстандагы офлайн базарыбызны югалттык, икенче яктан исә яңа кагыйдәле һәм чикләнмәгән географик мөмкинлекләргә ия интернет-базарны кабул иттек. Коронавируска бәйле вазгыять җайлангач, бизнесыбызда бер юнәлеш урынына ике булыр, дип өметләнәм.

Үзизоляция режимында пәйда булган кыенлыкларның берсе – хезмәт дисциплинасы. Өйдә эшләүгә күчкәч, шәхсән мин үзем әллә ни аерма сизмәдем – төшке ашка вакытым кыскарды һәм юлга акча әрәм ителми башлады. Әмма безнең кайбер хезмәткәрләргә кыенга туры килде. Ярый ла мин гаиләмне авылга җибәрдем. Тик бөтен кешенең шундый мөмкинлеге юк бит. Мотивацияне ничек югалтмаска, гаилә проблемаларына игътибарны киметеп, «мин яшәгән фатир» белән «мин эшләгән фатир» арасындагы чикне ничек билгеләргә? Бераз хезмәт куярга туры килде.

Бүген сатып алу сәләтенең кимүе хакында сөйлиләр. Күп клиентның акчасы бар, әмма әле аны тыныч кына туздырырлык иминлек дәрәҗәсенә ирешә алмыйлар. Кешеләр чыгымнарын рациональ рәвештә, төптән уйлап планлаштыра башлады. Һәм моны һичшиксез исәпкә алу зарур. Һәр эшкуар үзенә мондый сорау бирә бүген: клиентка мин нәрсә тәкъдим итәм, аның нинди ихтыяҗын канәгатьләндерәм? Кичә сезнең рестораныгыз булып, бүген исә йортлар буйлап төшке аш таратып йөрисез икән – бу «кешеләрне ашату» гына түгел инде.

Бүген асылрак кыйммәтләрне күрсәтү мөһим. Мәсәлән, санитария кагыйдәләрен төгәл үтәү, югары сыйфатлы продуктлардан сәламәтлеккә файдалы һәм иммунитетны ныгытырлык ризыклар әзерләү, илтеп тапшырганда бик игътибарлы, әдәпле булу... Әлеге сорауга җавап биргәч, без үзебезнең продуктлар линейкасын үзгәрттек – мотивацион чараларны туктатып, биредә һәм хәзер файда китерерлекләрен генә калдырдык.

Әйе, кызганыч, бизнесның хәзерге чынбарлык шартларында үзгәртеп коруы катлаулы булган формалары да бар. Әмма бу еш кына кешеләрнең: «Яхшы иде, начарланды» – категориясендәге уйлануларыннан килеп чыга. Әмма моңа карашны үзгәртергә вакыт: «яхшы» түгел, ничек бар, шулай иде. Бу бары тик ничек кабул итүгә генә бәйле. Күз алдыгызга китерегез әле: бәлки, без яңа эра башлануына шаһит булганбыздыр һәм якындагы 500 елда да бүгенгедәй хәл сакланачактыр? Әлбәттә, кайгырып утырып була, янәсе, хәтерлисеңме, кайчандыр ерак 2019 елда кешеләр урамга чыга алган бит, дип. Әмма моңардан гына бернәрсә дә үзгәрмәячәк. Мин үзгәртелгән нәкъ менә шушы чынбарлыкта һәм вазгыятьтә яшим, ул миңа уенның яңа кагыйдәләрен тәкъдим итә. Һәм, чын эшкуар буларак, аларны аңларга, үз эшемне аларга яраклы рәвештә оештырырга, базардагы иң шәп тәкъдимне ясарга тиешмен. Димәк, миңа бизнес-моделемне дә, ә ихтимал, бөтен бизнесымны да үзгәртергә туры киләчәк.

КОВИД ЧОРЫНЫҢ ОФЛАЙНЫ

Эш, уку, консультацияләр, күңел ачулар, фитнес – март ахырында Татарстанда боларның барысы да онлайнга күчте. Шул ук вакытта, өйдә утырмыйча, хезмәт итүчеләр дә булды. Сүзебез – алар турында… Ничек эшләүләре һәм үзләрен ничек хис итүләре турында белештек.

Автор:
Алсу Троицкая

«БЕЗ ЭШЛИБЕЗ. БЕЗ ТЫРЫШАБЫЗ»

Айнур Нуриәхмәтов, Республика клиник дәваханәсенең травматолог-ортопеды:

– Хәзерге вакытта мин дәваханәнең кабул итү бүлмәсендә яңа килгән пациентларны карыйм. Эпидемия чорында төрле белгечлек буенча табибларның бер-берсенә ярдәм итүе табигый. Бүген стационарда минем белән терапевтлар, рентгенологлар, кардиологлар, төрле хирурглар, неврологлар эшли… Барыбыз да коронавируслы авыруларны кабул итү буенча сертификацияләнгән курслар уздык. Әйе, мәгълүмат чаралары тарафыннан безгә игътибар зур хәзер. Теләсә кайсы илдә, теләсә кайсы шәһәрдә медикларга җиңел түгел бүген. Һәм беребез дә үзенең һөнәре белән масаеп йөрми. Безнең өчен ул – бары тик эш.

Башка табиблар кебек үк, мин дә үземнең гаиләм өчен борчылам. Өйгә инфекция алып кайту ихтималын да бик яхшы аңлыйм. Аларга куркыныч тудырмас өчен хатыным белән дә, балаларым белән дә, әти-әнием белән дә айдан артык инде күрешкәнем юк. Якыннарым хәзер авылда яши. Әлбәттә, сагынам, ләкин башкача мөмкин түгел. Вакытлыча дәваханә кунакханәсендә яшим – һәр кизүдән соң шунда кайтам.

Ял көннәре азрак, эш күбрәк хәзер. Процедуралар саны да артты. Кизү вакытында экипировка, мәсәлән. Тиешле бөтен киемне, саклану чараларын үз тәртибе белән кияргә кирәк. Саклану костюмын, башлыкны, респираторны, күзлекне, перчаткаларны. Сменадан соң, шлюзда кире тәртиптә чишенеп, аларны эшкәртергә тапшырырга. Инструкция генә түгел бу. Табибларның һәм пациентларның сәламәтлеге шуннан тора. Авырулар өчен без барыбыз да бер, шуңа да исемнәребезне саклану костюмнарына язарга туры килә.

Без эшлибез. Без тырышабыз. Минем дөньяны тоемлавым үзгәрдеме соң? Асты-өскә килде дип әйтә алмыйм. Ләкин бүгенге көндә якыннарым белән бергә үткәргән вакытның кадерен ныграк белә башладым. Мөгаен, төп үзгәреш – шушы. Ныклы сәламәтлек барыгызга да!

«КАЙДА ЯРДӘМ КИРӘК БУЛСА – БЕЗ ШУНДА»

Анна Макарова, «Волонтер-медиклар» Бөтенроссия иҗтимагый хәрәкәтенең Татарстан Республикасындагы җитәкчесе:

– Ябык ишекләр, бушап калган юллар, кешесез урамнар… Ә без исә эштән туктамадык. Шәһәр март ахырында йокыга талгандай булды – урамнарга «Без бергә» Бөтенроссия үзара ярдәмләшү акциясенең волонтерлары чыкты. Эшебез – пандемия шартларында чыннан да ярдәмгә мохтаҗларга, ягъни өлкән яшьтәгеләргә һәм мөмкинлекләре чикләнгән кешеләргә булышу. Азык-төлек, дарулар китерү, дәваханәләрдән рецептлар алу, ТКХ хезмәтләренә түләү. Катлаулы эш түгел. Безгә федераль кайнар телефон номеры аша (8 800 200 34 11 – ред. иск.) шалтыратулар килә, без аны кабул итәбез, төгәлләштерәбез һәм юлга чыгабыз.

Шулай ук 500 дән артыграк волонтер-медиклар Татарстанның медицина оешмаларында хезмәт куйды һәм куя: авыруларның температурасын үлчи, табибларга амбулаториядә һәм реанимациядә ярдәм итә.

Үзизоляция? Юк, мин аны сизмим. Көн саен ялсыз эшлибез. Кешеләр өйдә калса, коронавирус инфекциясенең таралуын туктатып булуын аңлыйбыз. Һәм бу безнең төп бурычыбыз булып тора.

Әлбәттә, күп нәрсә үзгәрде, кешеләр мондый яшәү рәвешенә күнекмәгән иде. Ләкин нәкъ менә хәзер мин аралашуның тәмен белә башладым. Социаль челтәрләрдә түгел, ә күзгә-күз. Кешеләр бер-берсе белән янәшә булгандагы аралашуны. Табибларга әлеге эпидемиологик вазгыятьтә никадәр кыен булуын аңладык. Алар көн саен алны-ялны белмичә авыр шартларда эшли. Мин аларның хезмәте белән чиксез горурланам.

«КАРДИНАЛЬ ЧАРАЛАР БЕЛӘ ТОРЫП ТӘРТИП БОЗУЧЫЛАРГА КАРАТА ГЫНА КУЛЛАНЫЛА»

Рамил Сафин, Россия Эчке эшләр идарәсенең Казан буенча патруль-пост хезмәтенең 1 нче батальоны бүлекчәсе командиры:

– Безгә, полицейскийларга, шулай ук яңа шартларга яраклашырга туры килде. Әйе, хезмәтебез катлаулырак, кыенрак хәзер – вак урлашулар саны артты. Күрәсең, эшсезлекнең артуы йогынты ясады. Кагыйдә буларак, азык-төлек кибетләреннән ашамлыклар, исерткеч эчемлекләр урлыйлар.

Безнең төп бурычларның берсе – урамда булмаска тиешле кешеләрне кисәтү. Сәламәтлеге хакына. Без аларны җинаятьчеләрдән дә, чир йоктыру ихтималыннан да сакларга, аларның куркынычсызлыгы өчен барысын да эшләргә тиеш. Юк, безнең максат аларны штрафка тарту түгел. Болай да эшсез калганнарны соңгы акчаларыннан мәхрүм итү эш түгел инде ул. Без, беренче чиратта, хокук саклаучылар һәм хокук бозулар буенча профилактика белән шөгыльләнергә тиеш, җәзалау чаралары күреп, кешеләрнең ачуын китерә торган фактор булырга тиеш түгел.

Без бөтен кешене дә намуслы һәм яхшы итә алмыйбыз. Килеп чыккан вазгыять барыбыз өчен дә яңа, аны аңлар, төшенер өчен вакыт кирәк. Шуңа да без халык белән күп аралашабыз – урамда, кибетләрдә, даруханәләрдә... Бернинди максатсыз урамда йөрергә ярамый, бары тик өйдә калып кына без бу хәлдән исән-сау чыга алачакбыз, дип аңлатабыз. Бары тик белә торып тәртип бозучыларга карата гына кардиналь чаралар күрәбез.

Иң кыены нәрсә? Урамда яз, кояш көлеп торса да, өйдә утырырга кирәк, урамда саф һава сулап йөрергә ярамый, дип, балаларга аңлатуы кыен. Хатыным да, балалар да – үзизоляциядә. Безнең өчен иң яхшысы – дача. Иң шатлыклы көннәр – эштән соң, гаиләм янына дачага кайту. Якын кешеләрем янәшәдә, балалар көлә, бергәләп ашыйбыз, ашыкмый гына сөйләшеп утырабыз – кешегә бәхет өчен тагын ни кирәк?

«СЕЗНЕҢ ЧӘЧНЕ БЕРӘҮ ДӘ ОНЛАЙН КИСМӘЯЧӘК»

Лидия Егорова, чәчтараш:

– Берничә атна рәттән мәҗбүри ялда эшсез һәм акчасыз өйдә утырырга мөмкинлегем юк. Беренчедән, балага урамда коронавирус, шуңа күрә өйдә ашарга юк, дип аңлатып булмый. Икенчедән, кредитларым бар, ә ярдәм итәр кешем юк. Шуңа да үземә генә ышана алам. Беренче атнада мин дә паникага бирелдем... Әйе, мин дә башка меңнәрчә вак эшкуар хәлендә калдым, ләкин моны белү миңа тынычлык китермәде. Мин үземә: «Лида, тыныч бул һәм вакыйгаларның кая таба баруын күзәт: нәрсәгә әзер булырга – шуны аңларга кирәк», – дидем.

Чәчтарашханәләргә ачылырга рөхсәт булу белән шунда ук мини-салоныма эшкә чыктым. Үзләрен тәртипкә китерергә теләүчеләр бик күп булып чыкты. Хәзер мин ишек тоткаларын даими эшкәртәм һәм клиент күп тапкыр кагылып үткән урыннарга даими рәвештә дезинфекция ясап торам. Битлек һәм перчаткалар киям. Алдан язылу буенча гына эшлим. Эш хәзер йола кебек башкарыла. Клиентны билгеле бер вакытка язасың, шул вакытка килүен көтәсең, салон ишеген ачасың, чәчен кисәсең, буйыйсың да артыннан ишекне ябып озатып каласың...

Клиентлар дүрт-биш атнага бер тапкыр чәчен тәртипкә китерә, кыска чәчлеләр ешрак та йөри. Даими клиентларны санаганда гына да, ике атна алдан язылырга кирәк. Яңалары турында әйтеп тә тормыйм. Кайчандыр чәчтараш һөнәрен сайлавым белән бәхетле! Кешеләр һәрвакытта да чәч кистерергә йөриячәк. Һәм бу эшне онлайн башкарып булмый.



«МИН ӘЛЕ ТЫП-ТЫНЫЧ»

Александр Мельников, Казанда он һәм комбиазык җитештерүче компаниянең машина йөртүчесе:

– Үзизоляция минем тормышта берни дә үзгәртмәде. Гадәти режимда башка хезмәттәшләрем кебек эшләдем. Кешеләргә яңа пешкән ипи көн саен кирәк бит. Димәк, ипи пешерүчеләр өчен үзизоляция була алмый. Мин үзизоляциядә төрле вебинарларда катнашып, йөзләрчә яңа күнекмәләр алган, йөзләрчә кинофильмнар караган яки фатирына ремонт ясарга өлгергән суперкешеләр рәтеннән түгел. Минем тормышны «аңа кадәр» һәм «аннан соң» дип бүлеп булмый. Ихтимал, бүгенге вазгыятьтә шулай яхшырактыр да.

Алай гына да түгел, эшләгәндә тотрыклылык хисе, иртәгәге көнгә ышаныч бар. Өйдә генә утыручылар арасында, аралашу җитмәү нәтиҗәсендә, психик киеренкелек барлыкка килгәннәр дә бар. Миндә исә андый нәрсә булмады.

Нәрсә хис иттемме? Коронавирус куркынычы барлыкка килүгә, әлбәттә, туганнар, дуслар белән аралашуны туктаттым. Күңелдә берничә этап булып узды: шок, кабул итү, инкарь итү...

Ләкин, дөресен генә әйткәндә, мин үземне тыныч хис итәм. Бу хәл берәр кайчан узар һәм барысы да элеккечә булыр, дип ышанам. Дуслар белән үзебез яратып йөри торган кафега барып, креветкалар капкалап, сыра эчеп, кинотеатрда берәр фильм карар көнне түземсезләнеп көтәм.

ТАТ МЕДИА

ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР

Язылган өчен мотоблок, ТВ, планшет һәм башка бүләкләр от!

Бүләкләр 2020 елның 19 августында уйнатылачак

1 языл — 2020 елның 30 июненә кадәр «ТАТМЕДИА» АҖнең газета һәм журналына языл (акциядә катнашучы басмалар белән tatmedia.ru сайтында танышып була)

2 җибәр — «Акция» билгесен куеп, язылу квитанцияләренең күчермәсен безгә җибәр (телефон номерын язарга онытма). Адрес: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 яки podpiska@tatmedia.ru

3 от — Язылган өчен мотоблок, телевизор, планшет, тузансуырткыч, 100 л бензин, блендер, үтүк от

Тулырак мәгълүматны, акциянең узу вакытын, бүләкләр, аларны алу тәртибен tatmedia.ru сайтында белә аласыз. Акция 2020 елның 12 маеннан 2020 елның 20 сентябренә кадәр үткәрелә. Гаризалар 2020 елның 20 июленә кадәр кабул ителә. Оештыручы – «ТАТМЕДИА» АҖ. Реклама 16+
Бүләкләр рәсемдә күрсәтелгәннән үзгә булырга мөмкин.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

КЕМ ул китап академигы

2020 елда **НИНДИ** татар китаплары дөнья күрде

КИТАП ҺӘМ МИЛЛӘТ САГЫНДА

Автор:
Мөршидә Кыямова

Әбрар Кәримуллин – дөньякүләм танылган китап тарихы белгече, татар тарихы буенча йөзләгән хезмәт язган олпат галим. Исән булса, быел аңа 95 яшь тулган булыр иде. Ул милләткә татар китабының мең еллык тарихын язып калдырды. Шулай ук Ерак Көнчыгышта яшәүче татар мөһаҗирләренең тарихын һәм язмышын беренчеләрдән булып фәнни дәрәҗәдә өйрәнә башлаган галим буларак та беләбез без аны.

«ЯҢА ЮЛЛАР АЧКАН КАҺАРМАН»

Шәкертләре белдергәнчә, яу кырыннан кайткан Әбрар Кәримуллин гомеренең соңгы елларына кадәр үзен чын хәрбиләрчә тота. Әгәр алар арасында солдат хезмәте узып укырга керүчеләр булса, галим-мөгаллим еш кына: «Как военный военного, друг-друга поймем! » – дип әйтә торган була. Һәрвакыт җитди, тәвәккәл остаз башкалардан да шуны таләп итә.

Бөек Ватан сугышы солдаты буларак, ул Курск дугасындагы сугышларда, Украинаны, Венгрияне, Чехословакияне, Румынияне азат итүдә катнаша. Аннары Ерак Көнчыгышка япон милитаристларына каршы сугышка җибәрелә. Монголия, Кытайдагы үлем далаларын, Хинган тауларын кичә. I дәрәҗә «Ватан сугышы» ордены, ике тапкыр «Батырлык өчен» медале һәм башка күп медальләр белән бүләкләнә. Өч тапкыр яралана. Авыр контузия алган егет 1947 елда гына туган ягына кайтып егыла. Сугыш яралары аны гомере буена сызлап бимазалый. Һәм ул гомере буена, аякларын мамык шәлгә урап, эш өстәле янында кыйблага тугры калып иҗат итүен, милләт язмышындагы аяныч сәхифәләрне барлавын дәвам итә.

Бу шәхесне якыннан күреп белгән кешеләр аны үзенчәлекле холыклы, тиз кызып китә торган иде, дип искә ала. Милләт турындагы дискуссияләр вакытында да ул һәрвакыт үз фикерендә нык тора, башкаларга аның дөреслеген расламыйча чигенми.

Әбрар Кәримуллин татар халкының исемен һәм җисемен ачыклауга багышланган күпсанлы китаплар авторы да. Ул күп еллар дәвамында китап белеме, китапханә тарихы, китап фондлары, аларны туплау мәсьәләләре, каталоглар системасы, китап сайлау, басмалар белән эшләү кагыйдәләре, диплом һәм диссертацияләрдә библиографияне бирү тәртибе һәм башка темаларга лекцияләр укый.

Китап галиме төрле халыкара фәнни конференцияләрдә һәм конгрессларда катнаша, күп кенә халыкара оешмаларга кабул ителә, берничә тапкыр «Елның атаклы кешесе» дип билгеләнә, чит илләрдә басылган энциклопедик сүзлекләрдә галим турында материаллар басыла.

Милли яңарыш алып килгән 1990 нчы елларда Әбрар Кәримуллин Америка, Канада, Франция, Төркия архивларында эшли. Чит илләрдә гомер итүче милләттәшләр белән очрашып, татар мөһаҗирләре турында кыйммәтле материаллар туплый, аларны Татарстанга алып кайта. Ерак Япония белән элемтәләрне җайга сала, япон галимнәре белән таныша. Андагы татар тарихы турындагы шактый хезмәтләрне Казанда матбугат битләрендә киң катлам халыкка ирештерүдә үзеннән саллы өлеш кертә.

Тойо Бунко (Шәркыят көтепханәсе) фәнни хезмәткәре, Токио университеты профессоры Хисао Комацу татар галимен җылы сүзләр белән искә ала. Алар Әбрар Кәримуллин турындагы истәлекләре белән бик теләп уртаклашты. Хисао Комацу хатирәләренә тукталып узыйк: «Мәрхүм Әбрар бәй белән беренче тапкыр 1991 елның август башында Казанда таныштым. Ул вакытта мин Төркестан һәм Россия мөселманнары арасында җәдитчелек, ислах хәрәкәтен өйрәнү белән шөгыльләнә идем. Татарстанда Шиһабетдин Мәрҗани һәм «Шура» журналы кебек темалар буенча тикшеренүләр уздырылуын белә идем. Үзбәкстан Язучылар берлеге чакыруы буенча, Ташкентта булганнан соң, аларның киңәше белән туп-туры Әбрар бәйгә килдем. Ул һәм аның хатыны мине бик җылы кабул иттеләр. Бер атнага якын аларның йортында кунак булдым. Әбрар бәй миңа Казан шәһәрен дә, Иске Болгар шәһәрен дә күрсәтте. Татар зыялылары, шул исәптән вафат булган профессор Миркасыйм Госманов белән таныштырды. Әбрар әфәнде ярдәме белән мин Казанның гыйльми һәм мәдәни мохитен белә алдым. Төнге поездга утырып Казаннан Мәскәүгә киткәндә, Кинтә ханым минем өчен күп итеп өчпочмаклар әзерләде: Мәскәүдә һич тә ач йөрмәдем. Тагын бер нәрсә минем хәтеремә нык уелып калган. Поезд Казан вокзалыннан кузгалып киткәндә, микрофоннан бер дә көтмәгән тавыш ишеттем: «Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахииим». Дөресен генә әйткәндә, бу Советлар Союзының соңгы көннәрен яшәве иде. Токиога кайткач, Әбрар бәй белән хат язышуны дәвам иттем һәм без янә Казанда җыелган халыкара конференцияләр вакытында очраштык. Аның танылган әсәрләреннән: «Татарлар: исеме һәм җисеме» дигән китабына мин «Тойо Гакухо» журналында (Шәркыят җыентыгы) китап тanытмасы (рецензия) бастырдым. Аның «У истоков татарской книги: от начала

Фотолар автордан алынды

возникновения до 60-х годов XIX века» кебек хезмәтләре тикшеренүчеләр өчен гомер-гомергә бик файдалы фундаменталь чыганак булып калачак. Әбрар бәй Бөек Ватан сугышында гына түгел, фәнни тикшеренүләр өлкәсендә дә бетмәс-төкәнмәс батырлыкка ирешеп, яңа юллар ачкан чын каһарман иде», – дип язды безгә Токио профессоры.

ГЫЙБРӘТЛЕ ДӘ, ФАҖИГАЛЕ ДӘ ЯЗМЫШ

Замандашлары Әбрар Кәримуллинны татар теле өчен көрәшнең башында торган галим, диләр. Аның газета-журналларда дөнья күргән тирән фикерле язмалары, радио-телевидениедә яңгыраган чыгышлары халкыбызда милли үзаң тәрбияләүдә зур роль уйный. Милләт язмышына бәйле фикерләре әле бүген дә гаять актуаль булып кала бирә. Ана теле язмышын милләт язмышыннан аерылгысыз, дип санаган шәхес туган телгә нибары аралашу чарасы итеп кенә карамый.

«Телдән башка милләтне милләт итеп саклаучы бернинди көч тә, бернинди гамәл дә, бернинди юл да юк. Тел яшәгәндә генә милләт яши, телнең тормышта тоткан урынын милләтнең яшәеше билгели, теле йомшара башлаган милләтнең киләчәге юк, андый халык маңкортлашу юлына баса, юкка чыга, башка милләтләр үсеше өчен тирескә әйләнә. Милләт булып җитлеккән һәр халык моны бик яхшы аңлый һәм, шуннан чыгып, милли телен яклау, үстерү, аның тормышта тоткан ролен ныгыту өчен бөтен көчен бирә, аны күз алмасы кебек кадерли дә, яклый да, мактый да…», – ди ул үз чыгышларының берсендә.

«Үз анасын яратмаган кеше башка аналарны да ярата алмый. Үз туган теленә хөрмәте аз булган кешенең башка телләргә дә хөрмәте зур булмый. Үз туган теленә хөрмәте булмаган кешенең үз ата-анасына, үз халкының әхлак нормаларына, халкының сәнгатенә, тарихына да хөрмәте булмый. Милли нигилизм нигезендә вак, түбән хисләр, эгоизм, рухи, тарихи наданлык ята. Мондый кешеләргә үз шәхси мәнфәгатьләреннән тыш берни кирәк түгел – тел дә, гореф-гадәт тә…», – дип яза Әбрар Кәримуллин, тел турындагы ярсу хисләрен белдереп.

Галимнең фәнни һәм публицистик хезмәтләре исемлеге 700 гә якын эшне колачлый. Аның фәнни-тикшеренү темалары – милли китап һәм төбәкнең китапчылык эше тарихы, татар халкының килеп чыгышы, татар әдәбияты

Бер төркем иҗатчылар (сулдан уңга): Разил Вәлиев, Әбрар Кәримуллин, Равил Бохараев, утырган – төрек шагыйре Осман Төркәй. Лондон шәһәре.

һәм аның Шәрык, Европа әдәбиятлары белән бәйләнешләре, тел тарихы, археография, этнография, топонимика мәсьәләләре һ.б.

Әбрар Кәримуллинның тормышындагы мөһим кыйбласы – татар китабының тарихын өйрәнү. Алда әйтелгәнчә, татар милли китабының үсешен беренче булып ул тикшерә, шушы үсешнең этапларын билгели, басма китапларның эчтәлеген системалаштыра. Әбрар Кәримуллин раславынча, татарлар, дөньядагы төрки халыклар арасында беренче булып, хәреф җыю ысулы белән китап бастыруга керешә; татар тарихы, ягъни бу халыкның борынгыдан килгән язуы һәм бай кульязма китап мирасы, әдәби традицияләре, мәктәп-мәдрәсәләре, галимнәре, әдипләре булу һ.б. моны ышанычлы рәвештә дәлилли.

«Академик Георги (Иóганн Гóтлиб – ред. иск.) Идел-Урал буе татарлары турында язганда хәллерәк татар йортында, бигрәк тә сәүдәгәр, муллаларда шактый бай өй китапханәләре булуын искә ала. Казан ханлыгы чорында да, хәтта татарча басма китап барлыкка килгәч тә, бездә күчереп китап язу белән шөгыльләнүче осталар күп булуы тарихта яхшы билгеле. Кызганыч ки, ерак гасырлардан ул китапларның абсолют күпчелеге безгә килеп җитмәгән. Татар кульязма китабының тарихы гаять фаҗигале. Ничек кенә булмасын, ул бай кульязма мирасның бер өлеше сакланып калган, хәтта Рим, Париж, Лейпциг, Вена һәм башка чит ил китапханәләренә барып җиткән, әле дә анда саклана», – дип яза Әбрар ага.

Инкыйлабка кадәрге татар китабы сан ягыннан, рус басмаларыннан тыш, бары тик латыш китабыннан гына калыша, ә тиражы буенча рус китабыннан соң икенче урында тора. Әбрар Кәримуллинның үзенчәлекле фәнни трилогияне тәшкил иткән «У истоков татарской книги» («Татар китабының башлангычы», 1971), «Татарская книга начала XX века» («XX гасыр башы татар китабы», 1974), «Татарская книга пореформенной России» («Россиядә реформалар алдыннан татар китабы», 1983) хезмәтләре татар халкында инкыйлабка кадәр укый-яза белүчеләрнең аз булганы турындагы уйдырмаларга чик куя. Тынгысыз галим татар әдәбиятының үзенә кадәрге тикшеренүчеләр игътибарыннан читтә калган, цензура тарафыннан тыелган күпсанлы ядкәрләрен фәнни әйләнешкә кертеп җибәрә ала.

Библиограф милли китап теориясе үсешенә дә бик зур өлеш кертә. Беренче булып ул хәзер илебездәге китап белемендә кабул ителгән милли китап концепциясен эшли. Әбрар Кәримуллинның хезмәтләре Татарстанда гына түгел, ә илебезнең барлык төбәкләрендә, шулай ук чит илләрдә дә киң таралыш һәм лаеклы бәя ала.

Галимнең, күп вакытын сарыф итеп, иске басма татар китабы каталогларын яңартуы нәтиҗәсендә әлеге китап хәзинәсен киң җәмәгатьчелеккә җиткерү мөмкинлеге туа. Аның тарафыннан тел белеменә, фольклористикага, әдәбият белеменә, Татарстан тарихына караган библиографик күрсәткечләр күпләп төзелә. Нәкъ менә шушы хезмәтләрдән Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының сәнгать һәм фольклор бүлекчәсендә эшли ул. 1968 елда галим Татарстанда һәм аннан читтә эшләгән барлык (дәүләт, күчмә, колхоз-совхоз, халык) татар театрлары турында 8000 нән артык исемдәге татарча

Әбрар Кәримуллин раславынча, китапның теле, авторның милләте, әсәренең китап булып басылган урыны һәм башка сыйфатлары аның кайсы халыкка хезмәт итүе белән берлектә каралырга тиеш. Автор тарафыннан милли китапның берьюлы берничә халыкның, бигрәк тә кардәш халыкларның, уртак байлыгы булуы ихтимал икәнлеге ачыла.

һәм русча документны үз эченә алган «Татар сәхнәсе: 1917–1967 нче еллар» дигән зур библиографик хезмәтен тәмамлый. Бу – татар театрының үзенчәлекле энциклопедиясе, илебездәге библиографиядә хәзер дә тиңе булмаган хезмәт.

1991 елдан Әбрар Кәримуллин – Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең фәнни киңәшчесе. Кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге аның җитәкчелегендә «1722–1917 нче елларда дөнья күргән татар басма китабының җыелма каталогы»н төзүгә керешә. Әлеге каталогны бастырып чыгару – Татарстанның, Россиянең, төрки телле дәүләтләрнең, шулай ук Европа һәм Американың зур китапханәләрендә сакланган иске басма татар китапларын барлап, теркәп кую дигән сүз.

Милли китапханә фондларында Әбрар Кәримуллинның шәхси китапханәсендәге, исән чагында үзе бүләк иткән китаплар тупланмасы да кадерләп саклана. Әлеге тупланма татар, рус, башкорт, инглиз, төрек телләрендә китапчылык фәненә, тел һәм әдәбият белемнәренә, тарихка, библиографиягә һ.б. караган дүрт меңгә якын китап һәм журналдан гыйбарәт. Галимнең вафатыннан соң, хатыны Кинтә Батыева фондка аның кульъязмаларын, хатларын, фоторәсемнәрен һәм шәхси әйберләрен тапшыра.

Татарстан Республикасы Милли китапханәсе, мәшһүр фән эшлеклесе Әбрар Кәримуллин истәлегенә багышлап, 2003 елдан бирле ике елга бер тапкыр «Кәримуллин мемориаль укулары» фәнни-гамәли конференциясен оештыра. 2012 елдан ул халыкара конференция дәрәҗәсен ала. Әлеге мемориаль укуларда тикшерелә торган мәсьәләләр даирәсе шактый киң.

УЛ КАЛДЫРГАН ЭЗЛӘР

1996 елда басылып чыккан «Язмыш, язмыш… » дигән китабы да авторның үз халкы язмышына багышланган. Монда чит илләрдә яшәгән милләттәшләребезнең гыйбрәтле гомере һәм үзебезнең Татарстандагы милли-мәдәни, фәнни, әдәби һ.б. проблемалар яктыртыла.

1997 елда Әбрар Кәримуллинның татар теле тарихы, аның бүгенгесе, киләчәге мәсьәләләренә багышланган «Тел – милләтнең сакчысы» дигән китабы дөнья күрә. Татар телен яклауга, саклауга, үстерүгә, камилләштерүгә, аңа мәхәббәт тәрбияләүгә багышланган бу хезмәт гаҗәеп актуаль проблемаларны ачып сала, аларны гамәлгә ашыру өчен кулланма да булып тора.

Галимнең 2000 елда басылган «Без тарихта эзлебез» дигән китабында, исемннән үк күренгәнчә, татар халкының тарихына, мәдәниятенә караган материаллар тупланган. Биредә автор татар халкының милли азатлык, тигез хокуклылык, мөстәкыйльлек өчен көрәшен фәнни-публицистик рухта яктырта.

Иҗатта, фән дөньясында зур уңышларга ирешкән, дөньякүләм абруй яулаган галим шәхси тормышында да түгәрәк бәхетле булган дип әйтә алмыйбыз. Бердәнбер улы Шамилнең яшьли дөнья куюы мәгълүм. Әмма тормыш иптәше белән алар гомер буена бер-берсен аңлап яшиләр. Күренекле китап белгеченең якташлары хәбәр иткәнчә, Әбрар Кәримуллинның туганнары юк. Күршеләре һәм якын итеп йөргән, хатлар язышкан 80 яшьлек Фәрия апа гына исән. Галимнең аңа атап язган хатлары Олы Нырты авылы китапханәсендә саклана. 2001 елның 25 июнендә бу китапханәгә ТР Министрлар Кабинеты карары белән академик Әбрар Кәримуллин исеме бирелә. Шулай ук Байлар Сабасы бистәсендәге бер урам да Әбрар Кәримуллин исемен йөртә.

Сабада атаклы якташларын зур хөрмәт белән искә алалар. Ел саен галимнең туган ягында Әбрар Кәримуллинга багышлап әдәби сәгатьләр, күргәзмәләр оештырыла. Быел да Татарстан Республикасы Милли китапханәсе белән берлектә, Әбрар Кәримуллин исемендәге Саба район китапханәсе күренекле якташларының юбилее һәм Саба төбәгендә туып-үскән

ҺӘММӘБЕЗ ӨЧЕН ДӘ – МӨГАЛЛИМ

Разил Вәлиев, Татарстанның халык шагыйре:

– 1986 елның июль аенда мине В.И. Ленин исемендәге Республика фәнни китапханәсенә (хәзерге Милли китапханәгә) директор итеп билгеләп куйдылар. Шулчак башыма иң беренче килгән фикер – Әбрар ага Кәримуллин белән киңәшү булды. Эшебезне ныклы фәнни нигезгә салу өчен, Әбрар аганы китапханәгә эшкә чакырдык. Ул капыл гына ризалашмады: «Моңа кадәр бу китапханә Обкомның агитпункты ролен башкарды. Әгәр ул чын мәгънәсендә Милли китапханә булып, халкыбызга хезмәт итә башласа гына, бу эшкә алынам», – диде. Безнең дә ниятебез шундый икәнне белгәч, ризалашып, китапханәнең фәнни консультанты булып эшли башлады.

Борынгы татар китапларын эзләп, без аның белән Киевка, Ташкентка, Бохара һәм Сәмәркандка, Мәскәүгә юл тоттык. Мин хәтта Америкага барып, АКШның Конгресс китапханәсе белән эшчәнлек итү турында килешү дә төзеп кайттым. Торабара, офыкларыбызны киңәйтеп, китап һәм китапханәләргә багышланган халыкара конференцияләрдә, симпозиумнарда катнашу өчен Төркиягә, Англиягә, Канадага, хәтта Кытайга да барып чыктык. Бергәләп көрәшә, тарткалаша торгач, китапханә өчен ВЛКСМ Өлкә комитеты йортын һәм тагын берничә өстәмә бина алуга ирештек. Китапханәнең төрле бүлекләренә таралган борынгы кульъязма һәм басма китапларыбызны бер урынга туплап, аларны фәнни нигездә өйрәнү һәм системага салу өчен, кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге оештырдык. 1991 елда Канаданың Торонто каласында узган халыкара конференциядә Әбрар ага татар китабы тарихы турында рус телендә бик тәфсилле нотык тоткан иде. Әмма, тәрҗемәче булмау сәбәпле, аның эчтәлеген аңлаучы аз булды. Шунда ул: «Киләсе елда Англиядә узачак конференциягә хәтле мин, телне өйрәнеп, Кембридж каласында инглизчә чыгыш ясаячакмын», – дип сүз бирде. Казанга кайтуга ук инглиз теле курсларына йөри башлады һәм бер елдан соң Англиядә үз докладын инглиз телендә сөйләп шаккатырды. Ә аңа ул чакта 67 яшь иде! Гомумән, Әбрар ага Кәримуллинның бөтен тормышы милләт өчен игелекле гамәлләр кылудан, халкыбызга фидакарьләрчә хезмәт итүдән гыйбарәт булды.

Айсылу Габделхакова, Казан мәдәният институтының Китап белем, китапчылык һәм документлар өйрәнү кафедрасы профессоры:

– Әбрар ага белән беренче очрашуыбыз 1990 ел башында булды. Ул безнең кафедрага килгән иде. Бәлки, бу фәнни

танылган шәхесләр истәлегенә республикакүләм «Без тарихта эзлебез...» фәнни-эзләнү конференциясен үткәрү турында нигезләмә эшләнгән.

Остазлык бәхете дә тулы дип әйтә алабыздыр, чөнки күркәм шәкертләр калдырган Әбрар ага үз милләтенә. Академик Әбрар Кәримуллин җитәкчелегендә Татарстан фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында Г.Габделганиева, А.Габделхакова, Р.Вәлиуллин, Р.Сафиуллина, З.Гыйләҗевлар тарафыннан татар китабының төрле аспектларына багышланган кандидатлык диссертацияләре уңышлы яклана.

Әбрар Кәримуллинга хәтле, революциягә кадәр дә, Совет чорында да, һичшиксез, татар китабы тарихы буенча аерым эшләр башкарылган, ләкин аларны өйрәнелә торган теманың бөтен күләмен үз эченә алган, тулы канлы хезмәтләр дип атап булмый. Галимнең илебездәге китап белеме өлкәсенә керткән өлеше бәяләп бетергесез.

Токио университеты профессоры Хисао Комацу белән Болгар шәһәрлегендә. 1991 ел.

БЕЛЕШМӘ:

Әбрар Гыйбадулла улы Кәримуллин 1925 елның 29 маенда Саба районы Чәбия Чүрчи авылында туа. Әтисе Гыйбадулла – крестьян, соңрак агроном булып эшли, 1947 елда сугышта алган яраларыннан вафат була. Әнисе Сафия укытучы булып эшли. 1930 елда коллективлашу вакытында әнисен үтерәләр.

Әбрар якын-тирә авылларда укып, 1941 елда урта мәктәпне тәмамлый. Егетнең югары белем алу турындагы хыялларына сугыш үз төзәтмәләрен кертә. Ул колхозда тракторчы ярдәмчесе, бухгалтер, укытучы булып эшләп ала. 1943 елда Кызыл Армия сафларына чакырыла. Житомирда хәрби училище курсларын тәмамлагач, миномет наводчикы итеп фронтка җибәрелә.

Сугыштан соң, 1948 елда, ул Казан дәүләт университеты тарих-филология факультетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Аны тәмамлагач, университетның фәнни китапханәсендә эшли башлый: китапханәчедән башлап, фәнни эшләр буенча директор урынбасары дәрәҗәсенә кадәр күтәрелә. 1978 елда докторлык диссертациясен яклап, филология фәннәре докторы исемен ала. 1991 елдан – Татарстан Милли китапханәсенең фәнни консультанты.

Әбрар Кәримуллин – Татарстан Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы, ТАССРның атказанган фән эшлеклесе, Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе иясе, Кол Гали исемендәге халыкара премия лауреаты (1995). ТР Язучылар берлеге әгъзасы. Әбрар Кәримуллин 2000 елның 18 сентябрендә бакыйлыкка күчә.

конференция яки түгәрәк өстәл булгандыр? Казан мәдәният институтының Библиография һәм китап белеме кафедрасына югары, статуслы һәм бик энергияле кеше керүен хәтерлим. Моны барысы да сизеп алганнар иде. Аңа кадәр, 1970 нче елларда, ул безнең кафедрада эшләгән булган, бу – Мәдәният институтының башлангыч еллары, ул исә күренекле китап белгече һәм библиограф сыйфатында чакырылган булган. Әңгәмә барышында фән, аннары аспирантура турында сөйләштек. Кафедра мөдире урынбасары Т.В. Абалимова Әбрар Гыйбадулловичка минем кандидатлык диссертациясенең фәнни җитәкчесе булырга тәкъдим итте. Темасы шунда ук билгеләнде: «Революциягә кадәрге чорда татар балалар китабы». Әбрар ага бик кырыс, таләпчән җитәкче иде, хезмәтемнең нәтиҗәләренә, сыйфатына карата үз фикерләрен белдергәндә, еш кына кызып китә торган чакларын да хәтерлим. Диссертация язганда еш кына аларның өендә кунак булырга туры килде. Ульяновлар урамындагы фатирын хәзер дә хәтерлим. Китап киштәләре – түшәмгә кадәр, як-якта – каталог карточкалары тулган тартмалар, зур язу өстәле. Җәмәгате чәй, пироглар белән сыйлый. Әдәбият, язучылар, журналларда басылган соңгы әсәрләр турында гәп куертабыз. Кинтә апаның: «Әбрар бик җиңел яза, диләр. Әмма бу алай түгел. Үзенә кирәкле төп сүзне тапканчы, бик күп кәгазьнең башына җитә ул», – дигәне бик хәтеремдә. Үземне бәхетле кеше дип саныйм, чөнки фәнни һәм һөнәри эшчәнлегемне искиткеч кеше, талантлы остаз җитәкчелегендә башлап җибәрдем.

Ренат Вәлиуллин, Татарстан Республикасының Санкт-Петербург шәһәре һәм Ленинград өлкәсендәге Даими вәкаләтле вәкиле:

– Халкыбыз язмышына кагылышлы бер генә нәрсә дә аның игътибарыннан читтә калмый иде. Ул татарның чын тарихын торгызу эшендә армый-талмый хезмәт куйды, зур исемнәр, акча, матур йортлар кебек тормыш ваклыклары аны гомумән борчымады. Ул үзен беренче чиратта милләтнең яклаучысы, агартучысы буларак күзаллады. «Татарлар: исемебез һәм җисемебез», «Прототюрки и индейцы Америки: по следам одной гипотезы» һ.б китапларында ул татар халкының тарихына, мәдәниятенә караган материалларны яңа яссылыкта җиткерә алды, укучыларын уйланырга мәҗбүр итте. Әбрар ага үзенең бөтен барлыгы белән татар телен, гореф-гадәтләрен саклап калуны көнүзәк мәсьәлә итеп карады, ул күпләр әйтергә дә курыккан фикерләрне укучыларына җиткерә алды, күпсанлы мәкаләләрендә күңел ярсуын язып калдырды. Мин бу мәшһүр шәхеснең соңгы укучысы булдым, татар дәреслекләренә багышланган кандидатлык дессертациямне аның вафатыннан соң 3 ай үткәч якладым.

2020 ЕЛГЫ КИТАПЛАР, ЯКИ БҮЛӘККӘ НӘРСӘ КУЛАЙ

Автор: Луиза Янсуар

2020 елда мәдәни оешмалар һәм нәшриятлар планга кертелгән күпчелек проектларын һәм басмаларын паузага куеп торырга мәҗбүр булды. Татарстан китап нәшрияты да – шулар исәбендә. Әмма ел башында дөнья күреп өлгергән, инде сатуга әзер булган яңа кызыклы китаплары да бар нәшриятның. Аларны үзчикләү шартларында да tatkniga.ru сайтыннан заказ ясап сатып алып була иде.

2020 елда дөнья күргән яңа басмалар арасында күпчелекне шигырь җыентыклары, алар арасында да сайланма җыентыклар тәшкил итә. Бу санда шуларның берничәсенә күзәтү ясарга булдык.

Фотолар: ТКИ сайтыннан, goodfon.ru сайтыннан



ФӘНИС ЯРУЛЛИН
«АК БОЛЫТЛАР БУЛЫП АГЫЛА КҮКТӘН»

Нәшрият мөхәррирләре һәм китап кибетләрендәге сатучылар әйтүенчә, шулай ук мониторинг нәтиҗәләре буенча, Татарстанның халык шагыйре Фәнис Яруллин китаплары укучылар тарафыннан һәрчак күтеп алына һәм яратып кабул ителә. Шигырь җыентыклары – бигрәк тә. Бу шагыйрьнең әсәрләре, алардан канатлы сүзләр, цитаталар да – социаль челтәрләрдәге аккаунтларда иң еш искә алына торганнардан.

2020 елда дөнья күргән тупланманың төзүчесе – язучының хәләл җефете Нурсөя Яруллина. Әлеге китапта Фәнис Яруллинның 1982–1997 нче елларда иҗат ителгән шигырьләре тупланган. Җыентык хронологик тәртиптә төзелгән һәм, иҗади процессны эзлеклелегендә күрсәтеп, әдипнең еллар дәвамында ниләр уйлаганын, нәрсә сулап яшәгәнен чагылдыра.

Фәнис Яруллин иҗаты һәм шәхесе бербөтен булып үрелеп, кушылып китә бу җыентыкны укыганда. Фаҗигале шәхси язмышын иҗади бәхетле язмышка әверелдерү сәләтенә ия булган әлеге әдипне без көчле рухлы, һәрчак үз кыйбласына тугры калган зат буларак күрәбез, аның эчке давылларын, зилзиләләрен үзебез аша үткәреп, шагыйрьнең яңадан аяз күк астына чыгуына сөенәбез. Шул рәвешле, катарсис кичерәбез. Укучы аның иҗатындагы әнә шул яктыга, яшәүгә омтылган көчне, энергияне тоя һәм иҗатыннан үзенә дә яшәү көче ала, дип уйлыйм.

Моннан тыш, иҗатчы буларак, ул күп темаларны һәм проблемаларны колачлый, киң спектрдагы сорауларга җавап эзли. Әнә шул тынгысызлыгы – икенче сокландыргыч сыйфаты. Аның хакында «Шәһри Казан» газетасында басылып чыккан Айназ Нуретдинова исемле бер укучының мәкаләсендә түбәндәге юллар бар: «Күңелдә бер сорау туа: гомерлеккә урын-җиргә бәйләнгән кеше ничек бездән мең тапкыр күбрәк күргән икән? Ничек дөньяның барлык нечкәлекләрен дә тоя, аңлый белгән? Ул бит әле аңлап кына да калмый, кешеләрнең җаннарына, йөрәкләренә үтеп кереп, тетрәндерерлек итеп яза да белә. Фәнис абый һәр әсәренә күңел җылысын, җан ачысын, йөрәк ялкынын биреп яза. Шуңа күрә аның әсәрләрен укыган бер кеше дә тыныч кала алмый...»

Шулай язгандыр, күрәсең –
Яшим ике дөньяда.
Әйтерсең, бер үк вакытта
Коенам ике елгада. [...]

Ике дөньям – ике елгам
Беткән бергә чорналып:
Берсе шигърият дөньясы,
Икенчесе – чынбарлык.

Фәнис Яруллин шигырьләрен тоташ бер дулкында укыганда, аның хисләр һәм уйлар регистрын бар колачында кабул итәргә була. Бу җыентыкның уңай ягы һәм өстенлеге шундадыр, дип уйлыйм – бөтенлегендә. Тыйнак, җыйнак, һәм, бер үк вакытта, шагыйрьнең җитлеккән тормыш фәлсәфәсен чагылдырган саллы да тәэсир калдыра ул. Филолог буларак, мин, билгеле инде, аны Фәнис Яруллинның башка басылып чыккан җыентыклары, аның иҗаты турындагы тәнкыйди фикерләр һәм каләмдәшләренең шәрехләре контекстында кабул итәм. Шулай ук – көндәлекләре. Әмма бу җыентык гади укучы өчен дип аңлыйм, димәк, бу очракта – гадилектә галилек.

Тагын бер игътибарны җәлеп иткән фактор. Бүгенге заман укучысына, китапны кулга алгач та, бизәлеш әһәмиятле. Нәрсәгә төреп бирәләр бүгенге контентны – бу турыда бар яктан да кычкырып торалар, виртуаль платформалар, иң беренче эш итеп, «упаковка» төшенчәсен куллана. Бу җәһәттән, китапларга булган мөнәсәбәт тә аның тышкы кыяфәтеннән формалаша башлый, безнең башкалардан аерылып тора торган матур әйберне кулда тотасыбыз килә.

Бу җыентык үз сериясендә чыга торган башкалары кебек үк бизәлгән, димәк ки гадәти, дип кабул иттем, сатып алучы буларак. Эстетик яктан мин аны башкачарак – яңачарак күрергә теләр идем. Гомумән, мондый төр җыентыкларга яңа сулыш өрергә кирәк, дигән теләк бар...

Озын сүзнең кыскасы, «Ак болытлар булып агыла күктән» басмасы ул – киштәдән алып, күңелнең төрле халәтләрендә укый торган китап. Ә инде филологлар өчен – Фәнис Яруллинның шигъриятенә сылтама кирәк булып, тиз генә арада эзләп табар өчен кул астындагы уңайлы, кулай сайланма җыентык та...



ГАМИЛ АФЗАЛ
«АЙЛЫ КИЧЛӘР»

ГАМИЛЬ АФЗАЛ
«ЛУННЫЕ ВЕЧЕРА»

«Классик татар шигърияте» сериясендә басылып килә торган бу төр җыентыклар шәхсән минем үземнең күңелемә бик тә хуш килә. Бизәлеше, төзелеше ягыннан да күркәм, заманча, шул ук вакытта алар, гадәттә, кереш сүз белән чыгарыла. Әлеге кереш сүз укучыга әдипнең гомер һәм иҗат юлын бер кисемтәдә күрергә мөмкинлек бирә – тупланманы кабул итәргә әзерли. Ә инде соңыннан гына актарып чыгарга ният итүчеләрне өстәмә мәгълүмат, юнәлеш белән тәэмин итә. Гамил Афзал җыентыгының керешендә әдип үз иҗат юлының кыскача сурәтен тәкъдим итә – аңа гына хас ирониялe-ачы һәм лирик-җанлы тел белән…

Проектның җитәкчесе һәм Гамил Афзалның ошбу җыентыгын төзүче – Татарстан китап нәшриятының баш мөхәррире Ленар Шәех. Рус телендәге басманы төзүчеләрнең тагын берсе – Әлфия Шәйдуллина. Татар теленнән шигырьләрне тәрҗемә итүче – Рауза Хуҗахмәтова.

Ике телдәге җыентык та – бер-берсенә көзгедәге сыман чагылышы. Татар шигъриятенең рус теленә тәрҗемәдә шулай тулыканлы тәкъдим ителеше – ул зур һәм четерекле хезмәт, моңа, әлбәттә, «афәрин» диярге кирәк.

Җыентыкның буеннан-буена без Гамил Афзал поэзиясенең төрле кырлары белән танышабыз: аны лирик-фәлсәфи шагыйрь буларак та, иҗтимагый-трибун, юмор-сарказм тарафдары буларак та ачабыз. Болар бер-берсенә каршы килми, ә бик тә табигый рәвештә кушылып, үрелеп китә, иҗади бөтенлекне тәшкил итә.

Бу төр җыентыкның төп вазыйфасы – шагыйрь иҗатын мөмкин кадәр тулыканлы итеп күрсәтү, ачып салу, дип фаразлыйм. Бу җәһәттән ул, чыннан да, ихтирам уята, безнең алга әдипнең дөньясын шактый киң итеп, иркен итеп, колачында китереп бастыра.

Көн үтә, яктыра-кичегә,
Чәчәктәй гомерләр кечкенә.
Таралсын хәвефле болытлар,
Якты көн карасын кешегә.

Менә ул ап-ак-ак биләүдә,
Менә ул таякта – тәрәүдә…
Ике кат яшәмәс берәү дә,
Чәчәкләр бирегез кешегә.

Җыентыкларга тупланган әсәрләр арасында бик тә таныш шигырьләр белән беррәттән, үтә дә ягымлы, моңарчы күз уңыннан төшебрәк кала килгән шигырьләр дә очрый – алары китап сөючеләр өчен үзе бер бүләк. Мин андыйларын аеруча җылылык тойгысы белән, игътибарымны кат-кат юнәлтеп, барлап укыдым. Көтелгән иҗатның көтелмәгән якларын ачу ләззәте – үзгә бер ләззәт чөнки.

Җыентык Гамил Афзалга 100 ел тулу уңае белән дөнья күргән.

ЛЕНА ШАГЫЙРЬҖАН
«НИ ДАУЛЫЙСЫҢ, ЙӨРӘК?»

Минем өчен Лена Шагыйрьҗанның җыентыклары арасында иң күркәме булып «Шагыйрьнең иман кодексы» дигән үз кереш сүзе белән бастырып чыгарган җыентыгы тора. Ул басмада шагыйрь иҗатын, китапларына таянып, сарайларга бүлеп чыккан иде: «Язгы сарай», «Җәйге сарай», «Көзге сарай», «Кышкы сарай».

Татарстан китап нәшриятында 2020 елда басылып чыккан җыентыкның төзүчесе – Илһам Ногманов. Китапны төзү принцибы башлыча шул ук булып калган: шагыйрьнең китаплары эзлеклелеге буенча бару һәм иң күркәм иҗат үрнәкләренә басым ясарга омтылу.

Аңлавымча, бу җыентык, шигырьләре һәм эрерәк тезмә әсәрләре урын алган китап буларак, Лена Шагыйрьҗан иҗатын яктырткан беренче том. Алга таба чәчмә жанрларга да урын биреләчәк. Болай иткән очракта, үзенә күрә әдип иҗатын җыеп, бергә төйнәп кую булачак – Лена апаның иҗаты моңа, әлбәттә, лаек. Укучы өчен ул зур бүләк булыр иде, дип уйлыйм.

Шәхсән үзем тагын китапларда шәрехләр, интертекстуаль кыр урын алуын да теләр идем. Нигездә, академик басмаларга, сайланма җыентыкларга хас мондый якын килү бүгенге көн укучысына иҗатчыны әйләндереп алган әдәби мохит турында күбрәк мәгълүмат бирер, кызыксындыра алыр иде шикелле. Мөгаллимнәр, студентлар өчен дә кирәк дип беләм мондый мәгълүматны.

Мин шигырьдә калам!
Шигырь – минем
балам.
Шигырь – минем
дәвам ул.
Бу тормышның аягыңнан егар
агуына каршы дәва ул...
Шигырь илен ташлап китә күпләр:
Берсе – бу ил тар, ди, кысан, ди...
Берсе арган,
берсе парсыз калган.
Ялгызлыкка күпләр чыдамый...
Шигырь – Аллаң бит ул җаныңдагы!
Ятим калсаң, хәтта –
анаң да...
Мин шигырьдә калам –
Аллам да ул,
үзем дә ул,
газиз балам да!

ЯКУТ ШИГЪРИЯТЕ АНТОЛОГИЯСЕ

«Төрки әдәбият» сериясендә дөнья күргән бишенче китапта классик һәм хәзерге заман якут, ягъни саха шагыйрьләренең шигырьләре татар телендә тәрҗемәдә тәкъдим ителгән. Бу серия Татарстан китап нәшриятының соңгы еллардагы уңышлы проектларының берсе, дияр идем. Беренчедән, танып-белү: без кайчандыр совет иле буйлап таралып яшәп яткан шагыйрьләрне рус теленә тәрҗемәләрдә азмы-күпме укып, күзаллап үскән булсак, бүгенге интернет-киңлекләр ачык бер заманда кайда кемнең барлыгын белмибез, ваемламыйбыз. Икенчедән, тәҗрибә: кем генә ничек кенә димәсен, тәрҗемә шагыйрь өчен үзе бер олы мәктәп ул, аның аша без дә үзебезне баетабыз, әдәбиятлар арасында да багланышлар барлыкка килә. Өченчедән, караш киңлеге: без үзебезнең басу-кырларыбызны киңәйтәбез, ызаннардан атлап чыгып, башка дөнья барлыгын күрәбез. Олы бер Контекстта яшәвебезне тоемлыйбыз.

Әлеге җыентыкны әзерләгән тәрҗемәләр арасында миңа да катнашу бәхете тәтеде. Һәм мин үземнең өлешемә тигән авторларның иҗатын бик тә якын иттем, шактый күп әдәбият актардым, анда яшәүче халыкның риваятьләрен, җирлеген, тормыш-көнкүрешен өйрәндем. Бер генә үкенеч калды: кызганыч, турыдан-туры подстрочник яисә якут шагыйрьләренең үз шәрехләре белән эшләп булмады, ул очракта без авторларның иҗатына тагын да якыная алган булыр идек, минемчә. Оригиналга якын булыр өчен, тәрҗемәчегә тел, образларга үтеп кереп, үзен эретергә, ызан-кысаларыннан атлап чыгып, җиде кат тирен түгәргә туры килә бит...

Якут шигъриятенең классик үрнәкләреннән бүгенге заманга кадәр нинди юл узуын күзаллау гаять кызыклы. Ул чагыштырмача яшь әдәбият булып исәпләнә. Әлбәттә, ничек кенә яңа булмасын, тамырлары, рухи аһәңе белән ул барыбер дә борынгы эпоска барып тоташа, алай гына да түгел, ул эпик катламны, заманчалаштырып, яңарта, шуның аша үзенең Үткәне белән Бүгенгесен бөр төенгә төйни. Бигрәк тә урта буын белән бүгенге заманның яшьрәк иҗатчылары арасында сизелә борынгылыкны модернлаштыруга сусау күренеше. Хәер, милли әдәбиятларда мин моны барыбызга да хас күренеш, глобализация шартларында үзебезне сакларга омтылуның бер билгесе, дияр идем.

«Чуум-пу!» –
ике болан сөзешкәндәй,
галәм белән галәм бәрелешкән,
һәм чәчрәгән меңәр йолдыз-очкын! –
мәңгелекнең кайтавазы булып вәхи төшкән:
«Чуум-пу!»
Шулай иң бөек сер туган –
тынычлык.
Шулвакытта
Яратучы (чындыр бу):
«Яхшы-ы, – дип җиңел көрсенгән, –
Чуум-пу...»

(Рүзәл Мөхәммәтшин тәрҗемәсе)

Серле дә, кабатланмас та төрки кардәшләр иҗатын татар теленә тәрҗемә итүдә бер төркем шагыйрьләр катнашкан: Ркаил Зәйдулла, Галимҗан Гыйльманов, Рафис Корбан, Ленар Шәех, Фирүзә Җамалетдинова, Рүзәл Мөхәммәтшин, Луиза Янсуар, Лилия Гыйбадуллина, Илһам Ногман, Гөлүсә Батталова, Рифат Сәлах, Фәнил Гыйләҗев.

Китапның төзүчесе – Гавриил Андросов. Идея авторлары – Татарстанның халык шагыйре Ркаил Зәйдулла һәм Якутиянең халык шагыйре Наталья Харлампова.

Форматы буенча бәләкәй генә бу җыентык бүләк-китап рәвешендә әзерләнгән.

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

70 нче елларда совет Татариясе **НИЧЕК** яшәгән

80 нче еллар буыны **НӘРСӘләрне** хәтерли

90 нчы еллар буыны **НИНДИ** җиңүләр яулаган

Яңа меңъеллык Татарстанда **НИЧЕК** башланып китә

Казан **НИЧЕК** итеп спорт башкаласына әйләнә

ТАССР 100 ЛЕТ ЕЛ

БУЫННАР

«Татарстан» журналының махсус проекты

Май аенда Татарстан Республикасына 100 ел тулды. Түгәрәк тә, әһәмиятле дә юбилей: гасыр гына түгел, ә тарихның бер дәвере дә! 2020 елның декабрендә шулай ук 100 еллыгын бәйрәм итәчәк «Татарстан» журналы уртак юбилей уңаеннан «Буыннар» дигән проект әзерләде – анда без Татарстаныбызның олы тарихын язган кешеләр турында сөйләдек.

Май санында без республиканы үз куллары белән төзегән, ачлык, караклык һәм талауларга каршы көрәшкән, коллективлаштыруда, сала-калаларны электр уты белән яктыртуда катнашкан 20 нче еллар буыны, искиткеч энтузиазм һәм коточкыч репрессияләр чорында яшәргә туры килгән 30 нчы еллар буыны, Бөек Ватан сугышында катнашып, аннан җиңүче булып чыккан 40 нчы еллар буыны, сугыш җимергән шәһәрләрне торгызып, республиканың нефть сәнәгатен күтәргән 50 еллар буыны, космосны буйсындырган 60 нчы еллар буыны турында яздык.

Бүген бәянебезне дәвам итәбез...

Сүзебез илебез тарихына «торгынлык» чоры дип кереп калган 70 нче елларда яшәгән, эшләгән, иҗат иткәннәр, үзләре исә бу торгынлыкны сизмәгәннәр турында...

Күбебезнең бала чагы, яшьлеге туры килгән 80 нче еллар буыны турында...

«Давыллы» 90 нчы елларны исәнимин үтә алган, авырлыкларны җиңә алган көчле буын турында...

Татарстанга дөньякүләм спорт даны бүләк иткән, төбәгебезне туристлар өчен ачкан һәм җиһанның теләсә кайсы кыйтгасында танылырлык итә алган 2000 нче еллар буыны турында...

1970 нче еллар

БУЫННАР

ТОРГЫНЛЫКНЫ СИЗМӘГӘН «ТОРГЫНЛЫК» БУЫНЫ

70 нче еллар буыны – беренче миллиард тонна Татарстан нефтен табучылар, Түбән Камада беренче шиннарны һәм Яр Чаллыда беренче «КАМАЗ» авыр йөк машиналарын чыгаручылар, беренче Казан электричкасын юлга озатучылар һәм Түбән Кама ГЭСының беренче гидроагрегатын эшләтеп җибәрүчеләр, «Майский» теплица комбинатында беренче кыяр-помидор уңышын җыеп алучылар һәм беренче Ми-14 вертолёт-амфибиясен җитештерүчеләр. Менә шундый торгынлыкны сизмәгән дә «торгынлык» буыны...

70 нче елларда совет Татариясе ничек яшәгән?* ТАССР башкаласында кунакханәләрне һәм җәяүлеләр өчен җир асты кичүләрен кем төзегән? Ми-14 вертолет-амфибияләре кайда җыелган?

ХРОНОГРАФ

1970

- Татарстанда нефть табу күләме бер елга 100 миллион тоннага җитте. Бу нефть табуның илдәге иң югары күрсәткече. Ул 1976 елга кадәр сакланачак
- Шагыйрь Сибгат Хәкимгә В.И.Ленин турындагы шигырьләре һәм поэмалары өчен РСФСР Дәүләт премиясе тапшырылды
- Казанда «Татарстан» кунакханәсе ачылды
- Куйбышев мәйданында башкаладагы беренче җир асты кичүе барлыкка килде
- Казан киностудиясе «Татария. Год 1970-й» дигән беренче киң форматлы документаль фильм төшерде

1971

- Татарстанда нефтьнең беренче миллиард тоннасы табылды
- Казанда ТЭЦ-3 нең беренче чираты сафка бастырылды. Станцияне СССРның Европа өлешендәге бердәм энергосистемасына ялгадылар

1972

- Казан тимер юл вокзалыннан беренче электр поезды юлга чыкты

1973

- Түбән Кама Шин заводы беренче продукциясен чыгарды
- Казан вертолёт заводында Ми-14 вертолёт-амфибияләрен җыя башладылар

*70нче еллар буыны турында тулырак – журналыбызның 2020 елның февраль санында

Әлмәттән Яр Чаллыга автозавод төзелешенә килгән комсомол-яшьләр төзүчеләр бригадасы. 1970 ел.

Фото ТР Милли музееннан алынды

1974

- Яшел Үзән районының «Майский» теплица комбинатында помидор һәм кыярларның беренче уңышы җыелды

1975

- Татарстанда нефть табуның максималь дәрәҗәсенә ирешелде: аның күләме 103,7 миллион тоннага җитте

1976

- КАМАЗның төп конвейерыннан беренче авыр йөк автомобиле төште

1977

- Татарстан башкаласында Яшьләр үзәге ачылды
- Сара Садыйковага ТАССРның халык артисткасы исеме бирелде

1978

- КДУның фәнни-тикшеренү химия институты директоры Борис Арбузовка һәм СССР ФА әгъза-корреспонденты, СССР ФАның Казан филиалы – Органик һәм физик химия институты директоры Аркадий Пудовикка Фән һәм техника өлкәсендә Ленин премиясе тапшырылды

1979

- Казанда миллионынчы кеше туды
- «Казан-2» аэропорты – Халыкара «Казан» аэропорты ачылды
- Г.Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театрында «Әлдермештән Әлмәндәр» спектаклен куючылар – пьеса авторы Туфан Миңнуллинга, баш рольне башкарган Шәүкәт Биктимеровка, режиссёр Марсель Сәлимҗановка театр сәнгате өлкәсендә К.Станиславский исемендәге РСФСР премиясе тапшырылды
- «Вечерняя Казань» газетасының беренче саны чыкты
- Казан дәүләт университеты Ленин ордены белән бүләкләнде
- Түбән Кама ГЭСының беренче гидроагрегаты сафка бастырылды, сусаклагычның тирәнлеге 62 метрга җитте. Чулман һәм аның кушылдыклары, Иж елгасы үзәнлекләрендә 78 мең гектар мәйдандагы җирләр су астында калды. Сусаклагыч өчен Татарстан (91,4 мең гектар), Башкортостан, Удмуртия, Пермь өлкәсе территорияләреннән 173 мең гектар җир алынды

1970 нче еллар

ТАССРДА ТУГАННАР

Композитор Давид Тухманов 1972 елда Владимир Харитонов шигыренә музыка иҗат итә һәм... «Мой адрес – Советский Союз» дигән бу җыр совет чорының рәсми рәвештә танылмаган гимнына әверелә.

«СССРда туганнар», димәк, «Татарстанда туганнар» да, аны яттан белә һәм элеккечә үк дәрт вә энтузиазм белән җырлый. Әлеге җыр юллары соңрак «торгынлык чоры» дигән сәяси клишега әвереләчәк вакытның фотографияләренә тәңгәл килеп, аларны тулыландырып тора. Бу чорда яшәгән һәм анда яшәгәннәрен әле белмәгән кешеләр шул «торгынлык тормышларын» якты эшләре, кыю казанышлары һәм җырдагы юллар белән билгеләгән:

Я там, где ребята толковые,
Я там, где плакаты «Вперед!»,
Где песни рабочие, новые,
Страна трудовая поёт.

Карагыз да, үзебезнең хезмәт батырлыкларын, шат йөзләребезне, безнең данлы, әмма һич тә торгынлыкта булмаган үткәннәребезне искә төшерегез.

Заботится сердце, сердце волнуется,
Почтовый пакуется груз…
Мой адрес не дом и не улица,
Мой адрес – Советский Союз!

Фото: Е. Фрумин

Казан. Муса Җәлил һәйкәле. 1970 ел.

«Түбән Кама Нефтехим» җитештерү берләшмәсе. 1970 ел.

Елхово АТХ хезмәткәрләре «Нефтьче» колхозына бәрәңге җыюда булышалар. 1970 ел.

«Камгэсэнергострой» берләшмәсе хезмәткәрләре. 1970 ел.

Фотоларны ТР Милли музее тәкъдим итте

Чистай халык театры агитбригадасы авылларда чыгышлар ясап йөри. 1971 ел.

Пионерлар парады. 1972 ел.

1970 елның 1 мае. «Комсомолец Татарии» журналистлары газетаның беренче май санын тараталар. Уртада – баш мөхәррир Евгений Ухов.



Камал театры сәхнәсендә – «Мылтыклы кеше» спектакле. 1976 ел.

Камил Исхаков тантаналы пленумда чыгыш ясый. 1978 елның октябре.

Дәүләт музее фәнни хезмәткәре авыл кешеләренә лекция укый. 1978 елның июне.

Шагыйрь Сибгат Хәким һәм язучы Рафаэль Мостафин (1991–1998 елларда «Татарстан» журналының баш мөхәррире). 1979 ел.

ХӘРБИ ЧОР ИЛЧЕСЕ

1979 елның 22 ноябре. Әфганстанда СССРның яңа илчесе Фикрәт Табиев ӘДР президенты Хафизулла Әмингә ышаныч грамотасы тапшыра. Советлар Союзының «дусты» бәхетле: Мәскәү, Табиевка кадәр булган илчене чакыртып алып, аныңча эшләде. Әмма Әмин дә бу вакыйгалардан соң бер ай чамасы гына яшәп кала. Фикрәт Табиевка Әфганстанда җиде ел илче булып торырга һәм әфган җирендә барган күп кенә фаҗигале вакыйгаларның шаһиты, турыдан-туры катнашучысы булырга туры килә...

Автор:
Әскәр Сабиров

Сугыш барган илдә илче булып эшләү ничек булган соң? Кайчак яу кырында ут астында йөргән сугышчыныкыннан да болайрактыр. Сугышта барысы да аңлаешлы: алда – дошман, янәшәңдә – үзеңнекеләр. Ә дипломатия кырында? Безнекеләр Әминнең сараен штурм белән алганнан соң, «Правда» газетасында халык өчен версия пәйда була: «Ачулы халык ташкыны Әминне, иярченнәре белән бергә, гадел халык суды каршына бастырды һәм җәзасын бирде...» Олы сәясәттә еш кына беренче карашка бик гади тоелган карарлар артында да күпбаскычлы комбинацияләр тора.

Фикрәт Табиевны Әфганстанга илче итеп билгеләү дә шул комбинацияләрнең бер өлеше булгандыр, мөгаен. Чыннан да дипломатларны алыштыру Советлар Союзында Әфганстан президенты Хафизулла Әминнең шәхси үтенечен исәпкә алгандай итеп эшләнә. Берничә ай эчендә Әмин Мәскәүгә совет илчесе Александр Пузанов өстеннән җиде шикаять юлларга өлгерә. Әфганстан президенты совет илчесен оппозициягә хәерхаһлылыкта гаепли, илче революция эшенә һәр яктан зыян китерә, дип ышандырырга тырыша.

Әфганлылар белән очрашуда. Уртада: Фикрәт Табиев һәм Әфганстан Министрлар советы рәисе Кештбанд.

Чынлыкта шактый катлаулы хәлдә калган Хафизуллага Иске мәйданда беркем дә ярдәм итәргә ашыкмый. Элеккеге илченең эшчәнлеге нәтиҗәле булмауны танып һәм аны кире илгә кайтарып, Мәскәү, һичшиксез, әфган президентының уяулыгын киметергә ниятли.

КАБУЛГА – ДАВЫЛ АЛДЫННАН

Сугыш исе килгән, ил эчендә әйдәп баручы партияләр һәм төркемнәр арасында каршылыклар сүз белән генә чикләнмисе мәгълүм булган дәүләтләргә (искә төшерик, 1979 нчы елның сентябрендә Әмин, хакимияткә килү өчен, Нур Мөхәммәд Таракины юкка чыгара) илче булып китәргә атлыгып торучыларны профессионал дипломатлар арасында табу шактый четерекле эш була, әлбәттә. Ул чакта да тәвәккәллек таләп ителгән әлеге вазыйфадан берничә кандидат баш тартканнан соң, Татарстан өлкә комитетының беренче секретаре булып эшләгән Фикрәт Табиев кандидатурасына тукталалар.

Әфганстанга алдынгы автоном республиканың алдынгы җитәкчесен илче итеп җибәрүне КПССның төп идеологы Михаил Суслов тәкъдим итә. Дөрес, Әфганстан партия-хуҗалык идарәсе буенча тупланган тәҗрибәне шунда ук дипломатиягә алыштыру җиңел булган илләр исемлегенә керми. Дипломатик тәҗрибә Табиевта бөтенләй булмый. Әмма КПСС ҮКнда, ихтимал, тиздән бу илдә дипломат теленең беренче рольләр биләмәячәген белгәннәрдер. Икенче яктан караганда, провинциядән килгән дипломатның шиксез өстенлекләре бар. Табиев татар, мөселман – димәк, аңа җирле җитәкчелек, халык белән уртак тел табу җиңелрәк булачак.

Фикрәт Табиев өчен партия дисциплинасы – буш сүзләр генә түгел. Карьера амбицияләре дә тиешле югарылыкта. Нәтиҗә бер: мондый тәкъдимнән баш тартмыйлар. Кремльдә, күрәсең, нәкъ менә шуңа исәп тотканнардыр.

Соңрак Фикрәт Әхмәтҗанович болай дип искә ала: «Без Суслов белән Леонид Ильич Брежнев янына кердек.

– Менә, иптәш Табиев ризалыгын бирде, – дип хәбәр итте Михаил Андреевич.

– Бик яхшы! – дип елмайды Леонид Ильич. – Фикрәттә мин беркайчан да шикләнмәдем».

Яңа вазыйфага керешер өчен Табиевның күпме вакыты була соң? Алдагы вакыйгалар күрсәткәнчә, бөтенләй булмый. Яңа илче үзенең Кабулдагы резиденциясендә чемоданнарын бушатканга бер атна да үтәргә өлгерми, КПСС ҮК Политбюросы ул вакытта Әфганстан хакименә туры мәгънәсендә үтергеч характеристика бирелгән документ кабул итә. Документта болай диелә: Әмин «...хакимлек итүне

СССР илчесе Фикрәт Табиев әфганлылар арасында.

ярата, шәфкатьсезлегә һәм мәкерлелеге белән аерылып тора, Әфганстан халык-демократик партиясенең оешканлык ягыннан йомшаклыгы һәм идея ягыннан көчсез булуы шартларында, үзенең шәхси хакимиятен саклап калу өчен, аның сәяси режим юнәлешен үзгәртергә омтылуы куркынычын сызып ташларга ярамый. СССР белән мөнәсәбәтләрдә Әминнең ихлас булмавы һәм икейөзлелеге торган саен ныграк ачыла бара».

Әмин сараен штурмлауга бер айдан да әзрәк вакыт калган була.

ДЕГЕТ МИЧКӘСЕНДӘГЕ ДИПЛОМАТИЯ

Хафизулла Әмин яңа совет илчесенең үзенә ошавын яшерә алмый. Кабулга иялэшергә дә өлгерми, ул әфган президентына күптәннән көтелгән хәбәрне җиткерә: СССРда аның Әфганстанга совет гаскәрләренең чикле контингентын кертүне сораган үтенече канәгатьләндерелә. Үзе Таракины юкка чыгарган кебек, оппозициянең дә шулай ук эшләвеннән курыккан Әмин моңа кадәр Мәскәүгә бертуктаусыз мондый адымның кирәклеген раслый торган үтенечләр юллый һәм әлегә кадәр нәтиҗәсе булмый. Элеккеге илче вакытында, Хафизулла фикере буенча, барысы да матур сүзләргә генә кайтып калган, ә яңасы килгәч, яхшы якка үзгәрешләр күзгә күренеп тора. Ләкин вәгъдә ителгән гаскәрләрне кертү кайчан башланыр соң? Фикрәт Табиев бу мәсьәләдә дә төгәл. Ул Әфганстан президентына гаскәрләрне кертү 25 декабрьдә үк башланырга мөмкин, дип хәбәр итә. Әмин шатлыгын яшерә алмый: аның хыялы тормышка аша кебек.

Ә Мәскәүнең, үз чиратында, шулай ук планнары чынга аша башлый. Кабулга яңа илченең килүе Әфганстан президентының уяулыгын киметте – бу күзгә күренеп тора. Фикрәт Табиев белән Хафизулла Әмин беренче көннәрдән үк бер-берсе белән нормаль мөнәсәбәтләр урнаштыра. Алай гына да түгел, күпмедер вакыт үткәннән соң, әфган президенты Табиевка чиксез ышаныч күрсәтә башлый. Моңа бер очрак ярдәм итә. Бервакыт төшке аштан соң Әмин үзен кинәт кенә начар хис итә башлый. Үзен агулаганнар дип курыккан Әмин, коты очып, совет илчесенә хәбәр итеп өлгерә. Табиев тиз генә үзенең табибын президент янына җибәрә. Табиб, чыннан да, җитди агулануны раслый һәм Хафизулланың гомерен саклап кала...

Соңрак ачыклана: әфган президентын агулауны махсус хезмәтләр оештыра, гаять яшерен рәвештә әзерләнгән әлеге операция, аның детальләре турында совет илчесенә хәбәр итеп тормыйлар. Әгәр белгән булса, ихтимал, безнең гаскәрләргә гомерләрен куркыныч астына куеп, президент сараен штурмларга кирәкмәс тә булган булыр иде...

Әмма әлегә сәясәтчеләр, дипломатлар, киңәшчеләр Политбюро документында язылган күрсәтмәләрне тормышка ашыра: «Югарыда аталганнарны исәпкә алып һәм таләп ителгәннәрдән чыгып, Әфганстанда контрреволюциянең җиңүен яисә Әминнең көнбатышка сәяси юнәлеш алуын булдырмас өчен, түбәндәге линия буенча эшләү максатка ярашлы дип табыла: Әмин белән, аңа ышанмавыбызны һәм аның белән эш йөртергә теләмәвебезне аңларга сәбәпләр калдырмаслык итеп, актив хезмәттәшлекне дәвам итәргә. СССРга карата дустанә мөнәсәбәт күрсәткән һәм «Апрель революциясе» язмышы өчен борчылган затлар белән әңгәмәләр вакытында хәзерге көндә Әфганстанда барган хәлләрне хуплыйбыз дигән тәэсир калдырмаслык итеп сөйләшергә һәм мондый затларны читкә этәрмәскә...»

ШӘҺӘРДӘ НИНДИ АТЫШЛАР БАРА?

Әмин сараен штурмлау турында Фикрәт Табиев бәрелешнең иң кызган вакытында гына белә, дип сөйлиләр: әфган лидерын юкка чыгару буенча оештырылган операциянең яшеренлеге моңарчы күрелмәгән дәрәҗәдә югары була. Операция белән җитәкчелек иткән Вадим Кирпиченко (СССР Дәүләт куркынычсызлык комитетында легаль булмаган разведка эшен алып барган суперяшерен «С» идарәсе белән җитәкчелек итә) болай дип искә ала: «Беренче ату тавышлары ишетелүгә һәм илчелек территориясенә яралыларны ташый башлауга, илче Фикрәт Әхмәтҗанович Табиев дулый башлады.

Илченең хатыны Динә Мөхәммәтовна Табиева Әфганстан дин эшлекләләре арасында.

Әфганстан президенты Нәҗибулла СССР илчесе Фикрәт Табиевта кунакта.

Миңа шалтыратты һәм усал тавыш белән шәһәрдә нәрсә барганлыгын аңлатуны таләп итте. Мин сугыш бара, хакимият «парчамистларга» көчә һәм сөйләшеп торырга вакытым юк, дидем. Вазгыять турында тулырак иртән хәбәр итәрбез, дип кистердем...»

Күп нәрсә яшеренлек пәрдәсе белән өретелгән, бер операциянең детальләрен – КГБ гына, икенчесенекен хәрби киңәшчеләр генә белгән шартларда илче үзен үз вазыйфаларын башкару ни дәрәҗәдә катлаулы булуын күз алдына китереп була. Әлбәттә, сугыш барган, әмма шул ук вакытта меңләгән ватандашың – укытучылар, төзүчеләр, табиблар һ.б.лар эшләгән илдә дипломатия кагыйдәләрен саклап эш итү – гаять катлаулы.

Әйтергә кирәк, Фикрәт Табиевның сайлау мөмкинлеге була. Иң җиңеле – үз резиденциясендә ышанычлы сак астында утырып тору, ил буенча хәрәкәт итүләрне минимумга калдыру. Ләкин илче бөтенләй башка юлны сайлый. Провинцияләр буйлап еш йөри. Хакимлек итүче партия һәм оппозиция вәкилләре, руханилар, хәтта каршы торучы якларның кыр командирлары белән дә очраша. Һәм соңрак үзенең истәлекләрендә сөйләгәнчә, һәр әфган кешесенә гади генә фикерне җиткерергә тырыша: Советлар Союзы әфган халкына яманлык теләми, яңа тормыш төзергә булыша һәм булышачак. Гаскәрләр ни өчен кирәк? Алар реакцион көчләрне тыеп тору өчен кирәк, һич кенә дә бүтән максатларда түгел...

Совет илчесе китергән дәлилләр кайвакыт чыннан да тәэсирле була. Саланг тау сырты аша үтә торган юл, Гераттан Кандагарга кадәрге автотрасса, Әфганстанга 250 мең гектар сугарылган җирләрне кире кайтарган мелиорация эшләре, гидроэлектростанцияләр, хастаханәләр – болар барысы да совет белгечләре катнашында башкарылган эшләр. Гади халык моны белә һәм күрә. Шулай ук башка бер генә илнең дә Әфганстанда бер генә нәрсә дә төземәгәнен дә яхшы аңлый...

ГОРБАЧЕВКА ХАТ

Шулай да рухи лидерлар һәм офицерлар арасында совет илчесе казанган ихтирам аңа иминлекне гарантияли алмый. Көнбатышка йөз тоткан көчләргә Табиевның гамәлләре, мөгаен, мөҗәхитләргә каршы армия тарафыннан кылынган операцияләрдән дә кимрәк зыян китермәгәндер. Табигый ки, мондый вазгыятьтә уңайсыз илчедән котылу юлын эзләгәннәр дә җитәрлек була.

– Илчелек капкасыннан чыгып киткәндә мин беркайчан да кире исән кайтукайтмавымны белми идем, – дип искә төшерә Фикрәт Әхмәтҗанович күп еллар үткәннән соң. – Кабулда адым саен үлем сагалап тора. Хәтта хатыным белән Михаил Горбачевка хат та яздык: безне үтерсәләр, балаларыбызга күз-колак булырга, ярдәмнән ташламаска үтенеп. Хат илчелектәге сейфка яшерелгән иде, бәхеткә, кирәге чыкмады.

Гаҗәп, шул ук вакытта Табиев сугыш барган Әфганстан буенча сәфәрләре яисә сөйләшүләр барышында килеп туган нинди дер гадәттән тыш хәлләр турында беркайчан да сөйләми. Киресенчә, гел шуңа басым ясый: «совет илчесе» исеме үзенә күрә сак грамотасы – илчегә кагылмыйлар. Күрәсең, бу очракта «проблемалы» илдә экстерн рәвешендә үзләштерелгән профессиональ дипломатия алымнары сизеләдер. Табиев четерекле якларны дипломатларча җайлап җибәрергә, начар яклар турында күп сөйләмәскә тырышкандыр.

Шул ук вакытта 1980 елдан 1981 елның августына кадәр илче сагына кергән Александр Лисичкин (Кавказ арьягы чиге округы офицерларыннан һәм прапорщикларыннан торган махсус билгеләнештәге подразделениедә хезмәт иткән) төрле хәлләр булуы турында искә ала:

СССР илчесе Фикрәт Табиев кунакларны кабул итә.

Динә Табиева, Фикрәт Әхмәтҗанович һәм Әфганстан җитәкчесе Бабрак Кармаль.

Иң югары дәрәҗәдәге очрашу.

– Без аның тормышын сакларга, иминлеген тәэмин итәргә тиеш идек. Кая да булса чыгар алдыннан маршрутны тикшерәбез, чөнки минага, снайпер пулясына яисә мөҗәһитләр капкынына эләгү мөмкинлеге зур. Илче машинасына берничә мәртәбә аттылар да. Провинциягә барырга туры килгәндә, икенче машина бирәләр – кораллы өстәмә сак өчен. Бервакыт «кызган» әфганлылар төркеменә тап булдык – нindидер җыен бара иде. Алар илче утырган «Мерседес»ны уратып алдылар, мин дә шул машинада идем, автомобильне әйләндереп каплар өчен, селкетә башладылар. Үзләре: «Аллаһу әкбәр!» дип кычкыра. Һавага берничә мәртәбә атарга, кисәтергә туры килде. Автомат тавышын ишеткәч, читкә таралыштылар.

Ул вакытта Әфганстанда булган барлык ватандашларыбызның – дипломатмы алар, эшчеме, хәрбиләрме яисә гражданлык белгечләреме – барысының да тормышына куркыныч яный иде. Әфганстандагы бөтен киңәшчеләргә, хәтта укытучы белән табибларга да корал бирелүе очраклы хәл түгел, өстәвенә, алар сак белән дә тәэмин ителәләр иде. Шулай ук совет илчесенә карата Әфганстандагы кайбер террористик төркемнәр каршына төгәл максат куелуы да билгеле факт: Табиевны әсирлеккә алырга һәм совет хөкүмәтеннән аның гомере өчен акча сорарга. Дипломатны һәм аның позициясен хөрмәт иткән мөҗәһитләрнең башлыклары әлеге планнарны тормышка ашырырга комачаулаган, дип тә сөйлиләр.

Әфганстан Демократик Республикасында эшләү дәверендә Фикрәт Табиев 30 килограммга ябыга.

«КАТГЫЙ ЯШЕРЕН» ГРИФЫ

Табиев көн саен диярлек тормышын куркыныч астына куя. Шул ук вакытта ватандашларының гомерләрен саклап калу өчен булдыра алганның барысын да кыла. Әфганстанда төзүче булып эшләгән Виталий Гафаров бу илдә булганда үзендә һәрвакыт куркыныч тойгысы яшәвен искә ала. Эш шуңа җитә ки, ул илчелеккә киңәш сорап бара.

– Табиев минем Казаннан икәнемне белгәч, болай диде: «Улым, син нәрсә, үзебездә эш тапмадыңмы? Үлеп калганчы, кайтып кит моннан. Бу безнең җир түгел!» Аның киңәшен тыңламаган булсам, язмышым ничек булыр иде, гомумән исән булыр идемме икән, белмим...

Иосиф Кобзон белән булган очракны да искә алыйк. Табиевның ватандашларына карата кайгыртучанлыгы концерт белән килгән җырчының чыгышын чак кына өзми. СССР илчесе Әфганстанга килергә тәвәккәлләгән артистка сугышчылар каршында чыгыш ясарга рөхсәт итми.

«Иптәшләр, бу ничек була соң инде? – дип, ризасызлыгын белдерә ул чакта Иосиф Давидович. – Мин монда артистлар төркеме белән килдем, без үзебезнең сугышчы-интернационалистлар каршында чыгыш ясарга, аларның сугышчан рухын күтәрергә әзер. Әйдәгез, эшлик инде...» Фикрәт Әхмәтҗанович каршы төшә: «ҮК Политбюросы рөхсәтеннән башка ярамый. Куркыныч! Ә сезне үтерсәләр, Иосиф? Без халыкка ни дип әйтербез?»

Ул вакытта Кобзонның абруе үз ролен үти. Табиев ризалыгын бирә, әмма хәрбиләргә моңарчы күрелмәгән дәрәҗәдә сак күрсәтелүен таләп иткән күрсәтмә бирә.

Дипломатия хезмәтенең катгый таләпләре, кагыйдә буларак, иң мөһим эпизодларны кадрлар артында калдырырга мәҗбүр итә. Дипломатик кабул итү кичәләре, матбугат конференцияләре, имзаланган документлар – болар барысы да күз алдында. Куркыныч һәм көтелмәгән каршылыклар тулы көндәлек эш – анысы турында азлар гына белә. Әфганстанда СССР илчесе эшчәнлегенең күп кенә сәхифәләре бүгенге көнгә кадәр «катгый яшерен» грифы белән саклана.

Хәер, аның белән бергә, иңне-иңгә куеп эшләгән кешеләрнең хәтере, истәлекләре калган. Әфганстанда Табиев алып барган дипломатлык эшенә иң кыска һәм тирән бәяне, мөгаен, күптән түгел генә бакыйлыкка күчкән милләттәшебез, Россия Хәрби фәннәр академиясенең элеккеге президенты Мәхмүт Гәрәев биргәндер: «Фикрәт Әхмәтҗановичның Әфганстанда СССРның Гадәттән тыш һәм Тулы вәкаләтле илче буларак эшчәнлеге турында болай дип әйтә алам: ул вакытта Әфганстанда вазгыять бик авыр иде, төрле катлаулы хәлләр туа килде, ләкин Табиев һәрвакытта да алардан чыгу җаен таба алды».

Башка объектив критерийлар да бар: Фикрәт Табиев – бер ил җирендә башкарган хезмәте өчен ике орден алган СССРның бердәнбер илчесе. Ике Ленин ордены. Аның Әфганстандагы җиде еллык хезмәтенә дәүләт шундый бәя бирә.

Әлеге сугышта илебезнең чын югалтуларын белгән Фикрәт Табиев исә соңгы көннәренә кадәр Әфганстанны үзенең җан ярасы дип атый.

1970 нче еллар

1976

ЯҢАЛЫКЛАР

1972

0000001 НОМЕРЛЫ «КАМАЗ»НЫ БАШКОРТОСТАНДА ЭЗЛӘП ТАБАЛАР

«Кабул ит, Ватан, беренче «КАМАЗ»-ны» – йөк машинасының бортына эшчеләр эре хәрефләр белән әнә шулай дип язып куйган. Ә машина үзе 1976 елның 16 февралендә Яр Чаллының төп конвейерыннан әзер булып килеп төшә.

Бу хәл КАМАЗ төзүчеләр өчен генә түгел, ә бөтен ил өчен дә олы вакыйгага әверелә. Советлар Союзы заманча куәтле йөк машинасына һәм автогигантка – дөньяда тиңе булмаган заводлар комплексына ия була. Предприятиенең беренче чиратка кабул итү актына 1976 елда кул куела, ә 1979 елның 10 июнендә КАМАЗда инде йөз меңенче йөк машинасын җитештереп чыгаралар. Автогигантның беренче карлыгачы – бортлы «КАМАЗ-5320» – бүгенгә кадәр менә дигән булып сакланган. Әлеге йөк машинасы Башкортостанда кулланылган, соңрак завод музее тарафыннан сатып алып торгызылган да, инде экспонат рәвешендә экспозициягә куелган. Хәзерге көндә ул музейның 0000001 нче номерлы кадерле экспонаты буларак билгеле.

Сүз уңаеннан:
1976 елда СССРда гаять популяр булган «Работница» журналы тышлыгын зәңгәр джинс куртка киеп алган, ә башына эре хәрефләр белән «КАМАЗ» дип язылган фирма кепкасы элгән елмаеп басып торучы кыз сурәте бизи. Автогигантның 50 еллыгы уңае белән фотосессияне янә кабатларга карар кылалар. 2019 ел моделе буларак КАМАЗ хезмәткәре Мария Сарычева сайлана. 1970 нче еллардагы КАМАЗның джинс спецовкасын җирле тарихи-туган якны өйрәнү музеенда табып алалар. Фирма кепкасын, бераз гына башкарак фасондагысын, КАМАЗ музеенда. Дөрес, төшергәндә инде башка фон кулланырга туры килә, чөнки хәзер конвеердан бөтенләй башка төрле, яңа заман йөк машиналары төшә. Шулай да бу гүзәл туташыбыз Марияга теге еллар КАМАЗының фирма билгеләрен чагылдырырга комачауламый.

БЕРЕНЧЕ КАЗАН ЭЛЕКТРИЧКАСЫ ПАССАЖИРЛАРЫН КАҺАРМАННАР КЕБЕК КАРШЫЛЫЙЛАР

1972 елның 1 февралендә Казан вокзалыннан беренче электропоезд кузгалып китә.

Озатучылар һәм каршы алучыларның шатлыгы эченә сыймый. Вакыйганың шаһитлары беренче электропоездны әллә ни ерак юлга озатмаса да, аны бөтен Казан белән озата. Күпләрнең күзләрендә яшь була. «Җаваплы партия хезмәткәрләре» һәм тормыш иптәше белән бергә тарихка кереп калган рейска әләгү бәхете Әнисә Зәки кызы Заһидуллинага да насыйп була. Аның истәлекләре буенча, Арчада – соңгы станциядә – электричка пассажирларын «сугыштан кайткан каһарманнар» кебек каршы алалар.

Әлеге шатлыклы вакыйганың репетициясе бер ай алдан башлана. 1 нче гыйнварда машинист Шәмиев яңа ЭР1-55 электропоездында Арча-Казан участогындагы так сандагы электрлаштырылган юлны сынап карый. Ә кирегә илтүче Казан-Арча бүленешле юлын ЭР1-58 электропоездында инде машинист Власов сыный.

Поездның төп «пассажиры» Ленин портреты һәм аның күрәзәчел сүзләре була: «Коммунизм ул – совет власте плюс бөтен илне электрофикацияләү!»

1976

70 НЧЕ ЕЛЛАР ДИСКОТЕКАСЫ: «КАЗАН ФЕНОМЕНЫ» БЕЛӘН ИСӘПЛӘШМИ БИЮЛӘР

1976 елның февралендә Казандагы иң романтик бию мәйданнарының берсе – Урицкий исемендәге Мәдәният йортында чираттагы бер кич коточкыч сугышу белән тәгәлләнә.

Аны ул чактагы «Тяп-ляп» дип аталган атаклы Казан төркеме гопниклары оештыра. Биегән һәм күңел ачкан публиканы, як-якка чөеп ташлап, гопниклар күз ачып йомганчы юкка да чыга. Килеп җиткән милиция хезмәткәрләре буш кул белән кала.

Ул чакта мондый хәлләр Казандагы бию урыннарында еш кабатлана, әмма, группировкалар булганга карап кына, яшьләр биюдән баш тартмый. Казан – яшьләр шәһәре, биредә һәрчак студентлар кайнап тора. Яшь һәм дәртле кан, әлбәттә, дискотекаларга әйди, гопниклардан курку гына баса алмый аның ялкынын. «Без, «Казан феномены» белән исәпләшми, рәхәтләнеп бии идек, – дип искә ала 1976 ел Казан студенты Светлана Корнеева. – Хәер, әле ул чакта гопникларны «Казан феномены» дип атамый да иделәр, бу атама соңрак пәйда булды. Без аларны бары тик хулиганнар буларак кына кабул итә идек.

1977

ДОШМАННЫҢ ТЕШЕ ҮТМӘСЛЕК «ПАРОЛЬ»



Казанда уйлап табылган «Үзебезнеке – Үзебезнеке түгел» гомумгаскәри радиолокацияле илне тану системасы менә инде дүрт дистә ел дәвамында илебезнең һава һәм диңгез юлларын саклауга хезмәт итә.

Һавадагы һәм судагы корабларданкайсы безнеке, кайсы безнеке түгел икәнлеген бер ялгышсыз билгели ала торган әлеге уникаль системаны булдыручыларның берсе – Илдус Мостюков. Ул 1928 елның 6 мартында Казанда туа, 334 нче номерлы НИИ да (хәзерге Казан Радиоэлектроника фәнни-тикшеренү институты) укый. 1962 елда ул инде әлеге институтны үзе җитәкли, институт исә илнең «Пароль» («Үзебезнеке – Үзебезнеке түгел») Бердәм гомумгаскәри радиолокацияле илне тану системасын булдыру буенча төп мәйдан итеп билгеләнә. Илдус Мостюков бер үк вакытта «Пароль»нең баш конструкторы вазыйфасына да алына. Проектны җитештерүгә 10 елдан артык вакыт таләп ителә, әмма, ахыр чиктә, ил НАТО җитештергән заманча аналоглы системалардан бер ягы белән дә калышмый торган уникаль продуктка ия була. 1977 елда кабул ителгән дәүләтнең гомумгаскәри радиолокацияле илне тану системасы Россия хәрби көчләре тарафыннан хәзер дә кулланыла. Аның уникальлеге нәрсәдә соң? Ә менә нәрсәдә: дошман кулына элементларның кайсы да булса эләккән очракта да, система расшифровкага бирелми, шулай ук аны яңадан программалаштырып та булмый.

Дәүләт каршына куйган махсус әһәмияткә ия бурычны лаеклы рәвештә үтәгәне өчен, СССР Югары Советы Президиумының «яшерен» Указы нигезендә, Илдус Шәйхелислам улы Мостюковка 1980 елның 2 июлендә Социалистик Хезмәт Герое исемен бирәләр.

1977

ВЫСОЦКИЙ ЯШЕЛ ҮЗӘНДӘ БЕР СУМГА ҖЫРЛЫЙ

«Әйдәгез, мин сезгә күбрәк җырлыйм, ә сез азрак алкышлагыз...» – Владимир Высоцкийның Казандагы бер концертында әйткән әлеге сүзләрен җанатарлары озак хәтерендә саклаячак. 1977 елның 12 октябреннән алып 18 октябренә кадәр бары тик Высоцкий концертлары белән генә яшәвен дә хәтереннән чыгармаячак алар, билгеле. Актер хәлдән тайганчы сәхнә тота: көнгә бишәр концерт. 10:00 да һәм 12:00 да – Яшьләр үзәгендә, 15:00 дә, 18:00 дә һәм 21:00 дә – Спорт сараенда. Әле бит планнан тыш чыгышлар күпме – КХТИда, Актерлар йортында, Яшел Үзәндәге «Родина» Мәдәният сараенда, Боровое Матюшинодагы Обком дачасында...

Әлеге коточкыч график теләсә кемне аяктан егар иде, әмма актерга махсус үз рецепты буенча пешерелгән чәй булыша. «Шестеро молодых» дигән вокаль-инструменталь ансамбль концертта «разогрев» ролен үти, алар искә алганча, чәйнең составы бик гади була: стаканның дүрттән бер өлеше – коньяк, калганы – каты кара чәй... Ләкин Высоцкийны суык тиюдән бу «дару» да саклап калмый: тамагы авырта башлый, гастрольләр куркыныч астында кала...

Яшьләр үзәгенең спортчыларны тәрбияли торган табибы Юрий Алашеевский ярдәм итә: авыруга чын дарулар белән физпроцедуралар билгели. Киткәндә, Высоцкий аңа үзенең фотографиясен язып бүләк итеп калдыра: «Юрага – игелек һәм уңышлар. В.Высоцкий».

Ә менә Яшел Үзәндәге «Родина»да көтелмәгән хәл килеп чыга. Анда Владимир Высоцкий нибары 5 җыр гына җырларга өлгерә, югыйсә Казандагы концертка соңга калачак. Тамашачы моңа риза булмый, билгеле, шау-шу куба. Зур акчалар түләделәр дә, вәгъдә ителгән Высоцкий урынына җирле ансамбльне тыңласыннар, имеш! Нииндидер ветеран, ачуыннан сүгенә-сүгенә, концертны ташлап фойега чыкса, машина килгәнен көткән Высоцкийның... үзе белән бәрелешә.

Картлач дипломат булып торуны кирәк тапмый, турысын кистереп сала: «Володя, билет өч сум тора иде, ә син нибары бер сумлык кына җырладың!» Высоцкий вәгъдә бирә: «Хәзер тагын ике сумлык җырлыйм!» һәм шунда, фойеда ук, аның өчен берничә җырын җырлый да.

РЕНАТ ИБРАҺИМОВ ҺӘМ «БЕЗНЕҢ ШӘҺӘР»

1979

Бу – татарның сандугачы Ренат Ибраһимов йолдызы калыккан ел. «Песня-78» Яңа ел тапшыруыннан соң, аның бәрхет баритонына бөтен ил гашыйк була. Хәер, казанлыларның үзләре өчен Ренат Ибраһимов инде ул чакта «ачыш» түгел – биш ел дәвамында җирле опера театрының солисты. Үз йолдызларыңа әллә ни исең китми бит ул, ә менә башкаланыкылар кызыктыра. Бәлки, шуңа да июль аенда Казан урамнарында җырлап камерага төшкән Ренат Ибраһимовны күргән казанлылар, авызларын ачып, өере белән ияреп йөрмәгәндер.

Хәер, бик кулай да: клипны төшерер өчен, Казанның нәкъ үзәгендә, урамнарны камап алып, машина ташкынын туктатырга туры килми. Ибраһимов Ленин урамы буйлап атлый, Казан университетының алып биналарына сокланып атлап бара, ә тирәсендәге шәһәрлеләр үз эшләре белән кайсы кая ашыга. Аларның бу импровизацияле концертка һич тә исләре китми. Әмма иң игътибарлылары шулай да күрә: җырчы үзе ишетелер-ишетелмәс кенә җырлый, ә менә «Мы любим наш с тобою старый город...» сүзләрен сузучы бәрхет баритон исә каяндыр динамиклардан агыла...

Советлар илендә «фанера»га башкару мөмкин булуы турында әле бик күпләр белми ул чакта. Дөрес, бу очракта халтура эшләгәннәр дип әйтеп тә булмый. Шәһәр буйлап атлап барган һәм микрофонсыз җырлаган җырчы белән клипны башкача сыйфатлы яңгыраштатөшереп булмас иде ләбаса. Концертларда Ренат Ибраһимов, әлбәттә, үзенә «фанера»га чыгыш ясауны беркайчан да рөхсәт итми.

...«Безнең шәһәр» җырына төшерелгән клип исә тарихта уникаль урынын яулый: бу клиплар әле гомумән төшерелмәгән чорда Казанда төшерелгән беренче клип була. Аны хәзер дә Интернеттан табып карарга мөмкин.

«Татарстан» журналының махсус проекты

1980 нче еллар

БУЫННАР

ДИСКО БУЫНЫ

80 нче еллар – күпләр өчен бик якын чор ул, чөнки без йә тумышыбыз, йә балачагыбыз һәм яшьлегебез белән 80 нче еллардан... Ул еллардагы вакыйгалар әле безнең хәтердә саклана. 80 нче еллардагы җырлар әле бүген дә яңгырый... Яшьлекләре шул елларга туры килгәннәр иң матур хатирәләрен яңартсыннар: 80 нче еллар дискотекасы кебек онытылмастай күңелле кичәләрне, «су буенда янган учакларны», «Бони Эм»нарны – диско буыны яшәгән вакытларны.

80 нче еллар комсомоллары нинди җырлар җырлаган? 80 нче елларда совет халкы ничек яшәгән?* Мәдәнияттә нинди яңалыклар булган?

ХРОНОГРАФ

1981

- Татарстанда икенче миллиард тонна нефть чыгарыла
- Казан янында Займищедан Идел аша күпер төзелеше башлана

1982

- Яр Чаллы шәһәренең исеме Брежневка үзгәртелә
- Казанда Шаляпин исемендәге беренче опера фестивале үтә (1985 елда ул бөтенроссия статусын ала)
- Казанның «Оргсинтез» заводында «Этилен-200» җитештерелә башлый

1983

- «Оргсинтез»да елына 200 мең тонна куәт белән түбән басымлы полиэтилен җитештерелә башлый

1984

- Алабугада Кама трактор заводы төзелеше башлана
- ТАССР Югары Советы Президиумының ТАССР дәүләт бүләкләре нигезләмәсен раслау турында Указы чыга

1986

- Казанда таможня барлыкка килә
- Хәрби комиссариаттан мобилизацияләнеп, татарстанлылар Чернобыль АЭС афәтен ликвидацияләү эшендә катнашырга китәләр

*80нче еллар буыны турында тулырак – журналыбызның 2020 елның март санында

1987

- Казан аэропортыннан беренче халыкара рейс башкарыла. Ту-154 Берлинга оча
- Түбән Кама гидроагрегатларының барысы да кулланылышка тапшырыла

1988

- Кама трактор заводын ЕЛАЗ җиңел машиналары җитештерә торган завод итеп үзгәртү турында карар кабул ителә
- Әлмәт янында кыю фәнни тәҗрибә башланып китә – Яңа Елховойда үтә дә тирән скважина бораулыйлар. Проект тирәнлеге – 7000 метр
- Татариядән Әрмәнстанга җир тетрәү нәтиҗәсендә хәрабә хәленә килгән шәһәрне торгызу эшләренә төзүчеләр отрядлары җибәрелә

1989

- ТАССР Министрлар Советының халык мәгариф системасында туган телне һәм әдәбиятны укытуны яхшырту буенча Карар кабул ителә
- Казан янында Идел аша автомобильләр йөрү өчен күпер кулланылышка тапшырыла

КАЗАН. ПАРАЛЛЕЛЬ ДӨНЬЯЛАР

1980 нче еллар башы Казаны, май. Урам тузаны һәм алмагач чәчәге исе бергә кушылып, биредә җитештерелә торган «Слеза Мичурина» төнәтмәсеннән дә болайрак исертә. Дөрес, сиреньнең хуш исе Кабан күленнән күтәрелә торган тынчу күкертле водород исен бераз баса. Динамиктан яңгыраган «магнолияләр иле» турындагы шлягер исә чынбарлык хакында уйланырга мәҗбүр итә...

Автор:
Әскәр Сабиров

Чынлыкта исә бернинди сюрреализм да юк боларда. Моннан йөз ел элек вакыт туктап калган иске Казан бакчалары май аенда тоташ чәчәккә күмелә. Сукно бистәсе алачыклары, Вишневскийдан Жданов урамына (булачак Эсперанто) төшкәндә кырыйда кала торган кыекмыек йортлар, Калинин, Островский, Тихомирнов урамнарындагы череп каралган агач өйләр бер-ике атнага аклы-шәмәхәле томан эчендә югала... Тәүге лэйсән яңгырында ук лыгыр пычракка әйләнә торган тузан фәкыйрь капка төпләреннән генә күтәрелеп калмый, бу – биргә үзгәрешләр җиле ташый торган тузан. Ул җил «гасыр төзелеше» – Ирек мәйданыннан ерак түгел урнашачак Ленин мемориалы, Татарстан урамындагы төзелүе бик озакка сузылган Камал театры бинасы ягыннан исә. Башка, өр-яңа, панельле-типовой Казан салынып яткан Кварталлар һәм Горки микрорайоны тарафыннан исә. Җирле йолдыз Ренат Ибраһимовның «тормыш һәм мәхәббәт хакында иркенләп сөйләп була торган» ил турындагы шлягеры исә – иртәгәдән бүгенгә сәлам кебек... Параллель дөньялар.

СЫЙНФЫЙ ИДЕЯЛӘР КРЕМАТОРИЕ

Ленин мемориалын берничә елдан соң, чираттагы бөек революцион бәйрәмгә – Казан студентлары сходкасының 175 еллыгына тәгаенләп төзеп бетерәчәкләр. Казанга килгән шагыйрь Евгений Евтушенко совет архитектурасының әлеге котсыз могҗизасына озак карап торачак, аннары исә үз талантына табынучыларга:

– Казансу буендагы калкулыкта урнашкан һәм крематорийга охшаган

әнә теге бинаның нәрсә икәнен һаман аңламадым мин, – диячәк...

Билгеле, архитектор ул бинаны бөтенләй башкача күзаллаган. Бина җилдә җилфердәгән пролетарийлар байрагын хәтерләтергә тиеш булган, әмма акчаны кискәннәр, проектны гадиләштергәннәр – һәм карета кабакка әйләнгән дә куйган. Әмма әчтә барысы да тиешенчә. Партия документларының «бәһасез» күчермәләрен чырайны сытмыйча карап та булмый, ә бит биредәге экспонатлардан халык массаларының кәефен, рухын күтәрерлек энергетика ташып торуы планлаштырылган.

Гомумән, идеологик акцияләргә акча кызганмыйлар. Божра янындагы калкулыкта – тагын бер колачлы төзелеш. Биредә, шәһәр салу пропорцияләрен һәм перспективаларын санга сукмыйча, ялкынлы революционер Мулланур Вахитовка һәйкәл куеп яталар. Циклоптай фигура әлеге күркәм урынның доминантасын – финанс институтының затлы бинасын каплап торачак. Әмма революционерга барысы да рөхсәт ителә. Партия монументалистикасы җәүһәре өчен урын әзерләгәндә «Вузовец» кинотеатры һәм берничә дистә борынгы күркәм бинаның да җимерттерелүе вактөяк кенә бит...

Хәер, идеология кайвакыт үз корбаннарына файда да китерә икән. Уйламаган җирдән Мәскәү Ленино-Кокушкиноны төзекләндерүгә күп акча бирә. Янәсе, революцион идеяләре белән рухланган Ильич үзенең беренче сөргенен үткәргән урын муллык витринасына әйләнергә тиеш – ахыр чиктә, «Аврора» тикмәгә генә туптан атмаган бит инде...

Төзелешне партия өлкә комитеты махсус контрольдә тота, планеркаларны ТАССР Министрлар Советы рәисе урынбасары Мөхәммәт Сабиров үткәрә. Нәтиҗәдә сходка юбилеена әлеге гади авыл халкы шәһәр халкына әйләнә яза: асфальт, бөтен уңайлыклары булган фатирлар, кафе, универсам, мәдәният йорты. Тагын әле почта, телефон, телеграф – кабат революция ясасаң да була...

Табигый ки, буш урында өр-яңадан Бланк утарын да торгызып куялар. Югыйсә әллә ничек бит: Ильич крестьяннарны азат итү өчен көрәшкән, алар исә революция башлангач, беренче эшләре итеп, аның бабасының утарына ут төрткән...

АЛГА КИТКӘН СОЦИАЛИЗМНЫҢ ТУЗГАН ЙОРТЛАРЫНДА

Казанда тузган торакта яшәүчеләр Ленино-Кокушкино халкыннан үлеп көнләшә. Чәчәк аткан бакчалар артына унтугызынчы гасыр башы көнкүреше поскан, чөнки. Биредә рәсми идеология – үткен телләрне чарлау өчен сәбәп кенә. Казанның статуслы Ленин яки Карл Маркс урамнарын Беренче май бәйрәмендә бизи торган «Партиянең югары максаты – халыкның рәхәт яшәве» шигаре башка – Свердлов, Киров, Луковский яки Волков урамнарында мәсхәрәләү сүзе кебек яңгырый.

Ә бит 80 нче еллар Казаны мәрткә китүдән айнырга тиеш кебек иде. Елга аръягы һәм Горки бушлыкларында төзүчеләр тугыз катлы йортларны коймак пешергән кебек шапылдата гына, һәм зур оборона заводында, нефть химиясе тармагында эшләүче аеруча кирәкле хезмәткәрләргә егерме биш ел



Фото: Е. Канаев

бакыйлыкка күчкән Леонид Ильичның хезмәтеннән, мәсәлән: «Конкрет кеше, аның ихтыяҗлары һәм хаҗәтләре турында конкрет кайгырту – партиянең икътисадый сәясәтенең башлангыч һәм азаккы пункты», – цитатасын ятлыйсың.

Аның каравы, хәтта җимерек йортларда да кайберәүләрнең телефоны бар. Телефон номеры алу – лотерея оту кебек, чират әллә ничә елга сузылган. Әмма сиңа да, күршеләреңне сөендереп, үз гомереңдә бер тапкыр бәхет елмаерга мөмкин икән бит. Ә инде бәхеткә ирешкәч, иртәдән кичкә кадәр чит шалтыратуларга җавап бирәчәксең һәм сөйләшү өчен икенче каттагы Надя түтине, беренче каттагы Биби апаны яки каршы йорттагы Абрам дәдәйне чакырырга тиеш булачаксың. Чакырмый ярамый. Биредә партия Уставы буенча түгел, ишегалдының язылмаган кодексы белән яшиләр...

ИКМӘК ҺӘМ ТАМАША

Тик шулай да 80 нче еллар уртасыннан халык иркенрәк сулыш ала. Сәясәт турында инде Колхоз базары янындагы балык тәңкәсенә чумган пивнушкада басып түгел, бәлки Европадагыча уңайлы барда табын янында фикер алышырга мөмкин була башлый. «Раки» яки «Бегемот»та. Яки хәтта Чернышевский урамында ачылган купшы «Грот-барда». Бу биналарга сирәк кенә студентлар кергәли, биредә бай яшьләр кәеф-сафа кора, аларга хәтта чит ил кешеләрен чакырырга да оят түгел.

Берничә ел элек кенә биргә үзенең поляк коллегасын алып кергән өчен республика газетасы журналисты Владимир Устиновскийның чак кына эшеннән куылмыйча калуын белгәнгә, бу бик гаҗәп тоела. Ничек белгәннәр диген әле бу турыда! КПСС өлкә комитетына бер аноним Польша басмасының тышлыгын җибәргән. Анда исә – гайре табигый хәл! – совет журналисты пивбарга кереп бара...

Хәзер исә Яшьләр үзәгендәге «Кино дуслары клубында» (абонемент буенча гына керергә мөмкин) башкаладан килгән танылган режиссёрлар үзләренең цензура белән көрәше хакында сөйли һәм аздан гына киштәгә куелмый калган фильмнарын күрсәтә. Рязановның «Гараж» фильмы – исемлектә беренче. Биредә, шул ук Яшьләр үзәгендә, алдынгы карашлы студент яшьләр «Үзешчән сәнгать җырлары клубында» бардлар белән очраша. Тиздән биредә Булат Окуджава үзенең тиләләр һәм акыллылар турындагы атаклы җырын башкарачак...

Хакимият күп кенә иркенлекләргә бармак аша карый, хәтта әкренләп тимер пәрдә дә күтәрелә башлый. 1987 елда Казан чик буе шәһәренә әйләнә – аэропортта таможня ачыла. Бер-ике айдан, майда, биргә Лейпцигтан немец туристлары төялгән самолет киләчәк, беренче совет пассажирын исә – чартер рейсына очрак-

бүе торак чиратында торасы, гомерләрен тулай торакта уздырасы юк...

Өмет барын бар да бит, әмма Казан үзәгендәге җимерек йортларда яшәүчеләргә бу гына җиңеллек китерми. Аларның чын «уңайлыклары» чынлыкта бик сасы исле. Ишегалдындагы бәйрәм хөрмәтенә агартылган бәдрәфкә Максим Горький яшьтәше булган агач йортта яшәүче ике дистәләп кеше бертуктаусыз йөргәч, тагын нинди ис килсен инде аннан?! Революция җырчысы сурәтләгән ночлежкалардагы кебек үк, халык бик тыгыз яшәгән фатирларда һаман канализация дә, суүткәргеч тә юк...

Биредә яшәүчеләрнең – үз шигарьләре. Кремль янындагы иске йорт диварына зур итеп «Мы заложники трущоб» дип язып куя алар. «Здесь живут люди. Спасибо правительству за заботу» дигәнен Киров урамындагы коммуналка фасадына эләләр... Алга киткән социализм чорында мондый лозунглар өчен төрмәгә утыртмыйлар инде. Аларны нибары тиз-тиз буяп куялар, тик бераз вакыт үтүгә үк, язулар кабат пәйда була.

Әмма, яхшыга үзгәрешләрне бер дә күрмичә, нигә партиянең ачуын чыгарырга соң? Хәзер Казандагы барлык фатирларда диярлек газ бар, суга исә колонкага, күрше тыкрыкка гына, барып кайтып та була. Дөрес, кышкы салкыннарда колонкалар барысы да диярлек туңа, һәм өйгә чираттагы ике чиләк суны алып кайту челюскинчылар батырлыгын хәтерләтә: суы туңмаган колонкага кадәр егерме минут барасың, утыз минут чиратта торасың, һәм аннары – өйгә кадәр тагын егерме минут кайтасың. Бездә төзелеп беткән социализм турында имтихан бирергә әзерләнүче студентларга бик җайлы. Чиратта туңып торганда, күптән түгел генә

лы гына билет алган яшь лейтенантны – Чкаловны зурлагандай каршы алачаклар.

Әмма Казаннан туры чит илгә китеп булмый әле – билетлар сатылмый. Хәтта социалистик илгә дә – бары тик Мәскәү аша, бары тик төркем белән генә.

1986 елның апрель азагында КАМАЗның яшь эшчеләреннән һәм интеллигенция вәкилләреннән торган шундый төркемнәрнең берсе Чехословакиягә юнәлә.

– Без сезгә бүләк ясарга булдык, – диячәкләр турны оештыручылар төркем җитәкчесе, комсомол хезмәткәре Владимир Фоминга. – Тур программасында Киев юк иде, хәзер исә анда ике көн йөриячәксез, экскурсия үткәреләчәк, отельдә куначаксыз.

Моның нинди бүләк икәнен төркем тиздән аңлаячак. Киев аларны буш урамнар, су сиптерә торган машиналар колоннасы һәм спиртлы эчемлек тулы кибетләр белән каршы алачак. Бу Чернобыль АЭСындагы һәлакәттән соңгы бишенче яки алтынчы көн булачак...

СИН МАЛ ТАБУЧЫМЫ, ЮКМЫ?

1983 елның октябре. Иделнең Звенигово янындагы яры. Биредә гасыр газүткәргече Уренгой-Помары-Ужгород торбасын елга төбеннән менә-менә сала башлаячаклар. Казаннан килгән журналистлар суык сөякләренә кадәр үтеп туңган – алар инде берничә сәгать буе торбаның «Покорись, Волга!» дип язылган башы (дюкер) суга кереп киткәнне көтә. Әмма иң җаваплы мизгелдә кемдер:

– Егетләр, анда тушёнка китерделәр! – дип кычкырмасынмы.

Дүртенче хакимият, партия журналистикасының асыл ирләре, ике дә уйламый, шул якка йөгерә. Дюкерның су астына китүен бик аз кеше генә күреп кала...

Тушёнка банкасы гигант планнарга караганда ышанычлырак – конкретрак шул. Дөрес, КАМАЗ төзелешен үз җилкәсендә кичергән казанлыларга (ул дәвердә башкалада кайвакыт хәтта бәрәңге дә талон буенча бирелә) сиксәненче еллар башы хәтта бай кебек тә тоела әле. Хәзер Татарстан башкаласы – миллион кеше яшәүче шәһәр, СССРда бу статус метро турында хыяллану һәм нинди дә булса Саратовтагыга караганда яхшырак ашау хокукы бирә.

Чыннан да, атланмай инде талонсыз сатыла, Баумандагы «Сөт ризыклары» кибетендә исә хәтта сөт өсте һәм заварной пирожный да сатып алып була, соңгысын шәһәр читеннән дә эзләп киләләр. Көнбагыш кебек арзан креветка һәм кальмар сәрхушләрнең яраткан ризыгы булса, үзләрен хөрмәт итүче шәһәр халкы кайнар ысул белән ысланган экзотик исемле простипома балыгына һәм контрабанда юлы белән Әстерханнан литрлы банкаларда кайтартыла торган кара уылдыкка өстенлек бирә.

Ә менә фил төшерелгән чын һинд чәе, эри торган каһвә, ит, тавык кибетләрдә һаман күренми. Әмма моңа казанлыларның бер өлешенең исе дә китми. Берәүләр – КПСС җитәкчелек иткән илебездә шулар рәтеннән булучылар – Маяковский, Гоголь яки Париж Коммунасы урамнарындагы затлы йортларда яши, эшкә хөкүмәт машинасында йөри, дефицит ашамлык тутырылган пөхтә пакетларны аларга заказ буенча китереп бирәләр.

Икенчеләр, параллель дөньяда яшәүчеләр, якты киләчәк турында вәгъдәләргә ышанмаска кирәклекне яхшы белә һәм үзләрен үзләре кайгырта. Казан елга портыннан һәр сәгать саен китүче «Ракеталарга» утырып, алар Новочебоксарскига юл тота. Анда, күршеләрдә, люизит җитештерү буенча яшерен завод һәм Мәскәү тәэминаты – тавык кына түгел, хәтта чит илдә тегелгән кием-салым да табарга була.

Нинди дә булса модалы һәм чит илдә җитештерелгән әйбер табуның тагын бер юлы – ЗАГСка гариза бирү. Кыюлык өчен бүләк – махсус кибеткә талон, анда ГДРда тегелгән туй күлмәген, Чехословакиянең ЦЕБО фирмасы туфлиләрен, һәм Польшада тегелгән, Карденнан диярлек килеп төшкән костюмны кулга төшерергә мөмкин. Яхшы белә торган кешеләр әйтүенчә, бернидән дә куркырга кирәк түгел – хәзер инде өйләнешмәсәң дә була хәтта, әйберләрне барыбер кире алмыйлар...

Тагын берничә елдан, үзгәртеп кору белән бергә, Казанга кабат талон системасы әйләнеп кайтачак. Үзләренә тиешле май, чәй, иткә чират торганда, халык парадоксаль әйбергә аптыраячак: иркенрәк сулыш алган саен, нигә кибетләрдә товарлар азрак һәм чиратлар озынрак була икән? Хәбәрдарлык чорының шәраб бүлекләре исә сталинизм заманын хәтерләргә мәҗбүр итәчәк: талон буенча аракыны корыч рәшәткәле тәрәзәдән бирәчәкләр. Горбачев яңалыгы – эчкечелеккә каршы көрәшнең кызган мәле...

Ил упкынга тәгәри, ә параллель дөньяда, партия кабинетларында, һаман план коралар. Кама Аланында Татар атом станциясен салырга керешәләр. Алабугада КАМАЗ төзелешенә тиң гигант төзелеш гөрли – биредә елына 150 мең (!) данә трактор җитештерәчәк завод салырга ышандыралар. Аннары трактор заводын «Фиат» җитештерә торган автомобиль заводына әйләндерәчәкләр. Ахыр чиктә, «Фиат» урынына «Ока» җыярга карар кылачаклар...

Нәтиҗәдә Татар атом станциясен, төзеп бетермичә, ябалар. Алабугада трактор заводы да, гигант автозавод та чынга ашмый кала.

Мөгаен, унъеллык азагында күпләр аның ничек башлануын исенә төшерер. Олимпия аюының һавага күтәрелүе, елмаюы, күзеннән яшь тәгәрәү... Шундый булып чыга да шул әлеге дистә ел: дулкынландыргыч, моңсу. Илнең соңгы унъеллыгы...

PRESSA

1980 нче еллар

СУ БУЕНДА УЧАК ЯНА…

«Татарстан» журналының бүгенге редакциясе 80 нче еллардан: йә бала чагы, йә яшьлеге шул елларга туры килә. Шуңа күрә «80 нче еллар буыны» проекты сезне балачакка, мәктәп елларына, институт-университетларга чакыра. Тагын әле төзелеш отрядлары, хезмәт лагерьлары, походлар… Бергәләп бәрәңгегә барулар, дискотекаларга йөрүләр, демонстрацияләргә чыгулар. Армия, практика еллары… «Әй, гитара, әй, гитара, нечкә икән кыллары», – дип җырлаулар, таң каршылаулар, беренче мәхәббәт… Боларның барысы да фотопроектыбызда чагылыш тапты…

Фотолар «Татарстан» журналы редакциясендә эшләүчеләрнең гаилә архивыннан алынды

Беренче Май демонстрациясендә.

Галстуклы балачак. 80 нче еллар пионерлары галстуклары белән горурлана иде.



Казан зоопаркында.
1980 ел.

Хезмәт лагеренда
Нептун көне. 1984 ел.

«Электрониклар» Советлар Союзының һәр мәктәбендә бар иде.

Тегү түгәрәгенә кызлар гына йөри дип кем әйтте?
1985 ел.

1984 ел.

Унынчы класс укучылары – яңа уку елына китаплар алгач.
1985 ел.

Калашников автоматын һәр комсомол тизлеккә җыя һәм сүтә ала. 1984 ел.

Казан тренеры Владимир Житлов һәм ул тәрбияләгән фехтование буенча Олимпия чемпионнары һәм призёрлары: Наилә Гыйләҗева, Валентина Никонова, Ольга Князева.

КАМАЗ тулай торагында. 1988 ел.

КДУның журфагында телеүзәк ачылды. 1989 ел.

Бәрәңгегә барулары көтеп ала идек. 1983 ел.

Карате белән шөгыльләнү – модада. 1984 ел.

Театрның яңа бинасын ачу тантанасы. Р. Мотыйгуллина, Ш. Биктимеров, А. Гайнуллина. 1986 ел.

КАБАН КҮЛЕНДӘГЕ СӘХНӘ

Тышкы яктан караганда, ул балкон-палубалары һәм витражлы тәрәзәләре булган зур затлы корабны хәтерләтә, пыялалары аша иркен мәрмәр фойе буйлап атлап йөрүче кешеләр күренеп тора. Эчендә барысы да – су һәм җил тематикасында, хәтта тамашачылар залындагы лоджиялар биек ярларга туктаган көймәләр кебек эшләнгән. Әлеге зур кораб-бина Кабан ярына 1986 елда урнаша, әйтерсең лә ул туп-туры Камал театры режиссеры Марсель Сәлимҗановның хыялларыннан йөзеп килә.

Автор:
Олеся Бондаревская

Корабның нәкъ менә шушы урында торуы турында риваять бар. Бервакыт Габдулла Кариев «Болгар» кунакханәсенә Тукай янына кунакка килә. Алар балконга чыгалар, һәм Кариев, күлнең ярына таба күрсәтеп, болай ди:

– Безнең театр биредә ачылса, ничек яхшы булыр иде!

Бинаны төзү эшләре исә алты дистә елдан соң гына башлана. Республиканың төп сәхнәсе өчен моннан да яхшырак урынны бүген – бигрәк тә бүгентабып булмас иде. Иске Татар бистәсе, аның тарихи һәм рухи үзәге булган Мәрҗани мәчете, «Печән базары» территориясе, тормыш кайнап торган Татарстан урамы, төбендә хәзинәләр ятуы турында риваятьләр йөргән Кабан күле, Меңьеллык паркы, «Тукай» метро станциясе, Казан зооботаника бакчасы, үзәк базар – болар әйләсендәге театр, әйтерсең, тарих, хәзерге заман һәм киләчәкнең кисешкән урыны булып тора.

– Безнең адрес – Татарстан урамы, 1нче йорт. Без монда «роза ветров» үзәгендә кебек, – ди Камал театрының баш режиссеры Фәрит Бикчәнтәев. – Төрле билгеләр, метафоралар эзли китсәң, бик күп табылыр.

Фотолар Г. Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театры архивыннан алынды

КАМАЛ ТЕАТРЫ «МАРСЕЛЬЕЗА»СЫ

Горький урамы, 13нче йорт адресы буенча урнашкан бина (хәзер биредә – К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры) XX гасыр башыннан алып камаллылар өчен туган йорт була. ТАССРның халык артистлары, актерлар Хәким Сәлимҗанов һәм Галия Нигъмәтуллинаның улы Марсель Сәлимҗановның балачагы узган янкорма (флигель) нәкъ менә шунда урнашкан инде. Чын мәгънәсендә сәхнәдә үскән Марсель дә, нәтиҗәдә, әти-әнисе юлыннан китә. ГИТИСны тәмамлап, Казанга кайта һәм 1966 елда туган театрын җитәкли. Пассионарий, экспериментатор һәм шул ук вакытта милли татар мәдәнияте өчен янып йөрүче Сәлимҗанов труппасын һәрвакыт алга алып бара. Һәм, күпмедер вакыттан соң, театрга үз бишегендә кысан була башлый, аңа зуррак урын, күбрәк мөмкинлекләр, күбрәк тамашачылар кирәк була.

Яңа бинага беренче нигез ташы 1972 елда салына. Проект зур күләмле була, шактый финанслау таләп итә. Илдәге икътисадый вазгыять яхшыруга таба бармый, һәм мондыйрак проектлар, гадәттә, озак вакытка сузыла. Әмма үз театрының мәнфәгатьләрен Сәлимҗанов кебек төрле дәрәҗәләрдә яклый белгән кеше булмаган, диләр. Бернигә дә карамастан, яңа бина төзелеше 1986 елда тәмамлана. Бу – юбилей елы була, татар телендәге беренче спектакльнең сәхнәгә чыгуына, ягъни татар театры оешуга 80 ел тула.



«Ахырзаман» спектакле репетициясендә.

АНЫҢ ИЗГЕ УРЫННАРЫ

1987 елда актер һәм Камал труппасының яшь режиссеры Фәрит Бикчәнтәев армиядән ялга кайта һәм шунда ук яңа бинаны карарга килә. Балконга менеп, бөтен труппа катнашында узучы «Зәңгәр шәл» спектакленең репетициясен күзәтә.

– Марсель Хәмитович мине аска чакырып төшерде һәм сәгать ярымга якын бинаны күрсәтеп йөрде. Бизәнү һәм эш бүлмәләренә алып керде, күн кәнәфиләрне һәм диварларны тоттырып карады, бөтен нечкәлекләренә кадәр сөйләп бирде, – дип искә ала Фәрит Бикчәнтәев. – Ниһаять, ул мине өченче катка алып менде һәм: «Ә хәзер мин сиңа бу бинадагы иң яраткан урынымны күрсәтәм», – диде. Без аның кабинетына ишекне ачып кердек – һәм мин хушсыз калдым. Бик иркен бүлмә, уртада зур түгәрәк өстәл, мөгаен, король Артурның рыцарьлары гына мондый өстәл артында утыргандыр. Өстәл өстендә аның иске кабинетыннан кителгән зур люстра эленеп тора. Марсель Хәмитович әйтә: «Мин Ульяновның Вахтангов театрында, Ефремовның МХАТында булдым. Ләкин бары тик минем генә шундый кабинетым бар...»

Иске бинадан яңа бинага күчкәндә идән тактасын алып китәләр. 1987 елның гыйнвары.

ШӘЛ НӘРСӘ ЯШЕРӘ?

Яңа сәхнәдә куярга премьера итеп Сәлимҗанов Кәрим Тинчуринның «Зәңгәр шәл»ен сайлый. Аның бу пьесаны 1970 нче елларда куйганы була, әмма яңа театрның тамашачылар өчен үз ишекләрен ачуы уңаеннан, спектакльнең 1987 нче елгы версиясе әзерләнә. Төп рольгә татар опера театры солисты Венера Ганиеваны чакыралар. «Һәр театрның үз тарихы белән бәйле спектакльләре бар. МХАТның – «Чайка», Вахтангов театрының – «Турандот». Ә безне, гастрольләрдә: «О, «Зәңгәр шәл» килде!», дип каршы алалар»,– дип сөйләде ул вакытта журналистларга режиссер.

«Зәңгәр шәл» – авылның беренче чибәре Мәйсәрә тарихы, аны мәҗбүриләп карт һәм комсыз ишанга бишенче хатын итеп бирмәкчеләр. Вакыйгалар кызган вакытта авылга аның сөеклесе Булат кайтып төшә. Мәхәббәт билгесе итеп ул кызга ефәк зәңгәр шәл бүләк итә, ә аннары сөеклесен яклап сугышкан вакытта Җиһаншаны үтерә. Булат урманга качарга мәҗбүр була, анда да үзе кебек үк качкыннарны оч-



«Ахырзаман» спектакле. Рольләрдә: Ә.Хисмәт, В.Шакирова.

рата. Алар бергәләп ишан йортыннан Мәйсәрәне коткару планын кора.

«Мин бу пьесаны яттан беләм, ләкин аны кабат-кабат карыйм», – ди спектакль репетициясендә драматург Туфан Миңнуллин. «Зәңгәр шәл»нең кайсы ягы белән үзенә тартып торуын аңлатып бетереп булмый – һәркем өчен аңлаешлы юмормы, Салих Сәйдәшевнең искиткеч музыкасымы (сүз уңаеннан, спектакльнең музыкаль фразасы бүгенге көндә театрда чакыру итеп кулланыла), күпкатлы метафораларымы яки милли тарихи вакыйгаларга кагылышлы яшерен сылтамаларымы.

«Син дә, Фәрит, минем сүзләремне исеңдә тот, син дә аны куярсың!» – дигән бервакыт Сәлимҗанов Бикчәнтәевка. Һәм ул хаклы булып чыга: озакламый үзенең 95 яшен билгеләп үтәчәк «Зәңгәр шәл» бүген дә камаллылар сәхнәсеннән төшми. Спектакль әле дә аншлаг җыя.

«АХЫРЗАМАН»НАН КУРЫКМАГАННАР

Зур сәхнә, искиткеч акустика (аны театрның рәсми ачылышында чыгыш ясаганда Илһам Шакиров үзе югары бәяләгән), техник мөмкинлекләр, тамашачыны яңача утырту – болар барысы да репертуарны принципиаль яктан яңадан карауны таләп итә. Һәм театр ва-банк ясый: 1987 елда татар режиссурасының «дуамал шайтан»ы Дамир Сираҗиев Чыңгыз Айтматовның «Ахырзаман» әсәрен сәхнәләштерергә алына. Айтматов үзе әсәрне куярга рөхсәт биреп телеграмма җибәрде, дип хәбәр итә ул труппага.

Сираҗиев әлеге кыю, катлаулы, үз заманының проблемаларын һәм кимчелекләрен ачып бирүче әсәрне сәхнәгә драматург Мансур Гыйләҗев белән бергә күчерә. Куелышта катнашучылар фикер алышып, тамашачыга нәрсә күрсәтергә кирәклеген хәл итә. Сценография белән рәссам Сергей Скоморохов шөгыльләнә. Бүре сукмаклары салынган кыяларны гәүдәләндерүче күчмә декорацияләр Акбүре белән Ташчәйнәрне тамашачыга әле якынайта, әле ерагайта, төп геройларның аягы астында чайкалучы кыр, куркыныч хәрәкәтләнүче пәрдәләр – болар һәм башка күптөрле чаралар тамашачыны бүреләр һәм кешеләр, намус һәм комсызлык, җәмгыять һәм кеше арасындагы каршылыкның фаҗигале тарихы атмосферасына чумдыра. Театр тарихында беренче тапкыр сәхнәгә гитаралар һәм синтезатор белән рок-ансамбль чыга, интрументлар куелыш өчен махсус сатып ала.

«Ахырзаман» тулы залларда уза, спектакльне башка шәһәрләргә гастрольләргә алып баралар, аны кызып-кызып сүгәләр һәм шулкадәр үк дәрәҗәдә мактыйлар да. Спектакль тирәсендәге шау-шу – узып баручы чорның шартлап сынуы, бу вакыйганы камаллылар үз куелышлары белән мәңгегә теркәп куялар. «Ахырзаман» видеога төшерелә. Бу язманы, башка архив спектакльләренең язмалары кебек үк, театрның ютуб-каналында карарга мөмкин.

СӘХНӘ АРТЫ ТӨРЛЕЛЕГЕ

Бүгенге театр бинасы – 1970 нче еллар авангардына хас интерьер, ягъни чех витражлары һәм ГДР люстрлары, өч бар һәм холлдагы фонтан. Тамашачылар өчен бу – әкият дөньясы. Дөрес, тамашачыны әсир итәрлек бина труппаның үзе һәм театр хезмәткәрләре өчен бик уңайсыз булып чыга. Декорацияләрне саклау һәм цехлар өчен бүлмәләр булмау, көндезге яктылык җитмәгән кечкенә гримеркалар, 1000 кешегә исәпләнмәгән парковка (зур һәм кече заллар шулкадәр тамашачыны сыйдыра), гастроль спектакле белән фураны бушату өчен Татарстан урамындагы хәрәкәтне туктатып тору – күп еллар дәвамында камаллыларга

Камал театры труппасы. 1988 ел.

шушы һәм башка кыенлыкларны җиңеп эшләргә туры килә. Алар түземсезлек белән реконструкцияне көтә, ул инфраструктура проблемаларының бер өлешен генә булса да хәл итәргә мөмкинлек бирәчәк.

Тик болар барысы да театр серләрен саклый торган сәхнә артына карый. Сүз уңаеннан, алар арасында берничә реликвия дә бар. Шул исәптән – ике көзге. Берсен театрга Галия Нигъмәтуллина бүләк иткән. Ул сәхнә артында тора һәм аңа һәркем тамашачы алдына чыгар алдыннан карый. Икенче көзге – бинаның хезмәткәрләр өлешендә, бизәнү бүлмәсе янында урнашкан. Кайчандыр ул «Сәйяр» труппасының тәүге актрисаларының берсе Фатыйма Ильскаяныкы булган.

Сәхнәнең тамашачылар өчен күренми торган тагын бер урынында Горький урамы, 13 йорттагы сәхнәдән китерелгән берничә идән тактасы бар, аны бирегә Марсель Сәлимҗанов белән Фәрит Бикчәнтәев сүтеп алып кайта. Театр корабы бүген дә киләчәккә таба йөзүен дәвам итә. Тарихы ышанычлы итеп йөрәгенең нәкъ түренә яшерелгән.

ТЕАТР ТӨЗЕГӘНДӘ КРАННЫ ОНЫТЫП КАЛДЫРГАННАРМЫ?

Интернетта театрның төзелеш эшләре баручы түбәсеннән кран күренеп торган фоторәсем бар. Версияләрнең берсе буенча, төзүчеләр машинага чыгу юлы калдырырга оныткан, түбәне җәеп бетергән вакытка кран эчтә торып кала. Янәсе, кранны вертолетлар белән күтәреп чыгарырга туры килгән. Бина төзелешендә участок җитәкчесе булган Расих Фәйзрахманов сүзләренчә, чынлыкта, фотодагы кранның конструкциясе җыелма булган һәм түбәне җәеп бетергәч, аны сүтеп кенә алганнар.



Фото: vk.com/kazancatru

«Татарстан» журналының махсус проекты

1990 нчы еллар

БУЫННАР

ДАВЫЛЛЫ 90 нчы ЕЛЛАР БУЫНЫ

...Заманны сайлап алмыйлар – язмышыңа туры килгән заманда яшиләр, кирәк булса... исән калу өчен көрәшәләр. 90 нчы елларда без СССР, КПСС, ВЛКСМ белән хушлаштык... Пионерлар-октябрятлар һәм башка яшь натуралистлар белән саубуллаштык. Партия безнең юлбашчы булудан туктады, үткәннәр үткәндә калды, ә киләчәк килеп җитмәгән иде әле. Әмма шушы ике арада калган 90 нчы еллар буыны киләчәк өчен бик күпне эшләп калды: Татарстан мөстәкыйльлек алды, газлаштырылды, тузган торактан котылды, метро төзи башлады... Һәм давыллы еллардан җиңүче булып чыкты. Хәер, башкача була да алмый иде.

Болар барысы да ничек булды соң?* Бик кызык!

ХРОНОГРАФ

1990

- ТССРның Дәүләт суверенитеты турында декларация кабул ителә
- Татарстан АЭС төзелеше туктатыла
- «КАМАЗ» җитештерү берләшмәсе акционерлык җәмгыяте итеп үзгәртелә. Ул СССРның иң эре предприятиеләре арасында беренче акционерлык җәмгыяте

1991

- Минтимер Шәймиев Татарстан Президенты итеп сайлана
- «Бөгелмә» аэропорты янында Ан-24 самолеты һәлакәткә очрый. 41 кеше үлә

1992

- Республикада референдум үткәрелә, анда татарстанлыларга: «Татарстан Республикасы – Россия Федерациясе һәм башка республикалар, дәүләтләр белән мөнәсәбәтләрен тигез хокуклы килешүләр нигезендә кора торган суверен дәүләт, халыкара хокук субъекты булуы белән килешәсезме?» дигән сорау бирелә. Тавыш бирүчеләрнең 61,39 проценты «Әйе» дип җавап бирә
- Татарстан Республикасының яңа Конституциясе кабул ителә
- Казан халыкара аэропортыннан беренче даими рейс ясала. Маршруты: «Казан – Истанбул – Казан»
- РФ Президенты Борис Ельцин Горбунов исемендәге Казан авиация җитештерү берләшмәсендә Ту-160

*90нче еллар буыны турында тулырак – журналыбызның 2020 елның апрель санында

стратегик ракета йөртүче самолетлар җитештерүне туктату турындагы документка кул куя

1993

• КАМАЗның двигательләр заводы яна

1994

• «Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр һәм вәкаләтләрне бүлешү турында» Шартнамәгә кул куела

• Борис Ельцинның Россия Президенты статусында Татарстанга беренче килүе

• Яр Чаллыда «ОКА» автомобильләре җитештерү заводы эшли башлый, ул елына 75 мең машина чыгарырга тиеш була

1995

• Тузган торак республика программасы гамәлгә ашырыла башлый

• Казанның «Аэростан» авиакомпаниясенең Ил-76 самолетын талиблар кулга төшерә. Экипажны әсирлеккә алалар

1996

• Татарстан Президенты сайлаулары. Президент Минтимер Шәймиев яңа срокка Президент итеп сайлана. Аның өчен сайлаучыларның 97,1 проценты тавыш бирә

• Кандагарда әсирлеккә алынган Ил-76 экипажы, үзләренең самолетына утырып, талиблардан кача. Командир Владимир Шарпатовка һәм икенче очучы Газинур Хәйруллинга Россия Герое исеме бирелә

• Алабугада «Шевроле Блейзер» автомобильләрен җыя башлыйлар. Ул үзебезнең илдә җыелган беренче иномарка дип исәпләнә

1997

• Татарстанда Икътисади һәм социаль прогресс дәүләт программасы кабул ителә. Максаты – дөньякүләм хуҗалыкка интеграцияләнгән социаль юнәлешле икътисад булдыру

• Казанда метро төзелеше башлана

1999

• Казанда Төбәкара клиник-диагностика үзәге булдырыла

• Казан вертолет заводында эшләнгән «АНСАТ» җиңел вертолеты беренче очышын ясый. Бу СССР таркалганнан соң, илдә конструкцияләнеп, һавага күтәрелгән беренче һәм ул вакытка бердәнбер очкыч була

БЕРЕНЧЕ ПРЕЗИДЕНТ ДӘВЕРЕ

1991 елга кадәр Татарстанның президенты юк иде. Шуңа күрә 90 нчы еллар халык хәтеренә беренче президент – Минтимер Шәймиев чоры буларак кереп калды. Республика тарихындагы әлеге иң истәлекле вакыт турында Минтимер Шәрипович белән әңгәмәбезгә хәтта коронавирус та комачаулый алмады. Татарстанның Беренче Президенты, ә хәзер ТР Дәүләт Киңәшчесе тулы үзизоляция шартларында, «Татарстан» журналы редакциясе белән скайп аша элемтәгә чыкты.

Текст:
Татьяна Вафина,
Алсу Дәүләтшина

– Минтимер Шәрипович, 90 нчы елларга «болгавыр еллар» дигән мөһер сугылып калды. Советлар Союзы таркала, бер сәяси стройга икенчесе алмашка килә, чуалышлар, ачлык игълан итүләр, кибетләрдә буш киштәләр... Сезгә шушы вазгыятьтә президент булып сайланып, республикада тәртип урнаштырырга туры килә. Әлеге давыллы елларда сезнең өчен иң катлаулысы нәрсә иде? Кайсы вакыйга белән аеруча горурланасыз? Нииндидер үкенечләр дә бардыр, бәлки...

ЯЗГА ЧЫККАН БОЗАУЛАР КЕБЕК ИДЕК...

– Нәрсәсенә үкенәсең? Бу – безнең буын язмышы, безнең өлешкә әнә шундый хәлиткеч, асылда, революцион еллар тиде. 1917 елда революция кораллы юл белән ясалган, ә 90 нчы елларда империянең таркалуын тормыш үзе китереп чыгарды.

Шулай килеп чыкты: нәкъ менә шундый вакытта президент булдым. Моңа кадәр хакимиятнең күп баскычларын уздым – министрдан алып республиканың Югары Советы Рәисенә кадәр, тиктомалдан президент була алмыйсың. Өстәвенә, безнең илдә президентлык институты юк иде әле. Президентларны беркем дә әзерләми, бу эшкә беркайда да өйрәтмиләр. 90 нчы еллар алдыннан, 1989 елда, мин, беренче тапкыр альтернатив нигездә, КПСС Татарстан өлкә комитетының беренче секретаре итеп сайландым. Бүләкнең дә бүләге иде бу! Минем өчен иң катлаулы еллар – үзгәртеп кору заманы менә шунда башланды да. Кешеләр тормышны яхшыртуны таләп итә. Бөтен нәрсә җимерек, кәстрүлләр буш... Тасвирлы әйтүем. Телевизордан Борис Николаевич Ельцинның, КПССның Мәскәү шәһәр комитетының беренче секретаре буларак, кибетләрдә йөргәнен күрсәтәләр, ә анда бөтен киштәләр буш. Кешеләр үз фикерләрен ачыктан-ачык белдерә башлады, урамнарның халык белән тулганын хәтерлим. Фәүзия Бәйрәмова протест йөзеннән ачлык игълан итте... Ул бит чын-чынлап ач торды, табигате шундый аның. Тормыш та шундый иде ул чакта. Барлык катлаулы сорауларга җавап табарга кирәк иде. Сөйләргә, аңлатырга, чөнки халык төркеме хакимияттән, димәк, миннән барысын да хәл итүне көтте. Төркем белән аралашу гомумән бик катлаулы. Биналарда чыгыш ясау – бер хәл, ә урамнарда, митингларда – бөтенләй башка. Кешеләр күкрәк киереп саф һава сулый башлады кебек, әмма алга таба ничек яшәргә кирәген белмиләр иде әле. Безнең танылган язучыбыз Туфан Миңнуллин үзенең бер чыгышында бу вазгыятьне болай сурәтләп биргән иде: «Кешеләр үзләрен декабрьдә туган бозау шикелле тота. Кыш буе өйдә торган да, яз җиткәч, аланга чыгарганнар». Бик төгәл билгеләмә. Без, авыл малайлары, мондый күренешне еш күзәтә идек, шул бозаулар белән бергәләп шатланышып-сикерешеп йөргәнебез дә булды. Нишләргә белмисең: ирек, шатлык, кояш җылыта... Кинәт кенә кая килеп эләккәнеңне һич аңламыйсың...

ИТЕ ДӘ ЮК, МАЕ ДА

Союз ни өчен таркалды? Беренчедән, СССР Конституциясендә КПССның җитәкче роле турындагы 6 нчы статья бар иде. Шуңа күрә партия катнашыннан башка бернәрсә дә эшләнмәде – җитди мәсьәләләрне Госплан да, Министрлар Советы да хәл итә алмый иде. Төп сәбәп, әлбәттә, җитештерү өлкәсендә – халыкка нәрсә ашатырга? Мәсьәләләр хәл ителсен өчен союздаш республикаларга хокук бирергә кирәк иде, автономияле республикалар һәм өлкәләр турында әйтеп тә торасы

Фото: Ната Смирнова

Президент вазыйфасына керешү. 1991 елның 4 июле.

Фото: ТР Президенты Матбугат хезмәте архивыннан.

юк. Автономияле республика буларак Татарстанның да бернинди хокукы юк иде. Мин – республика җитәкчесе, моны үз башымнан кичердем. Менә бер очрак. Бервакыт, Министрлар Советы Рәисе булып эшләгән чагымда, безне Краснодар крае башкарма комитеты рәисе Николай Кондратенко белән бергә КПСС Үзәк Комитетына «келәм өстенә» чакырдылар. Башта миннән союз фондына ТАССР ның сыер итеннән күбрәк дуңгыз ите тапшыруын аңлатып бирүемне сорадылар. Аңлатам: бездә яшүче халыкның яртысыннан артыгы мөселманнар. Без ит тапшыру буенча планны тулаем үтәп барабыз, ләбаса! Җавап: Юк, дуңгыз ите сыер итеннән күбрәк булырга тиеш түгел!

Ә Кондратенкога мондый дәгъва белдерелде: бик күп субпродукт (малның эчке органнары) тапшырасыз, ә фондка бары ит кенә кирәк. Ул да аңлата: крайда җитештерелгән барлык ит болай да союз фондына китеп бара, үзебезнең халыкка да нидер калдырырга кирәк бит... Юк! Син СССР Госпланы күрсәтмәсе буенча нәкъ менә ит кенә җибәрергә тиеш. Ә субпродуктны үзегезгә калдырыгыз.

Без дә җитештерәбез, алар да җитештерә, әмма ни аларда, ни бездә бернәрсә дә калмый. Бөтен нәрсә бик катгый күзәтчелек астында. Хәтта эремчекнең майлылыгын да өстән билгелиләр: 13% майлылыктагы эремчек ашарга хакыгыз юк, киметегез! Хәлләр менә шундый иде.

ЗАМАНА ТАЛӘБЕ

Гомумән алганда Татарстан Республикасы Балтыйк буендагы өч республика бергә җитештергән кадәр продукция эшләп чыгара иде. Сәнәгатебез мөмкинлекләре гаять зур, әмма республика аның бары тик ике проценты белән генә идарә итә ала иде. Калганы – СССР Министрлар Советы, өлешчә РСФСР Министрлар Советы карамагында. Ул вакытта «кечәге» союздаш республикалар союздаш дәүләт хокукларына дәгъва итә башлады. Һәм автономияле республикалар да үз хокуклары турында сүз кузгатты.

Россиядәге автономияле республикалар арасында дәүләт суверенитеты турындагы декларацияне беренче булып без кабул иттек. Бу, әлбәттә, кыю таләп иде. Без моны аңлап эш иттек. Татарстанның тарихы катлаулы. Милли мәдәният, тел, гореф-гадәтләр проблемалары алгы планга чыкты. Аларны хәл итәргә кирәк иде. Мондый мәсьәләләр килеп чыккан очракта аларны кичекмәстән хәл итәргә кирәк. Җәмгыятьтә киеренкелек калдырырга ярамый.

ЕЛЬЦИН ТРАМВАЙДА КИТЕП БАРДЫ

Ул чакта, 90 нчы елларда, бик күп көнүзәк проблемалар өлгереп җиткән иде, шуңа күрә без чигенергә уйламадык та, вазгыять тә шундый иде. 1990 елның август башында Казанга килгәч, Борис Николаевич Ельцин хәлнең бик нык кызганын күреп, халык алдында: «Суверенитетны йота алган кадәр алыгыз», – дип белдерде. Аның бу сүзе инде тарихи гыйбарәгә әверелде. Ә ул Язучылар берлегендәге очрашу вакытында туды. Татар зыялылары һәм җәмәгатьчелеге белән очрашу бик давыллы узды. Барысы да Ельцинга кискен-кискен сораулар бирделәр, җавап таләп иттеләр... Нык кына кыса башладылар! Дөресен әйтергә кирәк, ул булдыра алганча түзде, барысына да җавап бирергә тырышты. Аннан соң арткы ишектән ишегалдына чыкты да күрде: халык һаман таралмый. «Моннан урамга чыгу юлы бармы?» – дип сорады. «Бар – дим. – Әнә анда трамвай соңгы тукталышына бара». Якында – Волков урамында Сәкинә Шакировна яши иде, аның белән йөргән чакта бу тирәләрне яхшылап өйрәнгән идем... Ельцин тиз генә урамга таба атлады, туктап торган трамвайга утырды да китеп барды. Китте дә барды, чөнки чынбарлыкны үз күзләре белән күрде.

Кичке ашка керешер алдыннан ул: «Минтимер, нишлибез инде?», – дип сорады. «Борис Николаевич, – дим, – вазгыять кызганнан–кыза бара, шартларга тора, бу хәлдән чыгу юлын табарга кирәк.

Кешеләрне тынычландырырга, сөйләшергә-килешергә кирәк».

Ул шартнамә проектын әзерләргә тәкъдим итте: «Әйдәгез, эшче төркемнәр төзик, алар эшкә керешсеннәр. Әгәр нәрсәгәдер барып төртелеп, шартнамә текстын язуны дәвам итә алмыйлар икән, без синең белән, яннарында торып, кулга каләм тотып, бу мәсьәләләрне хәл итәрбез». Шулай эшләдек тә. Ул сүзендә торды, һәм без 1994 елда шартнамәгә кул куюга ирештек. Тарихта беренче тапкыр Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр һәм вәкаләтләр бүлешү турында Шартнамә әнә шулай барлыкка килде.

Шартнамәгә кул куйгач, халык тынычланды, кыен хәлдән шулай чыктык. Беләсезме, мин ул вакытта нәрсәдән курыктым? Коткы салучылардан. Урамнарда, аеруча кичкырын, яшьләр иркенләп йөри, шәһәрдә студентлар күп, шунда берәрсе атып җибәрсә яки пычакка тотынса… Ә менә Ирек мәйданыннан өйгә кадәр ияреп кайткан төркем-төркем халыктан курыкмадым – кешеләр, бөтен нәрсәне миннән таләп итә-итә, янәшә атлыйлар иде…



Референдум көне. 1992 елның 21 марты.

Без ул чакта Россиядә Шартнамәгә кадәр үк референдум уздырган бердәнбер республика булдык. Референдум барлык процессларны да тизләтте.

ТАРИХ ДӘРЕСЛЕКЛӘРЕНДӘ НИЛӘР ЮК?

– Хәзерге буын 90 нчы еллардагы Татарстан турында нилләр белергә тиеш? Дәреслекләрдә язылмаганны…

– Шәхси тойгыларны, тарихи вакыйгаларга шәхсән катнашудан туган тәэсирләрнедер, мөгаен. Шул вакыйгалар эчендә кайнаган һәркем, һичшиксез, күңелендә җуелмас хатирәләр саклый. Соңыннан тарихка әвереләчәк әлеге хәлләрне үз вакытында йөрәкләребез аша уздырдык.

90 нчы елларда, яшь булсак та, тәҗрибәле, тормышны белә идек. Бу исә ахыр чиккә җитмәскә ярдәм итте. Белмим, бу кадәр сабырлыкны каян алганбыздыр – кешеләргә бөтен нәрсәне аңлатып бирергә кирәк иде бит. Барысы да беренче тапкыр эшләнә, ни кыларга, нинди адым ясарга кирәклеге аңлашылмый, хәтта партия элитасында да фикер каршылыклары килеп чыга иде.

Кагыйдәм шундый: башымда катлаулы проблемалар буенча төгәл карар, төгәл юнәлеш булдырырга тырышу. Әгәр эш барышында икеләнә, үз карарларыңны үзгәртә башласаң, хәл тагын да катлауланачак. Гадәти кагыйдәләр кебек, әмма алар барысы да безнең баштан үткән. Кешеләргә чынга ашмаслык вәгъдәләр бирергә кирәкми. Үзең булдыра алганны гына.

РЕФЕРЕНДУМ – БОРЫЛЫШ МИЗГЕЛЕ

Мәсәлән, 1992 нче елгы референдумны алыйк. Аның нәтиҗәсендә Татарстан, Канададагы Квебек, Испаниядәге Каталония шикелле, үзбилгеләнү турында референдум үткәрергә җөрьәт иткән, күпмилләтле халкы федераль үзәк белән мөнәсәбәтләрен ачыктан-ачык һәм цивилизацияле рәвештә билгеләгән республика буларак дөньяның иң яңа тарихы сәхифәсенә кереп калды. Бу инде халыкара дәрәҗәдәге вакыйга иде! Бүгенге көндә сезнең белән читлек аша сөйләшү ихтималы да бар иде…

Әлеге демократия, хокук юлларын башлап үтәргә туры килде. Без ул чакта Россиядә югарыда искә алынган Шартнамәгә кадәр үк референдум уздырган бердәнбер республика булдык. Референдум барлык процессларны да тизләтте.

1991 елның ноябрендә республиканың Югары Советы референдум турында закон кабул итте, февральдә аны уздыру көне билгеләнде – 1992 елның 21 марты. Референдумда катнашучыларга бер генә сорауга җавап бирергә тәкъдим ителде: «Татарстан Республикасының суверен дәүләт булуы, Россия Федерациясе һәм башка республикалар, дәүләтләр белән тигез хокуклы килешүләр нигезендә үз мөнәсәбәтләрен коручы халыкара хокук субъекты булуы белән килешәсезме?» Референдумга әзерлек СССР таркалу җирлегендә барды. Бу исә Мәскәүне бик җитди борчуга салды, мине бу нияттән ваз кичәргә үгетләделәр. Референдумны үткәрмәскә өндәү өчен башкалага чакырып алдылар. Казан вокзалында мине һич көтмәгәндә… Табиев каршы алды. Мин аны бик ихтирам итә идем, ул 1960–1979 елларда КПСС Татарстан өлкә комитетының беренче секретаре булып эшләде. Күрәсең, узара яхшы мөнәсәбәтебезне белеп, мине үгетләргә җибәргәннәр. Табиев – оста дипломат: «Ни дә булса әйтү дә, киңәш итү дә кыен», – диде… Ул да республика өчен борчыла иде. Сергей Михайлович Шахрай янына киттек. Аңа ничек бар, шулай әйттем: халык референдум таләп итә. «Сез бит күренекле демократ, халык ихтыярына каршы килергә мөмкинме-ни?», – дидем. Минем урында булсагыз, нишләр идегез? Үзебез демократиягә таба беренче адымнар ясыйбыз, шул ук вакытта, үзебез үк референдумны тыябызмы? Мин моны аңламыйм…

Ул вакытта Россия Югары Советы Рәисе Руслан Хасбулатов иде. Үз вакытында: «Шәймиевне читлеккә бикләп, Мәскәүгә алып килергә кирәк», – дип белдергән кеше ул. Әйе-әйе… Журналистлар ул заманда бу хакта бик күп язды. Хасбулатов – Кавказ кешесе, юл куярга теләмәде. «Референдумны уздырмау турында карар кабул итегез!» – дип таләп итте. Ә безнең команда барысына да әзер иде инде. ТР Югары Советы Рәисе урынбасары Зилә Вәлиева – Казанда, Фәрит Мөхәммәтшин Мәскәүдә, РСФСР Югары Советында оборона тоттылар.

Мин Мәскәүдәге җитәкчеләргә әйттем: «Үз халкыннан куркучы җәмгыять строе төзибезмени инде? Болай булса, без Россиянең яңарган, демократик рухлы җәмгыяте белән ничек идарә итәрбез соң? Революция бара бит… Халыкка референдум үткәрмәскә кирәк дип әйтергә кемнең хакы бар?»

Соңыннан җиткерделәр: ул очрашуда катнашкан берәү: «Каян чыккан бу үҗәт егет, кайда тәрбияләнгән?» – дип сораган…

Кыскасы, без берничек тә килешә алмадык. РСФСР Югары Советы безнең референдум буенча тискәре карар кабул иткән очракта, республика Югары Советының референдумны үткәрмәү турындагы утырышы әзерләнгән иде. Фәрит Хәйруллович Мәскәүдә депутатлар җәфалый, әмма ул бирешми. Татарстаннан сайланган кайбер депутатлар хәзер әүлия булып йөриләр-йөрүен, ә теге чакта

республикага каршы чыктылар. Тик мин гомерем буе андый хәлләргә артык игътибар бирмим, аларга вакыт сарыф итсәң, бик күп файдалы эшләргә өлгерә алмый калуың бар.

Республика җитәкчесе буларак, ахыргы сүзне мин әйтергә тиеш идем. Күңелемдә, бигрәк тә үзең өчен, карар инде кабул ителгән икән, икеләнеп торырга урын юк. Һәм без үз карарыбызны үзгәртмәдек. Мәскәүдән Казанга десант килеп төште – безнең халыкны референдум үткәрмәскә үгетләп йөрделәр. Безнең прокурор Антоновны сайлау участоклары эшен тыярга мәҗбүр иттеләр.

Референдум алдыннан, кич белән, татарстанлыларга телевидение аша Борис Ельцин мөрәҗәгать итте. Россия президенты безнең халыкны референдумга бармаска өндәде.

Ельциннан соң республика телевидениесеннән мин чыгыш ясадым. Халкыбызга бөтән караштан чыгып мөрәҗәгать иттем: демократик җәмгыятьне үстерү зарурлыгы, илебезнең инде бу юлга басканы турында сөйләдем. Референдум соравына уңай җавап кына Татарстанга тынычлык һәм иминлек китерәчәк, дидем.

Халык реферундумга бердәм катнашты, 2611 сайлау участогының барысы да вакытында ачылды һәм тыныч кына эшләде. Минем өчен моның әһәмияте зур иде, кешеләр прокурор тыйганга карап тормадылар. Сайлау хокукына ия булган халыкның 81,7% ы референдумда катнашты, сайлаучыларның 61,4% ы куелган сорауга «әйе» дип җавап бирде. Бу турыда рәсми документ бар. Бу – безнең заманның иң мөһим хокукый документларының берсе, ул тормышыбыздагы борылыш мизгелен дәлилләп тора. Ул мизгелдә барыбыз да шуны аңладык: артка таба юл юк, уртак тел табарга һәм алга таба үсәргә кирәк.

БОЛАРНЫҢ ГАМӘЛГӘ АШМАВЫ ИХТИМАЛ ИДЕ...

– 90 нчы елларда көчле проектларга нигез салынды, ә бит аларга күпләр шикләнеп карады. Югары инфляция заманында матур хыял гына булып тоелган төзелешләрне, эшләрне башлап җибәрергә ничек күңдерә алдыгыз кешеләрне? Тузган торакны бетерү, тоташ газлаштыру программалары, ул вакытта әкият булып тоелган метро идеясе...

– Боларны ничек гамәлгә ашыра алуыбызга бүген дә гаҗәпләнәбез. Кешеләргә чын, нәтиҗәле гамәлләр кирәк иде. Илдә хәтта акча әйләнеше дә калмаган вакыт бит – инфляция 1000% ка җитте! Ә без шундый зур проектларны башкарып чыгуга ирешә алдык.

Казан тузып-җимерелеп баручы шәһәр иде. Оборона предприятиеләре булган ябык шәһәр. Сугыш вакытында бирегә эшчеләре белән күпме предприятие күчеп килгән... Барысын да ашык-пошык, вакытлыча урнаштырып торганнар. Күбесе шулай калган да. Башкаланы үстерү-яңарту өчен акча юк. Кемне дә булса гаепләү дә кыен. Тирә-якта тормыш бик тиз яңадан корылганда, күпләр көчкә-көчкә очын-очка ялгап яшәгәндә торак төзү кайгысымыни?! Икътисадый яктан тотрыксыз үзгәртеп кору чорында торак төзүгә тотыну – читтән караганда, сәер генә түгел, ә гайре табигый хәл булып тоелгандыр. Әмма без 1995 елда җитди карарга килдек: шәһәрләрдәге һәм районнардагы барлык сәнәгать предприятиеләре җитәкчеләрен җыйдык та үз «салымыбызны» салдык – гамәлләштерелгән продукциянең 1% ын тузган торакны бетерү фондына күчереп барырга! Бу фәкать безнең – Татарстанның карары иде.

Бөтен тузган торакны исәпкә алдык. 1995 ел башына Казанда тузган торакта 31 мең гаилә яши, шуның 21 меңе – шәһәрнең иң үзәгендә булып чыкты. Күпме халык баракларда яши иде. Күпме кешегә фатир төзергә кирәклеген күз алдына китерә аласызмы? Хәзер минем үземә дә моңа ышану кыен, әмма без һәммәсен дә яңа, бушлай торакка күчердек! Бушлай, чөнки ул кешеләрнең түләргә акчалары юк, болай да, Горькийның «На дне» пьесасындагы кебек, тормышның төбендә яшиләр иде. Без кешеләрне тормыш төбеннән барлык уңайлыклары булган фатирларга тартып чыгардык. Бөтен ил шундый хәлдә иде, әмма без моны эшли алдык, ә башкалар – юк. Ил күләмендә моңа тиң программа хәзергәчә юк. Мин өй туйларына еш йөрдем ул чакта. Кешеләр сөенечтән елыйлар иде... Яшисең-яшисең җимерек йортта, һәм кинәт яңа йортта, яңа районда бушлай яңа фатир бирәләр! 2004 ел ахырында нәтиҗәләр ясадык: ун ел дәвамында тузган торак фондыннан гражданнарны күчерү өчен 48 мең 576 фатир төзеп тапшырылган. Мин бу карарыбызның дөреслегенә бер генә минут та шикләнмәдем, хәтта суд белән яный башлагач та. Татарстанны федераль салым базасына кул сузуда гаепләделәр, ә бу – хөкемгә тартырлык гамәл. «Мин хөкем ителергә әзер, әмма суд ачык булырга тиеш», – дип белдердем. Мин хәзер ул чорны рәхәтләнеп, канәгатьлек белән искә алам – без бөек эш башкардык.

Минтимер Шәймиев Тузган торакны бетерү программасы буенча яңа фатирларга күчүчеләрне котлый. 1998 ел.

“

Ил күләмендә моңа тиң программа хәзергәчә юк. Мин өй туйларына еш йөрдем ул чакта. Кешеләр сөенечтән елыйлар иде... Яшисең-яшисең җимерек йортта, һәм кинәт яңа йортта, яңа районда бушлай яңа фатир бирәләр!

КЕШЕЧӘ МӨНӘСӘБӘТ ҺӘМ КЕШЕЧӘ ШАРТЛАР

Газлаштыруга килгәндә, берничә тапкыр әйткәнем бар – бу минем шәхси ниятем. Туган ягым Актаныш районында урманнар бөтенләй юк диярлек. Без балачактан ук җәй буе ялыктыргыч, авыр эш белән – мичкә ягар өчен кизәк җыеп киптерү белән шөгыльләнә идек. Авыл гаиләләрендә балалар күп. Безгә су җылыту, чәй кайнату әнкәй өчен зур мәшәкать иде. Аның азапланыуы күңелгә уелып калган, күрәсең. Шуңа күрә, мөмкинлек чыгу белән, без республиканы газлаштыруга керештек... Тормыш сыйфаты шунда ук үзгәрде, бигрәк тә күп балалы аналар өчен. Җирдәге оҗмах – кәнкүрешебездә газ барлыкка килүне мин әнә шулай атыйм. Чөнки безнең буын мондый оҗмахсыз чорларны үз җилкәсендә татыды.

Моңа ничек ирештек? 90 нчы елларда күп нәрсә үзара мөнәсәбәтләр аша хәл ителде. Башкача булмый да, чөнки илдә акча әйләнеше туктаган, кешеләргә хезмәт

хакы түләргә дә мөмкинлек юк. Шулай бервакыт безгә «Газпром» башлыгы Рем Иванович Вяхирев килде. Без аның белән яхшы мөнәсәбәттә идек. «Минтимер, сез газны күп кулланасыз, әмма түләмисез», – диде ул. «Акча юк», – дим. Ул чакта бу бик киң таралган җавап иде. Республика предприятиеләренең «Газпром»га 53 миллион сум бурычы җыелган.

«Эшчеләргә айлык хезмәт хакын түләү өчен генә булса да бераз акча тап инде!» – ди Рем Иванович.

Һәм без ул вакытта Министрлар Советы Рәисенең беренче урынбасары Равил Моратов белән киңәшләштек тә, үз тәкъдимебезне керттек. Бездә, «Оргсинтез» заводында – полиэтилен, Әлмәттә металл торбалар җитештерәләр. Сәнәгать предприятиеләренең дә газ өчен бурычы җыелган икән, димәк алар барысы да республиканы газлаштыру эшенә кушылачак, дибез. Ә «Газпром»ның авылларны газлаштыру планы бар. Сез шул планыгызны үтисез, ә без, бурычларыбыз хисабына, бөтен республиканы газлаштырабыз. Килешкәнчә башкарып та чыктык. Без 2002 елга, илдә беренче булып, шәһәр-авылларыбызга тоташ газ керттек – газны һәр плитәгә китереп җиткердек. Хәзергә әле бер генә төбәкнең дә мондый уңышка ирешә алганы юк. Бүгенге көнгә илнең өчтән берендә газ бөтенләй кермәгән әле.

Метро турында да шул вакытларда хыяллана башладык. Хәтеремдә, ул вакытта Башкортостан җитәкчесе Мортаза Рәхимов белән еш күрешеп-сөйләшеп йөрдек – күршеләр бит! Мин планнарыбыз белән уртаклашам, метро төзи башларга ниятлибез, дим. Ә ул: «Минтимер, мөгаен, барып чыкмастыр ул эш, вакыты да ул түгел, транспорт мәсьәләсе дә ул кадәр кискен тормый...», – ди. Метро төзүләре җиңел булмады, ләкин хәзер тормышыбызны метродан башка күз алдына да китерә алмыйбыз. Әйе, чыгымлы эш булды, әмма яшәргә кешечә шартлар тудырдык!

ХЫЯЛЛАР ТОРМЫШКА РӘХӘТЕН ТОЕП АШЫРЫЛЫРГА ТИЕШ

– Ягъни теге яки бу гамәл – хыялны тормышка ашыру икән, димәк, ул уңышлы булачак?

– Минем өчен шулай. Һәм үз хыялыңны тормышка рәхәтен тоеп ашырырга кирәк. Инде ун ел президент булмасам да, нишләп мин берәүгә дә тынгы бирмим? Без «Яңарыш» фондын ни өчен оештырдык? Бусы да гомерем буе күңелемдә йөрткән хыялым иде: тарихи мирасыбызны – борынгы Болгар һәм Зөя шәһәрләрен тергезү. Президентлыктан соң мин үземне ирекләрәк кеше итеп хис иттем, күңел өчен нindидер игелекле эш белән шөгыльләнәсем килде. Эшләгәндә һәр көн җинаятьләр, янгыннар, һәлакәтләр һ.б. турында хәбәрләрдән башлана иде. Президентның көне беркайчан

> “
> Төркем белән аралашу гомумән бик катлаулы. Биналарда чыгыш ясау – бер хәл, ә урамнарда, митингларда – бөтенләй башка. Кешеләр күкрәк киереп саф һава сулый башлады кебек, әмма алга таба ничек яшәргә кирәген белмиләр иде әле.

да яхшы хәлләрдән башланмый – миңа ышана аласыз. Әмма республика Конституциясенә кулыңны куеп ант иткәнсең икән – сәламәт бул, хезмәт ит, эшләрне көрәп бар!

Акча беркайчан да җитми торган мәңгелек хәзинәләр бар: мәдәният, ана теле... Әмма кеше бу өлкәләрдә беренчел хокукка ия. Мин ЮНЕСКОның да мондый хәзинәләр өчен борчылганын беләм – глобальләшү шартларында күпме телләр югала! Әлеге мәсьәләләр күтәреп торырга мөмкин кебек тоела гына. Юк, күтә алмыйлар! Алар кичектергесез. Республикабызның уңышлы үсеше гореф-гадәтләрне, рухи мирасны саклау белән турыдан-туры бәйләнештә. Без моның белән шөгыльләнергә бурычлы. Безне аңларга телиләрме-юкмы – бусы мөһим түгел, без республикабызда яшәүче милләтләрнең барысының да ана телләрен сакларга бурычлы. Бу өлкәдә аңлашылмаучылыклар булу аркасында тынычлыгыбызны югалтабыз, балаларны тәрбия итүгә зыян китерәбез. Без эшли беләбез, димәк, максатка ирешергә кирәк. Без бергәләп, дус-тату һәм шат яшәргә, киләчәгебезне тәрбияләргә тиеш. Хәзер без күп телдә белем бирү комплекслары булдыруга тотындык, алар безнең балаларны көндәшлеккә сәләтле итеп үстерергә мөмкинлек бирәчәк. Өч телдән – рус, татар һәм инглиз телләреннән башлыйбыз. Ата-аналардан балаларга кытай, гарәп һәм башка телләрне өйрәтүне үтенеп гаризалар керә. Дөнья ачык хәзер, моңа шатланырга кирәк. Безнең заманда «тимер пәрдә» корылды, күп нәрсә тыелган иде, хәтта радио да тыңлый алмадык. Шуңа күрә, мөмкинлекләр ачылуына куанып яшәргә һәм үсәргә кирәк.

Берәүгә дә ике гомер бирелмәгән, тик без ни өчендер кайчак бу дөньяга мәңгегә килгәндәй кыланабыз. Ничек инде кешене туган теленнән мәхрүм итәргә, телне саклар өчен шартлар тудырмаска мөмкин? Тел мәдәният һәм гореф-гадәтләр өлкәсенә алып керә. Кешене үз милләтеннән, диненнән мәхрүм итәргә кемнең хакы бар? Моны туган теленнән мәхрүм ителмәгән кеше генә аңламыйдыр, мөгаен. Без бит ач-ялангач түгел, Аллага шөкер, сугыш юк. Хәзер ясалма киртәләр кору заманы түгел, нәкъ менә үсеш өчен шартлар тудыру вакыты. Безнең кирәкле дәреслекләрне әзерләү, күп телдә белем бирү мәктәпләре булдыру, кирәкле шартлар тудыру өчен мөкинлекләребез бар. Укытырга һәм укырга гына кирәк! Зур социаль программаларны гамәлгә ашыра алганбыз икән, бу проектны да башкарып чыгарбыз. Дәүләтнең иҗтиһади нигезе булырга тиеш, ул мәдәниятне дә, телне дә, рухиятне дә саклап калачак.

ЯРАТКАН ЗАМАН ҺӘМ ЯРАТКАН УРЫН

– ТАССРның 100 еллык бик бай тарихы бар. Төрле чорлар булган, шуларның кайсысы сезгә аеруча ошый, Сез кайсы чорда яшәргә яки кайсысына беразга гына кайтып килергә теләр идегез?

– Мин бүген сезнең сорауларга ихлас җавап бирдем, язмышымнан зарланганны ишетмәгәнсездер бит? Бу дөньяда яшәвең нинди генә чорга туры килсә дә, лаеклы яшәргә кирәк. Мине беркем дә көчләп каядыр кертеп җибәрмәде. Үз өлешеңә тигән теләсә кайсы заманда лаеклы гомер кичерергә тырышырга кирәк.

– Сез Татарстанда һәр районны, аның һәр почмагын беләсез. Яраткан

урыныгыз бармы? Сез үзегезне кайда бик бәхетле хис итәсез?

– Һәр кеше өчен иң яраткан урыны – туган җире, мөгаен. Актаныш районындагы кечкенә генә Әнәк авылы – язучы Нур Баянның һәм минем дә туган ягым. Без урта мәктәпне тәмамлаганда, анда 57 йорт бар иде. Югары уку йортларында да 57 студент укый иде. Димәк, уртача алганда, һәр йорттан бер бала югары белем алган булып чыга. Безнең мәктәп бик көчле иде, безнең күренекле укытучыларыбыз безгә бик яхшы белем бирделәр.

Әнкәй исән чакта авылга сирәк кайтканыма үкенәм. Барысы да бар югыйсә: транспорт, вакыт, мөмкинлекләр… Ә әнкәй янына кайтып күрешеп килергә өлгермим. Әни кеше ул һәрчак үз балаларын көтеп яши. Казанга безгә кунакка килгәч, ул бөтен нәрсә турында сөйли башлый иде. Эштән арып кайтасың, кайвакыт әнкәй сөйләгәндә йокыга да китәсең. Ә аның яңалыклары күп җыелган. Мин йокыга китәм, ә ул минем карават янында утырып сөйли дә сөйли… Нишләп мин аны тыңлап бетерергә, озаклап сөйләшеп утырырга мөмкинлек таба алмадым икән? Менә шушы хис һич тынгы бирми. Әти-әниләрне онытырга ярамый. Бу күңелгә мәңгелеккә кереп кала. Менә сезнең белән бер–беребезнең күзенә карап сөйләшеп утырабыз – сез дә үзгәрәсез, мин дә…

Минем тагын бер яраткан урыным бар – Казан Кремле. Анда ниләр булганын күзәтергә яратам. Ашлыкны гектардан берничә центнерга күбрәк җыелып алган уңышлы бер елда, авыл җыелышларында киңәшеп, Ходай биргән өстәмә уңышны саткан акчаны Кол Шәриф мәчетен төзергә һәм Благовещение соборын төзекләндерергә бирергә карар иттек. Төзедек, төзекләндердек. Кремльдә эшләгәч, мин анда кайвакыт җәяү йөргәлим, читтән күзәтеп торам. Кешеләр мәчеткә яки соборга гаиләләре белән киләләр һәм күз алдында үзгәрәләр. Ата-аналар балалары белән әкренрәк, ягымлырак сөйләшә башлый, күзләре нурланып китә. Күрәм дә шатланам. Чыннан да, игелекле уртак эшкә катнашу безне яхшыга үзгәртә. Бу – безнең байлыгыбыз. Бу – безнең барыбызның да яраткан урыннары. Бу – безнең Ватаныбыз.

БУЛДЫРА БУ ЕГЕТ!

– Сез – халыкның яраткан президенты. Сезне ни өчен яраталар? Халык игътибарын тою күңелләме? Авырсынмыйсызмы?

– Үз-үзеңә бәя бирү бик катлаулы. Минем озын тормыш юлым күп кешеләр белән бәйләнгән. Мин моның кадерен беләм!

Хезмәт юлымны бөек реформатор Никита Хрущев чорында башладым. Кешегә үз сәләтләрен эретү-күрсәтү, халык алдына чыгару мөмкинлеге биргән яхшы заман – «җепшек чор» иде ул.

Юллама белән Мөслимгә килдем. Яңа гына институт тәмамлаган 23 яшьлек инженер. Бәлки тырыштыр, намуслыдыр, әмма моны кем белсен ул чакта? Мөгаен, барысы да бергә бик яхшы туры килгәндер: заманы да, шәхси омтылышлар да, миңа насыйп булган форсат та. Без бит барыбыз да максималистлар идек, алныялны белми эшләдек.

Әлбәттә, тәҗрибәле осталар миңа сак карадылар: нишләр икән монда яшь инженер? Көз иде, остаханәләрне авыл хуҗалыгы техникасын ремонтлау сезонына әзерләү бара. Кулыма көрәк алдым да башкалар белән бергә остаханәне чүп-чардан чистарта башладым. Шуннан соң эшчеләр мине үз кеше итеп кабул иттеләр, үз араларына керттеләр.

Кыш көне яшь тракторчылар өчен әзерлек курслары алып барырга куштылар. Мәгълүм булганча, бу космосны актив үзләштерү еллары иде. Шуңа күрә «шәкертләрем» күбрәк трактор төзелеше белән түгел, космос белән кызыксындылар: галәмгә җибәрелгән иярчен ничек кире Җиргә егылып төшми икән? Кызыксынучан һәм белемгә тартылган кешеләргә үпкәләп буламыни? Озакка китсә дә, ясалма иярчен турында да, трактор детальләре турында да бар белгәнемне сөйләп бирергә тырыштым. Бу егетләрнең күзендә никадәр мәхәббәт, җылылык һәм өмет чагыла иде!

Иң мөһиме – кешеләрне аңлау. Кешеләр миңа ышана башлады, ә ышаныч ул – бик зур ярдәм. Мин яшьләр белән дә, олы яшьтәге тәҗрибәле агайлар белән дә уртак тел табарга өйрәндем. Һәркемгә кешечә карадым, тормышындагы проблемаларын хәл итүдә булышырга омтылдым.

Механизаторлар хезмәтен ничек җиңеләйтүем турында да искә төшерми булдыра алмыйм. Кышкы иртәләрдә машиналарны кабызу бик кыен иде, төнлә бөтен нәрсә туңа. Йөртүчеләр машина астына учаклар яга, двигательләрне җылыта, кайвакыт моңа ярты көн вакыт уза. Ул вакытта энергия белән тәэмин итү үзәкләштерелмәгән, автопаркта электрны урындагы генераторлар эшләп чыгара. Эшкә иң иртә килүче машинистка тәкъдим иттем: әйдә, машина йөртүчеләргә кайнар су әзерләп куябыз. Зур мичкә таптык, аңа катод белән анод урнаштырдык, асылда, зур су җылыткыч ясадык. Шул мичкәдә суны кайнап чыкканчы җылытабыз. Машина йөртүчеләрне җыйдым да әйттем: моннан ары бик иртә килергә кирәкми, радиаторларга салыр өчен кайнар су бар. Ни өчен моңа кадәр берәүнең дә башына килмәгәндер, белмим. Никадәр бәхетшатлык күрдем ул эшчеләрнең йөзендә!

Техниканы гына түгел, кешеләрне дә кайгыртучы яшь инженер турында хәбәр әнә шулай таралды. «Булдыра бу егет!» – дигән фикер туды халыкта.

Тормыш – катлаулы нәрсә. Һәр кеше үзенең әзерлегеннән, тәрбиясеннән чыгып, яшәү рәвешенә һәм кагыйдәләренә карап үз фикерен белдерә яки үз гамәлләрен кыла. Төрле кешегә төрле мохит тәэсир итә. Шуңа күрә үз карашыңны аңлата белергә һәм сабыр булырга кирәк. Үз гомеремдә күңелемдә эшче кешегә карата нindидер ачу туганы булмады. Барысы да – безнең кешеләр, безгә беркемне дә Айдан ташламаганнар, лабаса… Мин кешеләрне яратам – тормышымдагы төп кагыйдәм шул.

“Әнкәй исән чакта авылга сирәк кайтканыма үкенәм. Барысы да бар югыйсә: транспорт, вакыт, мөмкинлекләр… Ә әнкәй янына кайтып күрешеп килергә өлгермим. Әни кеше ул һәрчак үз балаларын көтеп яши.

1990 нчы еллар

ОҖМАХ
УТРАВЫНА СӘЯХӘТ

1994 елның 31 мае. Казан. Балалар реабилитация үзәге ишегалдында, комлык янәшәсендә, бер снайпер хуҗаларча үзенә урын җайлый. Бик шәп оптикалы винтовка, үтә күренмәле битлек, бронежилет, камуфляж... Мондый көтелмәгән күршелектән бераз аптырап калган репортерлар сак кына профессиональны күзәтә. Хәер, һәр ике як та биредә бер үк эш буенча: Россия Президенты Борис Ельцинны көтә.

Автор:
Әскәр Сабиров



Президент бераз тоткарлана, һәм әлеге сәфәрне яктыртырга килүчеләр белән илбашын саклаучылар арасындагы дистанция бераздан ничектер үзеннән-үзе якыная.

– Гафу итегез, ә бу нәрсә ул сезнең? – дип сорарга җөрьәт итә республика газетасы хәбәрчесе Әнвәр Маликов, снайпер винтовкасына төртеп күрсәтеп.

– Тавышйоткыч.

– Ә нигә кирәк ул?

– Ничек инде нигә? Күз алдыңа китер, Борис Николаевич чыгыш ясый, беркем дә комачауламаска тиеш һәм менә нәкъ шул вакытта, әйтик, әнә теге тугыз катлы йортта яшәүче берәү балконга чыга...

– Чыкса нәрсә була?

– Ничек инде нәрсә?! Ә Борис Николаевичның кинәт кенә фикере чуалса? Менә артык тавыш чыкмасын өчен, безгә тавышйоткыч кирәк тә инде.

Аралашу кинәт үзеннән-үзе туктап кала. Репортерлар снайперның сүзләрен уйлап баш вата – шаяртып әйтүемеюкмы? Янәшәдәге йорт түбәләрендә ялтырап киткәләгән оптика да шомлану өчен җирлек тудыра...

Ишегалдында чиновниклар һәм сакчылар арасында Борис Николаевич белән Минтимер Шәймиев күренгәч, киеренкелек кими төшә. Ап-ак күлмәк кигән, елмаймаган Ельцин – гаҗәеп мөлаем. Әмма җирле журналистлардан беркем дә Президентка үзенең соравын бирә алмый кала. Ельцинны бина эченә алып кереп китәләр, ул анда балалар белән сөйләшә, сабыйлар аңа үзләре үргән кәрзиннәрен бүләк итә, аннары Президент башкала телевидениесе хезмәткәрләре микрофонына дежур сүзләр әйтә дә – шуның белән вәссәлам.

ИҢ МӨҺИМЕ – ИМИНЛЕК

Татарстан Президентының матбугат сәркатибе Әнәс Хәсәновның аннан алдагы көнне ни өчен мине президент кортежына кертергә тырышуы менә хәзер аңлашыла инде: югыйсә җирле массакүләм мәгълүмат чаралары сәфәрне Беренче канал күзлегеннән генә «күрә» алачак бит. Әмма Россия Президенты аппаратында драматургиягә бернинди үзгәреш кертергә дә җыенмыйлар: юк икән, димәк – юк. Икенче көнне иртән Әнәс Хәсәнов кунакларны кабул итүче як үтенечен тагын кабатлый.

– Юк, – ди тагын бер мәртәбә Россия Президенты аппараты вәкиле, әмма инде бераз уңайсызланган кебек тә күренә. Чөнки аның чөгендердәй кызыл йөзе, Казандагы төн йокысыз үткән ахры, дигән уйларга этәрә.

– Кырынганда киселдегезме әллә? – дип, кунак йөзенең кызыллыгына ишарәле Хәсәнов, аңардан күзен дә алмыйча.

– Ярар, – ди ахыр чиктә, ирониягә түзә алмыйча, чиновник. – Барсын алайса, кортежда...

Президент кортежы эченнән бөтенесе дә яхшы күренә: сак чарала-

ры – моңарчы күрелмәгән дәрәҗәдә. Уртасында Ельцин лимузины барган машиналар кавалькадасы буп-буш урамнардан җилдерә. Юллар ябык, транспорт йөрми. Кортеж башындагы микроавтобуста – камуфляж кигән коралллы баһадирлар.

Әмма болары чәчәк кенә булган икән әле. Кортеж Осиновога – «Майский» совхозына юнәлгәч, тагын да кызыграк хәлләр башлана. Горький шоссесының буеннан-буена милиционерлар чылбыры тезелгән, алар бер-берсеннән 15–20 адым ераклыкта тора. Беренче чылбырдан соң, урманда – тагын бер шундый ук тере чылбыр. Әмма милиционерлар да исәпсез-хисапсыз түгел бит. Кортеж трассадан бистә урамына борылуга, милиция чылбыры башта сирәкләнә, аннары юкка чыга. Формалы кешеләр урынына – һәр капка төбендә җиңенә бәйләвеч таккан җәмәгать активисты.

«Майский» совхозы территориясенә беренче булып снайперлар утырган микроавтобус керә. Аларны тиешле урыннарга урнаштырып чыккач кына, Борис Николаевич утырган лимузин килеп җитә.

1990 НЧЫ ЕЛЛАР УРТАСЫНДАГЫ ОАЗИС

– Республика үзе теләгән кадәр суверенитет алганнан соң, мин Татарстанда халыкның ничек яшәвен карарга килдем, – дип, сәфәренең максатын аңлата Ельцин аэропортка килеп төшүгә үк.

Һәм башта курка-курка гына караны яхшы тоемлана. Татарстанның фетнәле төбәк буларак имиджы аны үзләре үк уйлап чыгарган башкала акыллыбашларына әле һаман тынгы бирмәве сизелә. Республика чигендәге гаскәрләр, Мәскәү ихтыярына каршы килеп үткәрелгән референдум һәм анда татарстанлыларның үз җөмһүриятләренең халыкара хокук субъекты булуын даулап алулары, катлаулы сөйләшүләр барышы – болар барысы да күптән түгел генә булган хәлләр бит әле. Хәтта РФ һәм ТР дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр һәм вәкаләтләр бүлешү турында Шартнамәне дә Мәскәү белән Казанның моннан өч ай элек кенә имзалаган чагы...

Әмма «Майский» янында, якын килергә ярамаганга ерактарак торсалар да, кешеләр Ельцинны ихластан сәламли, аларның кулында бернинди плакатлар да юк, һәм бу үзеннән-үзе киеренкелекне бетерә. Ә инде теплица комплексы территориясе буенча беренче адымнарыннан ук делегациянең кәефе бөтенләй күтәрелә. Ни әйтсәң дә, Татарстанда кунак каршылый беләләр шул: «Майский»да лимоннар өлгерә, тропик чәчәкләрдән хуш ис аңкый, плантацияләрдә исә кызарып пешкән помидор, борыч, сусыл кыярлар күзне иркәли... Салмак адымнар белән Ельцин атлап барган оазис үзеннән-үз, Татарстанда оҗмах ук булмаса да, ул каядыр янәшәдә генә, ахрысы, дигән уйлар уята түгелме соң?

Күтәренке кәеф бер генә тапкыр – Ельцинны озатып йөрүчеләр арасында бәхәс купкач кына бозыла яза. Республика газетасы мөхәррирен Яр Чаллыдагы милләтчеләр пикеты турындагы язмасы өчен шелтәли башлыйлар – ТР җитәкчелеге фикеренчә, андый пикет бөтенләй уздырылмаган була. Россия Президенты янында ук татарча бәхәсләшәләр, әлбәттә, Ельцин бернәрсә дә аңламый, әмма гаҗәпләнүен дә яшерә алмый...

Әмма бу тиз онытыла, Президент мактавыннан канатланган хуҗалар саф һавада, алдан ук әзерләнгән чатырларда табын кора. Биредә чәй, чәкчәк һәм бераз суынган өчпочмаклар белән тамак ялгаганнан соң, Ельцин, култамгасын салып, янәшәдәгеләргә китаплар бүләк итә – журналистларга гына эләкми, алар бу хәлне ерактан гына күзәтергә мәҗбүр була...

КИЛӘЧӘК БҮГЕНГЕДӘН ЯХШЫРАК

«Майский» бигрәк тә Ельцинны озатып йөрүче түрәләргә ошаячак. Юмарт хуҗалар башкаладан килгән кунакларның кофр һәм дипломатларына теплицада үскән нигъмәтләрне төяп җибәрәчәк, һәм канәгать әфәнделәр Казанга кайтып җиткәнче, хәзер инде ликер-аракы сәнәгатенең җирле предприятиеләре эшен барып карасаң да шәп булыр иде, дип шаяртачак.

Әмма сәфәр программасы югарырак бурычларны күздә тота. Татарстан Россия Президентына үзенең тагын сыйфатын – толерантлыгын күрсәтә: Петр һәм Павел соборында һәм Мәрҗани мәчетендә.

Мәчеткә кергәндә, Ельцин, шәригать кушканча, аяк киемен сала һәм бүләк ителгән түбәтәйне кия, шул рәвешле миллионнарча мөселманның ихтирамын яулый.

Россия Президенты статусында Татарстанга беренче сәфәре вакытында Борис Ельцин әдәпле, тыйнак, аз сүзле була. Ул да, татарстанлылар да үзара хөрмәт саклый. Ихтимал, нәкъ менә шул сәфәрнең иң мөһим нәтиҗәсе булгандыр һәм күпләрдә безнең уртак киләчәгебезнең хәзергедән яхшырак буласына ышаныч тудыргандыр да.

Дөрес, бер журналист соңрак әлеге сәфәрне экскурсия, дип атаячак. Чөнки Президент Казанда бер генә проблемалы предприятиегә дә бармый. Хәтта Ельцин карарларыннан соң юкка чыгу халәтенә килеп җиткән, төзелеп бетмәгән Ту-160 самолетлы авиация заводын да барып карарга теләүче табылмый.

Хәер, мондый төр проблемаларны харизма һәм сөйкемлелек белән генә хәл итеп булмый шул... ▪

1990 НЧЫ ЕЛЛАРГА СӘЯХӘТ

Узганнарга әйләнеп карасак, 90 нчы еллар буынына хәтәр вакыйгаларга шаһит булырга туры килүе искә төшә. Сәяси стройның алышынуы, митинглар, демонстрацияләр, бандитизм, инфляция... Язмышларына давыллы 90 нчы еллар язылган кешеләр үзләрен төрлечә тоталар, төрле гамәлләр кылалар: кемдер, ирек даулап, мәйданнарга чыга, кемдер, вуз дипломын тирәнгәрәк яшереп, зур букчасын асып, ерак илләргә товарга чыгып китә, кемдер һәлакәт салган зыянны юкка чыгаруда катнаша... Заманаңы сайлап алмыйлар – анда яшиләр, исән калу өчен тырышалар-тырмашалар. 90 нчы еллар буыны да исән-имин калды. Ничек? Безнең бүгенге ретрофоторепортажыбыз – шул турыда...

30 август – Республика көне. Казан.

Татарстанлылар итек белән тәэмин ителгән.



Татарстанда референдум. Тавыш бирү участокларының берсе. 1992 елның марты.

Авыл. Ипи китерделәр...

Фото: Рамил Гали; ТР Президенты матбугат хезмәте архивыннан

«Татарстан» журналының махсус проекты

2000 нче еллар

БУЫННАР

ИКЕ МЕҢЕНЧЕ ЕЛЛАР БУЫНЫ

Яңа гасыр һәм яңа меңьеллык Татарстанда ничек башланып китте? Казанның меңьеллык юбилеен ничек бәйрәм иттеләр? Казанның Изге Ана иконасын Ватиканнан туган җиренә ничек кайтардылар? Республикада нинди яңа предприятиеләр барлыкка килде? Ничек итеп Кама аша күперне төзеп бетерделәр һәм ничек итеп Казансу аша күпер салдылар? XXI гасырның бөек төзелешләре һәм бөек казанышлары – «Буыннар» проектында.

ХРОНОГРАФ

2000

- Казан Кремле ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы Исемлегенә керде

2001

- Минтимер Шәймиев өченче тапкыр президент итеп сайланды

2002

- Саескан тавында Кама аша күпернең беренче чираты сафка кертелде

2004

- Яр Чаллыда «Мастер» Кама индустриаль паркы булдырылды

2005

- ТР Дәүләт Советы РФ Президенты Владимир Путин тәкъдиме белән Минтимер Шәймиевне Татарстан Республикасы вазифасына раслады. Казанның меңьеллыгы бәйрәм ителде. Татарстан башкаласында БДБ илләренең саммиты үтте
- Колшәриф мәчете ачылды
- Татарстанга Ватиканнан Казан Изге Мәрьям Ана иконасы кайтартылды
- Казанда Казансу аша «Миллениум» күпере ачылды (беренче чираты)
- Казан метрополитены эшли башлады. Биш станция эшли
- Республика социаль ипотека программасы эшли башлады
- «Татнефть Арена» кулланылышка тапшырылды. Ачылу тантанасында Scorpions чыгыш ясады
- «Алабуга» махсус икътисади зонасы булдырылды

2006

- «Түбән Кама Нефтехим»да елына 180 мең тонна җитештерү куәте белән полипропилен чыгарыла башлады
- Әшәлчә чыганагында беренче 100 тонна битум нефте чыгарыла башлады
- КАМАЗ һәм Американың Cummins Inc. фирмасы «КАММИНЗ КАМА» уртак предприятиесен оештырды

2007

- Россия Федерациясенең дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләрне бүлешү турында Килешүгә кул куелды
- Республикада өченче миллиард тонна нефть чыгарылды
- Казансу аша «Миллениум» күперенең икенче чираты сафка керде

2008

- «Соллерс-Алабуга» заводы сафка кертелде. 27 майда РФ Премьер-министры Владимир Путин катнашуында беренче Fiat Dukato конвейердан төште
- Горбунов исемендәге Казан авиация берләшмәсе РФнең Хәрби-һава Көчләренә «Виталий Копылов» Ту-160 стратегик ракета йөртүчесен тапшырды
- Казан «Рубин»ы беренче тапкыр футбол буенча Россия чемпионы булды

2009

- Түбән Камада тоташ металл кордлы шиннар заводы сафка басты. Проект куәте – елына 1,2 миллион шин
- Россиянең һава-Космос Көчләре өчен «Ансат-У» вертолетлары эшләнә башлады
- «Ак Барс» хоккей клубы тарихта беренче тапкыр Гагарин Кубогын яулады

ФӘРИТ МӨХӘММӘТШИН: «УРТАК ЙОРТЫБЫЗ – ТАТАРСТАННЫ БӨТЕН ХАЛЫКЛАР ӨЧЕН ДӘ УҢАЙЛЫ ИТӘРГӘ ОМТЫЛАБЫЗ»

Федераль дәрәҗәдә Татарстанны гадәттәгечә милләтара аралашуның, халыклар арасында үзара аңлашу һәм хөрмәтнең югары культурасы булган төбәк дип атыйлар. ТАССРның бер гасырлык бәйрәме узачак елда Фәрит Мөхәммәтшин «Татарстан» журналы редакциясендә кунак булды һәм Татарстан халыклары Ассамблеясенең ничек барлыкка килүе турында сөйләде.

Текст:
Ольга Благодарова

Фотолар Татарстан халыклары Ассамблеясе тарафыннан бирелде

Ассамблея химаясендә үткәрелә торган халык бәйрәмнәре тезмәсе Казанда Масленица һәм Нәүрүздән башлана, Лаешта «Каравон» рус фольклор фестивале белән дәвам итә. Аннары Аксубай белән Әлмәттә чуваш Уявы һәм Учугы үткәрелә.

АССАМБЛЕЯ ЭШЧӘНЛЕК КОЛАЧЫН КИҢӘЙТҮГӘ ИРЕШТЕ

– Фәрит Хәйруллович, 2007 елда, Татарстан халыкларының II съездында, «Татарстан Республикасы Милли-мәдәни берләшмәләр ассоциациясен Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар ассамблеясе (Татарстан халыклары Ассамблеясе) итеп үзгәртү турында» карар кабул ителде. Сезне ассамблея рәисе итеп сайладылар. Татарстан халыклары Ассамблеясе эшләгән елларда нинди төп бурычлар хәл ителде? Нинди проблемалы мәсьәләләр үз чиратын көтә?

– Милләтара тынычлыкка һәм татулыкка ирешү өчен, Татарстанда һәрвакыт бик күп эш башкарылып килде. Әмма бу мәсьәләләргә әле 1990 нчы еллар башыннан бирле аерым игътибар һәм кайгыртучанлык күрсәтелә. 1992 елның маенда узган Татарстан халыкларының беренче съезды республика халыклары тормышында зур роль уйнады. Ул вакытта 9 җәмгыятьтән торган Татарстан Республикасы Милли-мәдәни җәмгыятьләре ассоциациясен төзү турында карар кабул ителде. 2007 елгы II съездда Ассоциацияне Татарстан халыклары Ассамблеясе итеп үзгәрттеләр.

Ассамблея эшчәнлегенең төп юнәлешләре – Татарстан халыкларының телләрен, матди булмаган мирасын (фольклор, гореф-гадәтләр һәм йолаларны), халык сәнгате һөнәрләрен һәм кәсепләрен саклау һәм үстерү, миграция проблемаларын хәл итүдә катнашу, төбәкара һәм халыкара хезмәттәшлекне үстерү, фәнни үзәкләр белән хезмәттәшлек итү һ. б.

Барлык халыклар өчен дә уртак әхлакый кыйммәтләр, мәдәният, тел, тарихи хәтер тирәсендә кешеләрне берләштерү – җәмгыять һәм дәүләт үсеше өчен бик зур потенциал. Нәкъ менә шуңа күрә республикада традицияләрне саклауга аерата игътибар бирелә. Ассамблея химаясендә үткәрелә торган халык бәйрәмнәре Казандагы Масленица һәм Нәүрүздән башлана, Лаешта «Каравон» рус фольклор фестивале белән дәвам итә. Аннары Аксубай белән Әлмәттә чувашларның Уявы һәм Учугы уздырыла, Мамадышта удмуртларның Гырон быдтоны, Мөслим районының Мари-Бүләк авылында мари Семыгы үткәрелә; мордвалар Лениногорскида Балтай һәм Тәтештә Валда Шинясьне уздыра; Яр Чаллыда Иван Купала көне, Мамадышта керәшеннәр Питрауны бәйрәм итә.

Питрауны былтыр егерменче тапкыр уздырдылар, анда бөтен республикадан һәм Россиянең башка төбәкләреннән 60 меңгә якын тамашачы җыелган иде.

– Без бергә булганда көчле!

Ассамблеягә, ассоциациядән аермалы буларак, юридик зат итеп теркәлгән иҗтимагый оешмаларның гына түгел, ә республика халкы арасыннан физик затларның да әгъза сыйфатында керүе күздә тотыла. Нигездә, болар – төрле министрлык һәм ведомстволар җитәкчеләре, дәүләт һәм муниципаль хакимият органнары вәкилләре. Бу исә Ассамблеянең әлеге структуралар белән хезмәттәшлеген көчәйтергә мөмкинлек бирде.

Татарстан халыклары Ассамблеясе миграция сәясәте өлкәсендә хезмәттәшлек турында килешү имзалау тәкъдимен күтәреп чыкты. Бу – Ассамблея тарихында мөһим вакыйга булды. Анда катнашкан якларның миграция сәясәте өлкәсендәге хезмәттәшлеге әлеге килешүнең предметы булып тора.

Татарстан чит ил гражданнары өчен социаль һәм икътисади яктан кызыктыргыч төбәк булып кала бирә. Республика Эчке эшләр министрлыгының Миграция мәсьәләләре идарәсе мәгълүматларына караганда, былтыр 335 меңнән артык чит ил гражданы миграция исәбенә куелган. Чит ил гражданнарының Татарстанга килүенең төп максаты – эшкә урнашу (33%). Миграция исәбенә куелучылар арасында иң күбе – Үзбәкстан (105 мең), Таҗикстан (42 меңгә якын), Казахстан (16 мең), Азәрбайҗан (13 меңгә якын) гражданнары.

Килешүне гамәлгә ашыру кысаларында Халыклар дуслыгы йортында милли-мәдәни мохтариятләр җитәкчеләре, хакимият һәм хокук саклау структуралары вәкилләре катнашында инде 20 ел дәвамында һәр квартал саен түгәрәк өстәлләр уза. Ахыр чиктә без Татарстанга күчеп килгән кешеләргә иҗтимагый тормышка кереп китәргә, гамәлдәге законнар нигезендә яшәргә һәм эшләргә булышабыз.

Ассамблея эшчәнлеге Татарстан Республикасының дәүләт милли сәясәте концепциясен тормышка ашыру юнәлешендә бара. Бу документ бәрабәренә Ассамблеянең дәүләт һәм муниципаль хакимият органнары белән конструктив хезмәттәшлек инструменты барлыкка килде, дип әйтергә була. Ассамблея эшчәнлек кырын шактый киңәйтүгә иреште.

Сер түгел, милли сәясәт өлкәсендә кабул ителгән дәүләт программаларына карамастан, Татарстанда бу юнәлештә тормышка ашырасы бурычлар аз түгел. Барлык эш шунда ки, милләтара мәсьәләләр бер тапкыр һәм мәңгегә хәл ителә алмый, аларга даими рәвештә игътибар бирергә, һәрвакыт уяу булырга кирәк. Көн саен системалы, эзлекле эш алып бару мөһим.

– Без, татарстанлыларга, республикабызда һәм илебездә яшәүче барлык халыклар да кадерле, барлык мәдәниятләр дә җанга якын.

ҮЗГӘРЕШЛӘР МАСШТАБЫН ХАЛЫК САНЫН ИСӘПКӘ АЛУ КҮРСӘТӘЧӘК

– Бу елларда Татарстанның милли составы үзгәрдеме? Соңгы мәгълүматларга караганда, Татарстанда күпме халык яши? Иң күп һәм иң аз санлы халыкны атый аласызмы?

– Сүз дә юк, Татарстан халыкларының I съездыннан соң узган 28 ел эчендә республиканың милли составы үзгәреш кичерде. 2010 елда үткән соңгы халык санын алу мәгълүматларына караганда, Татарстанда 173 тән артык милләт вәкиле яши, ә 2002 елгы халык санын алу нәтиҗәләре буенча 115 милләт теркәлгән иде.

Республика халыклары арасында сан ягыннан татарлар күпчелекне тәшкил итә (керәшеннәрне, Әстерхан һәм Себер татарларын да кертеп). Икенче урында – руслар, өченчедә – чувашлар, дүртенче урында – удмуртлар. Бишенче урында – мордва, 2002 елда алар украиннардан соң 6 нчы баскычны били иде. Алтынчы урында – марилар. Җиденче һәм сигезенче урыннар исә украиннар һәм башкортларныкы. Ассамблея вәкилләре арасында иң аз санлылардан ассириялеләрне, һиндларны һәм бурятларны телгә алырга мөмкин.

Киләсе Бөтенроссия халык санын алу бу елның көзенә планлаштырылган һәм «Бөтенроссия халык санын алу турында» Федераль законны тормышка ашу буларак узачак. 2020 елгы халык санын алу үзгәрешләр масштабын бәяләргә ярдәм итәчәк һәм Россия җәмгатенең структурасы турында кыйммәтле мәгълүмат чыганагы булачак.

Алдыбызда көткән халык санын алуда катнашу бик мөһим, чөнки ил халкы турында демографик һәм социаль-икътисадый яссылыктагы төгәл мәгълүмат төрле максатларда кирәк. Аның нигезендә төбәкләрнең һәм торак пунктларның бюджетлары планлаштырыла, икътисадый үсеш стратегиясе корыла. Сан алу нәтиҗәләре халыкның теге яки бу катлауларына (яшьләргә, балалы гаиләләргә һ.б.) булышуны күздә тоткан дәүләт программаларын әзерләү өчен хезмәт итә. Сан алу шулай ук республикада яшәүче төп халыкларның санын ачыкларга мөмкинлек бирә, бу да безнең өчен, әшебез өчен бик мөһим.

БЕР-БЕРЕҢНЕ АҢЛАУ СӘНГАТЕ

– Татарстан ассамблеясенең башка төбәкләрнеке белән чагыштырганда төп аермасы (бәлки, өстенлеге дә) нидә?

– Татарстан җире ачык йөзле кунакчыллык, халыкларның тыныч һәм тату яшәве, мәдәниятләр һәм диннәрнең уңышлы диалогы белән борын-борыннан дан тота.

Татарстанның иң зур казанышы – үзара аңлашу, уртак карарга килү, башка милләтләрнең мәдәни процессында катнашуны олуг сәнгать дәрәҗәсенә җиткерү. Дөнья төрле төсләргә бай, чөнки һәр халык гомумкешелек мәдәнияте мозаикасына үзенең кабатланмас буяу-төсмерләрен кертә. Анда бик сакчыл карарга, буыннан-буынга тапшырырга кирәк булган мәңгелек кыйммәтләр бар.

Татарстан күп кенә мәсьәләләрдә Россиянең башка субъектларыннан алда бара. Монда милләтара мөнәсәбәтләрне күзәтеп-тикшереп торуның төбәк системасы булдырылган һәм уңышлы эшләп килә, халыклар дуслыгы йортларын булдыруда комплекслы ысул кулланылган, гаммәви этномәдәни кичә-бәйрәмнәр уздырыла, гражданлык җәмгыяте институтлары белән уңышлы хезмәттәшлек алып барыла, алар арасында Татарстан халыклары Ассамблеясе аерым урын били. Президент һәм республика хөкүмәте милләтара һәм динара мөнәсәбәтләрнең торышына зур игътибар бирә.

1999 елда Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев ярдәме белән Халыклар дуслыгы йорты ачылды. Татарстан халыклары Ассамблеясенең 20 еллыгына, ә бу 2012 елда булды, республика Президенты Рөстәм Миңнеханов башлангычы белән, Татарстан Халыклары дуслыгы йортының яңа бинасы, Россиядә иң зур һәм иң яхшы җиһазландырылган Дуслык йорты ишекләрен ачып җибәрде. Дуслык йорты милли берләшмәләрне үстерүдә, дәүләтнең милли сәясәтен гамәлгә ашыруда ярдәм итүгә йөз тота, әмма ул милли берләшмәләрнең эшчәнлеген алыштырмый.

Хәзерге вакытта Ассамблея 240 тан артык милли-мәдәни иҗтимагый берләшмәне үз канаты астына ала. Район башлыклары тәкъдиме белән республикада ассамблеянең 19 вәкиллеге, 12 халыклар дуслыгы йорты һәм үзгә нәтиҗәле эшли.

Актив эш кысаларында Ассамблеянең милли-мәдәни мохтариятләренең яшь лидерлары милләтара мөнәсәбәтләрне камилләштерү юнәлешендә үзләренә хас – яшьләр форматындагы инициатива-тәкъдимнәр белән чыга башлады. 2014 елда алар аерым оешмага – Татарстан халыклары Яшьләр ассамблеясенә берләште. Ул чакта аларның команда эшендә көчләрен берләштерә алачагына шикләнеп караган идек. Беләсезме, хәзерге вакытта Яшьләр ассамблеясе төбәк милли-мәдәни автономияләренең 30 дан артык төрле яшьләр хәрәкәте вәкилләрен берләштерә, Татарстан районнарында аның 13 вәкиллеге бар, ул бик күп социаль әһәмиятле проектларны гамәлгә ашыра, Татарстан Республикасындагы чит ил студентларына адаптация һәм социальләшүдә ярдәм итә. Күргәнегезчә, безнең ул вакыттагы шикләребез нигезсез булып чыкты.

БЕЗ БЕРГӘ БУЛГАНДА КӨЧЛЕ

– Сезнеңчә, Татарстан халыклары дуслыгының сере нидә? (Шундый кызык сүз бар: Татарстанда гына Пасхага татар кешесеннән «Катерина, сәлам! Христос воскресе!», ә Гает көнне рус танышыңнан: «Привет, бәйрәм котлы булсын!» дигән тәбрикләү хәбәре алырга мөмкин. Раштуага руслар бәлеш пешерә, ә татарлар Пасха көнне рәхәтләнеп йомырка буйый һәм бу – балалар сораганга гына түгел...)

– Без бергә булганда көчле! Бары тик бергә генә без үз илебезне якларга, демократия һәм социаль гаделлек принципларына нигезләнгән чыпчын федератив дәүләт төзергә, Россия Федерациясе халыкларының бай тарихын һәм дәүләтчелеген, аларның мәдәниятләренең тиңсез төрлелеген һәм үзенчәлеген саклап калырга сәләтле.

Бүгенге Татарстан йөзенең көндәлек күренеше – милләтара һәм динара тынычлык белән татулыктан, үзеңнең һәм илебездә борын-борыннан гомер кичерүче барлык халыкларның мәдәни-тарихи традицияләренә хөрмәттән гыйбарәт.

Без татарстанлылар өчен республикабызда һәм илебездә яшәүче барлык халыклар кадерле, барлык мәдәниятләр җанга якын. Без уртак йортыбыз – Татарстанны барлык халыклар өчен дә уңайлы итәргә омтылабыз. «Җир нинди, чишмәләре дә шундый» дигән яхшы мәкаль бар. Татарстандагы тынычлык һәм татулык, дустанә күршелек һәм үзара хөрмәт – безнең төп байлыгыбыз, һәм безнең бурыч – бу кыйммәтләрне саклау, телләрне һәм милли мәдәниятләрне саклауда һәм үстерүдә тигез хокуклылыкны тәэмин итү.

Фото: Андрей Данилов

Фото: Камилла Вилданова

КАЗАННЫҢ МЕҢЬЕЛЛЫГЫ: ИСКИТКЕЧ БӘЙРӘМ!

2005 елда Казанның 1000 еллыгын бәйрәм иткәннән соң, Татарстан төрледән-төрле дөньякүләм вакыйгаларны үзенә җәлеп иткән, аларны лаеклы үткәрә торган үзәккә әверелде. Төрле шәһәрләрдән һәм илләрдән килгән күпсанлы кунаклар биредәге матурлыкны, уңайлылыкны һәм кунакчыл мохитне күрделәр. Ә инде чираттагы унъеллыкта ук Казан спорт башкаласына һәм туристлык Мәккәсенә әвереләчәк әле. 1000 еллык шәһәрнең фотографияләре һәм аның фонындагы селфиләр социаль челтәрләрне тутырачак, тик бу әле соңрак…

Ә башта Изге Вацлав хакимлек иткән чорга караган (чама белән 929–930 елларда сугылган) бер кечкенә чех тәңкәсе пәйда була, ул Казан Кремле территориясендәге казу эшләре вакытында табыла. Менә шуннан соң барысы да башлана инде…

Безнең буынга әлеге искиткеч истәлекле көнне — шәһәргә нигез салынуның 1000 еллыгын каршыларга насыйп булды. Калабызда, республикабызда яшәүче һәр кеше бу дулкынландыргыч һәм мөһим вакыйганы йөрәкләре белән кичереп, бәйрәмгә әзерлек эшендә кулдан килгәнчә катнашсын — туган һәм яраткан Казаныбыз өчен, кечкенә булса да, ләкин үзенең ихлас бүләген әзерләсен иде. Без Татарстан башкаласының туган көнен бәйрәм итүгә бәйле теләсә нинди ярдәмгә, теләсә нинди тәкъдимнәргә, теләсә нинди идеягезгә шат булачакбыз.

Камил Шамилевич Исхаков, Казан шәһәре администрациясе башлыгы, 2000 ел.

Казан мэры Камил Исхаков өч нульле юбилей тәкъдимен күтәреп чыкты, һәм ул Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев белән бергә тантананың төп оештыручысы булды. 1999 елда, Россия Президенты Борис Ельцин указы нигезендә, бәйрәм итүгә әзерлек өчен дәүләт комиссиясе төзелде. Аннан соң федераль максатчан программа кабул ителде. Әнә шул программа ярдәмендә шәһәр метрога, Кол Шәриф мәчете, «Миллениум» күпере, яңа ипподром, «Татнефть Арена», Меңьеллык паркы, Меңьеллык мәйданына ия булды. Шулай ук Петербург урамы, Үзәк стадион, шәһәр Ратушасы, Татарстан Министрлар Кабинеты, елга, шәһәр яңы тимер юл һәм автобус вокзаллары, халыкара аэропорт биналары реконструкцияләнде, Дәүләт Эрмитажы филиалы һәм Казанның Меңьеллык музее ачылды, шәһәрнең үзәк өлешендәге урамнарга реставрация ясалды.

Казанның меңьеллыгы — һич тә арттырып әйтү түгел, дөньякүләм масштабтагы зур вакыйга. Минемчә, бу хәтта халыкара вакыйга да. Шуңа күрә уртак бурычыбыз — әлеге юбилей тантаналарын, чыннан да, бу бөек шәһәр өчен дә, Татарстан Республикасы өчен дә истә калырлык, лаеклы вакыйгага әйләндерү. Шулай ук бөтен Россия өчен дә.

Владимир Владимирович Путин, Россия Федерациясе Президенты, 2005 ел.

Ә юбилей ничек узды? 2005 елның августында Казанның 1000 еллыгын бәйрәм итү уңаеннан рәсми чараларга аккредитация үткән «МК в Татарстане» газетасы фотохәбәрчесе Камилла Вилданова истәлекләреннән күренгәнчә, бәйрәм искиткеч зур һәм колачлы була! Һәм шактый озак – атна буе бара! 24 августта бәйрәм итә башлыйлар. Казанда һәр көнне тантаналы рәвештә нидер ачыла – йә метроның яңа станциясе, йә «Миллениум» күперенең беренче өлеше, йә Меңьеллык паркы…

Путин Казан метросын сынаган арада, казанлылар исә, юбилей датасына туры китереп, 1000 килограмм итеп әзерләнгән бинһаә зур чәкчәкне татып карады.

Чәкчәктән авыз иткәч, дәррәү ипподромга юл тоттылар. Аның ачылышы бик зурлап уздырылды. Шулай ук Россия Президенты призына беренче ат чабышлары да калышмады. Трибуналар гөрләде, казанлылар белән бергә Россия һәм Татарстан Президентлары дә рәхәтләнеп җан атып торды.

Көн саен Казанның бөтен җирендә: Бауман урамында, яңа Меңьеллык мәйданында, иске Ирек мәйданында, Болакта, Милли-мәдәни үзәк янында, паркларда концертлар куелды. Юлы уң килгән кешеләр хәтта легендар Scorpions төркемен дә ишетү бәхетенә ирешә – беренче билетсыз-нисез!

Колачлы бәйрәм 30 август кичендә мең залптан торган салют һәм лазерлы тамаша белән тәмамланды. Мондый шоуларны сөючеләр аны хәзер дә дөньядагы иң шәп, иң текә тамаша дип саный. Искиткеч салют тантаналарның тәмамлануын гына түгел, Казанны биш елга якын вакытка камап алган зур-зур төзелешнең тәмамлануын да билгеләп үтте. «Тәзекләндерү»дән соң шәһәрдә тормыш тагын да матурланды һәм уңайлырак булды. Шуның белән бетте дисезме? Ул чакта безне тагын да зуррак, колачлырак төзелешләр – юлларны ремонтлау, юл чатлары, спорт объектлары төзү көтәнен беркем дә белми иде, ләкин монысы инде – киләсе буын тарихы.

Мин Казанны яратам. Минемчә, Россиянең иң матур шәһәрләреннән берсе ул. Аэропорттан килгәндә үк шаккаттым: бөтен шәһәр — бер зур төзелеш бит! Меңьеллыкка берьюлы сигез йөздән артык объект төзелә.

Сергей Кириенко, РФ Президентының Идел буе федераль округындагы Тулы вәкаләтле вәкиле, 2004 ел.

Бәхетлеләргә легендар Scorpions группасы концертына эләгү дә тәтеде – менә шулай көтмәгәндә, билетсыз гына!

Колачлы бәйрәм 30 август кичендә мең залптан торган салют һәм лазерлы тамаша белән тәмамланды. Мондый шоуларны сөючеләр аны хәзер дә дөньядагы иң шәп, иң текә тамаша дип саный.

“Казанның искиткеч архитектура һәйкәлләре, шулай ук Татарстанда сакланган фольклор гадәт-йолалары бөтен дөнья җәмәгатьчелеге өчен зур әһәмияткә ия. Аларның күпмилләтле һәм күпдинле төбәктә саклануы бик мөһим. Минемчә, Казанның тиңсезлеге 100 дән артык милләт вәкилләренең тыныч-тату бергәлегендә, һәм бу факт үрнәк итеп алырга лаек.

Коитиро Мацуура,
ЮНЕСКО генераль директоры,
2005 ел.

2000 нче еллар

ЯҢАЛЫКЛАР

2000

АК КРЕМЛЬНЕҢ ЯКЛАУЧЫСЫ БАР!

2000 елның ноябрендә Казан Кремле ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы объектлары Исемлегенә кертелде. Шул рәвешле аның диварларында – республикада беренче тапкыр – әлеге оешманың тамгасы барлыкка килде.

Исемлеккә кертү турындагы карар Бөтендөнья мирасы Комитетының Австралиянең Кэрнс шәһәрендә узган 24 нче сессиясендә кабул ителде. «300 катнашучының һәркайсы алдында Казан Кремле турында икешәр буклет ята иде. Конгресс-үзәкнең фойесындагы экраннардан ике генә сюжет күрсәтелде: Австралиянең ул елны номинациягә эләккән Зур Барьер рифы белән Казан Кремле ансамбле турында», – дип искә алачак ул көнне Татарстаннан барган делегат, «Казан Кремле» музей-тыюлыгының баш архитекторы Рөстәм Зәбиров. Татарстан объекты Исемлеккә бернинди икеләнүләрсез кабул ителә. Әзерлек эшләрен Минтимер Шәймиев шәхсән үзе контрольдә тоту нәтиҗәсендә барысы да җиңел һәм шома уза.

Казанда ЮНЕСКО тамгаларын тапшыру тантанасына берничә мең кеше җыела. Соңрак Парижда ЮНЕСКОның штаб-фатирында Татарстан көннәре үткәрелә. Халыкара чиновниклар безнең республика халыкларының мәдәниятенә сокланә һәм, милли ризыклардан авыз итеп, бик канәгать кала, ә ЮНЕСКОның генераль директоры Коитиро Мацуурага татар халаты белән түбәтәе бик килешле булып чыга.

2002

«КЫЮ КЕШЕЛӘР» КАМА АША КҮПЕР САЛА

2002 елның 18 октябрендә Саескан Тавы бистәсе янында Кама өстеннән ярын бөтенләйгә ташлап китүче паромның саубуллашу гудогы яңгырый. Коеп яуган яңгыр астында тантаналы рәвештә автомобильләр йөри торган яңа күпер ачыла.

Аны төзү эшләре өч тапкыр планга кертелә. Беренче тапкыр – 1930 нчы елларда, икенчесендә Ромашкино чыганагында нефть чыгара башлагач. Өченчесендә уңышка ирешәләр, гәрчә төзелеш эшләре бик авыр 1990 нчы елларга туры килсә дә. Кризисның иң кыен елларында күпер төзүчеләр республиканың олы хыялын тормышка ашыра!

Төзелешнең сметада күрсәтелгән бәясе 270 миллион доллар тәшкил итә. Күпер төзелеше башлангычын үз кулларына алган ТРның беренче Президенты Минтимер Шәймиев әйткәнчә, «...мондый проектны үтә кыю кешеләр генә башкарып чыга ала».

Әмма нәтиҗәсе шуңа торырлык та! Бик күпләр әле паромга җыелган чиратларны хәтерлидер. Кыш көне боз аша авырлыгы биш тоннадан азрак булган машиналарга гына чыгарга рөхсәт итәләр иде. Ә язлый-көзли әйләнгеч юллар – Ульяновск һәм Яр Чаллы аша йөрделәр.

Яңа күпернең төп бурычы – республика юлларын тоташтыру. Казаннан Татарстанның көньяк-көнчыгышына барыр өчен берничә тапкыр азрак вакыт кирәк була башлады.

Тормыш алып бару өчен гаять әһәмиятле объектның кулланылышка керүе республикадагы проблемаларны гына түгел, ә федераль дәрәҗәдә бурычларны да хәл итте. Күпер Идел белән Урал арасын якынайтты, республиканың бик күп предприятиеләре өчен чын мәгънәсендә яңа сулыш булды.

Күпер төзелешенең икенче чираты 2003 елда башланып, 2016 елның 30 августында төгәлләнде. Рәсми рәвештә ачылган күпердән, беренче булып, җиңел машинада Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов узды.

2007

«АЛАБУГА». БЕРЕНЧЕ АДЫМ

2007 елның 20 ноябрендә «Алабуга» махсус икътисади зонасын рәсми рәвештә ачу тантанасы узды.

Россиянең сәнәгать-җитештерү тибындагы иң яхшы махсус икътисади зонасы булып танылачак «Алабуга» МИЗын тантаналы рәвештә Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев һәм Махсус икътисади зоналар белән идарә итү буенча федераль агентлык җитәкчесе Михаил Мишустин ачты. Биредә тагын бер чын мәгънәсендәге олы вакыйга моннан бер ел элек булган иде: анда 2006 елда беренче резидент – «Северсталь-Елабуга» компаниясе теркәлгән иде.

Проектның уңышы нигезендә барлык структураларның үзара килешеп эшләве ята. «Алабуга»ның үсешенә федераль үзәк тә, республика да, җирле хакимиятләр дә үз өлешен кертте.

– «Алабуга» МИЗның оешуында ул вакытта Татарстанның Премьер-министры вазыйфасын башкаручы Рөстәм Миңнехановның өлеше зур булды, – ди «Алабуга» МИЗның генераль директоры Тимур Шаһивәлиев. – Икътисади зонаны булдыру буенча дәүләт органнары вәкилләре җыелган киңәшмәләрнең берсендә ул болай диде: «Кем МИЗга каршы – шул миңа каршы!»

Алабугада махсус икътисади зона булдыру турында карар Татарстан проекты беренче ике МИЗ булдыру бәйгесендә җиңгәч кабул ителә. Хөкүмәт карары 2005 елның декабрендә чыга, ә инде гыйнварда РФ Икътисади үсеш һәм сәүдә министрлыгы, ТР Хөкүмәте һәм Алабуга муниципаль районы хакимияте өчьяклы килешүгә кул куя. Килешү нигезендә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы МИЗның инженерлык, транспорт һәм социаль инфраструктурасын бергәләп финанслау турында йөкләмә ала.

Бүген «Алабуга» – илдәге иң нәтиҗәле эшләүче МИЗ. Сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисади зоналар территорияләрендә гамәлгә ашырылган инвестицияләрнең гомуми күләмендә «Алабуга» өлеше (2019 елның 1 гыйнварына) 52,6 процент тәшкил итә; җитештерелгән керемнәрнең гомуми күләмендәге өлеше – 77,6 процент. «Алабуга» МИЗ – эш урыннары булдыру буенча лидер: аның территориясендә 33 җитештерү предприятиесе эшли.

2008

АЛТЫН КЫСАЛЫ «РУБИН»

2008 елның 2 ноябрендә бөтен Татарстан шатланды: Казан «Рубин»ы үз тарихында беренче тапкыр футбол буенча ил чемпионы булды!

Раменское шәһәрендә «Сатурн» капкаларына алтын голны финал сыбызгысы сызгырыр алдыннан гына Саво Милошевич кертте – Казан җанатарлары аны беркайчан да онытмаячак. Кунаклар файдасына 2:1 – чемпионат ахырына кадәр өч тур кала, «Рубин» алтын таҗны киеп карый. Корбан Бердыев җитәкчелегендәге команда, пьедесталдан Мәскәү һәм Санкт-Петербург клубларын төшереп, мөмкин булмаганны эшләде дияргә дә була. «Провинция»дән килгән клубның соңгы 12 елда беренче тапкыр чемпион булуы бит!

Ләкин казанлыларның җиңүе әллә ни шаккатырмагандыр да. Ниятләренең җитди булуы турында «Рубин», берьюлы җиде җиңү яулап, беренчелек башлануга ук, искәртеп куйган иде инде. Төп көндәшләре белән уеннарда алтын өчен көрәшкәндә өйдә дә, кунакта да очколар җыеп, ул үзен ышанычлы һәм җитди уенчы итеп күрсәтә алды.

– Без бәхетле! Аллага шөкер, ул безнең догаларыбызны ишетте, – диде, хисләрен тыя алмыйча, «Рубин»ның баш тренеры Корбан Бердыев, җиңүле матч тәмамлануга.

Теләсә кайсы көндәшен җиңә алырдай команда туплаган Корбан Бердыев, һичшиксез, – тарихи җиңүнең төп иҗатчысы. «Рубин»лыларның лидеры Сергей Ребровның да моның шулай икәненә иманы камил:

– Бердыев – үз эшенең остасы, ул тәүлегенә 24 сәгать футбол турында уйлый.

Казанлыларның капитаны – Сергей Семак, аны остазы бутсларын кадакка эләргә җыенган җиреннән чакырып китерә. Җанатарларның яраткан уенчысы – Макбет Сибайя. Ару-талу белми торган Гекдениз Караденизе. «Кысаларда» иң ышанычлысы – Сергей Рыжиков... Алар һәм аларның командадагы иптәшләре җиңү өчен булдыра алганның барысын да эшләде. Хәтта аннан да күбрәк.

Алда исә команданың тагын бер чемпионлыгы, Суперкубок һәм Россия Кубогы өчен уеннарда җиңүләре, «Камп Ноу» стадионында «Барселона» белән матчта тарихи җиңү. Афәрин, «Рубин»!

2008

ӘСГАТЬ ГАЛИМҖАНОВТАН ИГЕЛЕК ДӘРЕСЛӘРЕ

2008 елда Казан Кремле диварлары янәшәсендә Хәйрияче һәйкәле барлыкка килде: олаучы йөгәненнән атын тотып бара, арбада – балалар... Композициянең төп герое – Әсгать Галимҗанов һәйкәлне ачу тантанасында үзе дә катнашты, һәм ул бик бәхетле иде. Ул үзен бәхетле дип саный иде. «Үземнең бердәнбер – кешеләргә ярдәм итү максатымны тормышка ашырдым», – дип әйтә иде ул.

Казанның гап-гади колхоз базары олаучысын Лев Толстой исемендәге алтын медаль белән бүләкләделәр: ул да Тереза ана, Юрий Никулин, Астрид Линдгрен, Сергей Михалков, Альберт Бруно Сэйбин кебек балаларны яклауга үзеннән зур өлеш керткән.

Әсгать Галимҗанов 1936 елның 2 мартында Апас районының Болын-Балыкчы авылында туган, үзе исән чагында ук легендага әверелгән. Олаучы булып эшләгән һәм балалар йортларына ярдәм иткән. Аларга җиләк-җимешләр, автомобильләр, автобуслар сатып алган. Акчаны үз өе

янындагы сарайда дуңгызлар һәм үгезләр үстереп сатудан эшләгән. Хайваннарга ризыкны базарда җыйган калдыклардан юнәткән. Ялсыз эшләгән, яшәве дә бик тыйнак булган, ит тапшырудан кергән акчасын бөтенләе белән диярлек хәйриягә биреп бетереп барган. Берничә дистә ел эчендә балалар йортларына 80 нән артык машина сатып алып бүләк иткән. Әрмәнстандагы җир тетрәү корбаннарына булышкан, Чернобыль афәтендә каза күрүчеләргә ярдәм иткән, «Курск» су асты көймәсендә батып үлгән диңгезчеләрнең туганнарына ярдәм иткән... Туган авылында кипкән күлне яңадан торгызырга ярдәм иткән, балалар бакчасына бина төзеткән, мәчеткә хәйрия ярдәме күрсәткән. Гомере буена Казанда уңайлыклары булмаган иске агач йортта яшәгән, гәрчә хакимият аңа фатир да бүләк иткән. Галимҗанов аны Казахстаннан кайткан күпбалалы качаклар гаиләсенә бүләк иткән...

«Татарстан» журналының махсус проекты

2010 нчы еллар

БУЫННАР

ЦИФРЛЫ БУЫН

Ничек итеп «Яңарыш» үткәннәрне яңартты? Ничек итеп Казан спорт башкаласына әйләнде? Ничек итеп халыкара масштаблы вакыйгалар Казанга килде? Республиканың кайсы объектлары ЮНЕСКО мирасы Исемлегенә керде? Ничек итеп парклар, скверлар һәм яр буйлары Татарстанның йөзен үзгәртте? Үзизоляцияне ничек үткәрәбез? Милли проектлар Татарстанга нинди файда китерә?

ХРОНОГРАФ

2010

- Рөстәм Миңнеханов Татарстан Президенты вазифасына кереште
- Татарстан Республикасының Тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрен яңарту республика фонды булдырылды. Борынгы Болгар һәм Свияжск утрау-шәһәрен яңарту – өстенлекле бурыч. Фондның попечительләр советына ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев җитәкчелек итә
- РФ Президенты Владимир Путин «Казан Арена» стадионының нигезенә беренче ташны салды

2011

- «ТАНЕКО»ның беренче комплексы – Түбән Камада нефть эшкәртү һәм нефть химиясе заводлары комплексының бер өлеше сафка бастырылды

2012

- Булачак Иннополис IT-шәһәренең нигезенә капсула салу тантанасы үтте. Тантанада РФ Премьер-министры Дмитрий Медведев һәм ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашты
- «ТАНЕКО» комплексы нефть эшкәртү буенча проекттагы 7 миллион тонна куәтенә чыкты. Татарстан Россиядә нефть эшкәртү күләме буенча алтынчы урында тора
- «Казан» Халыкара аэропортында елына 1,2 миллион пассажир үткәрергә сәләтле 1А терминалы сафка басты

2013

- «Казан Арена» стадионы сафка басты. 45 мең тамашачы сыйдырышлы стадион 36 ай эчендә төзелеп бетте
- Казанда Бөтендөнья Җәйге универсиадасы узды. Универсиадага әзерлек кысаларында Татарстан башкаласында 29 спорт объекты кулланылышка тапшырылды

2014

- Борынгы Болгар ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы Исемлегенә керде

2015

- Татарстан Президенты сайлауларында сайлаучыларның 94,4 процент тавышын җыеп, Рөстәм Миңнеханов җиңеп чыкты

Фото: Марсель Бадыйкшин

• Татарстанның 2030 елга кадәрге социаль-икътисади үсеше Стратегиясе кабул ителде

• Казан су спорт төрләре буенча дөнья чемпионатын кабул итте

• Югары Ослан районында рәсми рәвештә Иннополис ачылды

• Менделеевскида «Аммоний» заводы сафка басты. Объектның бәясе 1,4 миллиард доллар

• Республикада 75 яңа парк һәм сквер барлыкка килде, тагын 65енә капиталь ремонт ясалды. Татарстанда Парклар һәм скверлар елының нәтиҗәсе шундый булды

• ТР Президентының Болгар Ислам академиясен булдыру һәм Казан Изге Мәрьям Ана иконасы чиркәвен торгызу турында Указы чыкты

2016

• Саескан Тавы янында Кама елгасы аша күпернең икенче чираты сафка басты

• Су саклау зоналарын тәртипкә китерү программасы кысаларында республиканың 21 районында 21 яр буе төзекләндерелде

• Көнкүреш техникасы җитештерү буенча дөньякүләм танылган Haier компаниясе Яр Чаллыда суыткычлар җитештерү буенча заводын ачты

2017

• Свияжск утрау-шәһәрендә Успение чиркәве ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы Исемлегенә кертелде

• Болгар Ислам академиясе ачылды

2018

• Лаеш районында «Россия почтасы» логистика үзәге ачылды

• КАМАЗда К-5 яңа буын «КАМАЗ» йөк машиналарына куела торган кабиналар каркасы заводы кулланылышка тапшырылды. Яңа кабиналар Mercedes-Benz йөк машиналары җыю заводы өчен дә җитештерелә

• Казан авиация заводында Ту-160М яңартылган самолетлары төзелеше башланды

• Казанда футбол буенча дөнья чемпионатының алты матчы үтте

• «Казан Экспо» Халыкара күргәзмәләр үзәге сафка басты

2019

• Казан вертолет заводында җыелган серияле Ми-38 вертолетларының беренчеләре заказчыга озатылды

• Казанда WorldSkills стандартлары нигезендә һөнәри осталык буенча дөнья чемпионаты үтте

• Республикада полилингваль мәктәпләр төзелешләре башланды. Алты полилингваль комплекс булдыру планлаштырыла: Казанда (2), Яр Чаллыда, Түбән Камада, Әлмәттә, Алабугада

• Татарстан Дәүләт Советына алтынчы чакырылыш депутатлар сайланды

• ТР Президенты Указына кул куелды: 2020 ел ТАССР төзелүнең 100 еллыгы елы дип игълан ителде

2020

• Республикада ишегалларын төзекләндерү буенча Татарстан Президентының «Безнең ишегалды» уникаль программасы эшли башлады

: ТАССР га 90ел : шәхес

«Татарстан» архивыннан

«Идарә итүнең иң яхшы рецепты – тәҗрибә һәм яңалык кертүнең бердәмлеге»

Юрий НИКОЛАЕВ
тексты

ОЧРАШУЛАР, СӨЙЛӘШҮЛӘР, КИҢӘШМӘЛӘР, ЭШЛЕКЛЕ СӘФӘРЛӘР... ТАТАРСТАН ПРЕЗИДЕНТЫНЫҢ ЭШ ГРАФИГЫ ШУЛКАДӘР ТЫГЫЗ КИ, БЕР ГЕНӘ БУШ МИНУТЫ ДА ЮК СЫМАН... ШУЛАЙ ДА УЛ ХӘБӘРЧЕБЕЗ СОРАУЛАРЫНА ҖАВАП БИРЕРГӘ ВАКЫТ ТАБА АЛДЫ.

– Бүгенге көндә сәяси курсның дәвамчанлыгы турында шактый күп сөйлибез, ә шулай да Татарстанның яңа Президенты сәяси идарә дилбегәсен үзенчә тотмас дигән шик тумый. Якын киләчәктә сәяси идарәчеләр командасы яшәрүен көтәргәме?

– Дәвамчанлык – бик яхшы төшенчә, ул минем күңелемә якын. Һәр эштә элгәрләр – бу эшне синнән алданрак башлап җибәргән кешеләр була. Уңышлы сәясәтчеләр, кагыйдә буларак, шул ягы белән аерылып тора: алар үзләренең эшгамәлләрен үзеннән алдагылар тәҗрибәсенә таянып башкарырга омтыла.

Безнең илдә, кызганычка күрә, берничә мәртәбә теге яки бу лидерның, дәвамчанлык турында купшы сүзләр сөйләп тә, соңыннан бөтенесен үзгәрткәне булды. Моңа мисаллар җитәрлек. Сүз уңаеннан шунысын да искәртим, чыннан да кайвакытта үзгәрешләр кертергә кирәк була, һәм шактый дәрәҗәдә кискен.

Минем үземә икеләтә уңай туры килде, дип саныйм. Барыннан да бигрәк, бик әйбәт мирас насыйп булды: республикабыз күтәрелеш чорында. Моннан тыш, үзем дә шактый озак еллар дәвамында хакимияттә икенче кеше буларак хезмәт иттем. Шунлыктан, сез әйткәнчә, минем «дилбегә тоту» стилем күптәннән билгеле. Аңа Хөкүмәт әгъзалары да, аппарат хезмәткәрләре дә күнеккән инде.

Төбәк дәрәҗәсендәге җитәкчелектә тулы мәгънәсендә сәяси идарәчеләр аз, чөнки сәяси функцияләр, нигездә, федераль хакимият җаваплылыгына туры килә. Кадрлар составын яшәртү процессы барырга тиеш, әмма механик юл белән түгел. Идарә итүнең иң шәп рецепты – тәҗрибә һәм яңалык кертүнең үзара ярашуында. Яшь мәсьәләсе бередә бердәнбер критерий була алмый.

– Татарстанның совет чорыннан соңгы кайсы казанышын иң әһәмиятле һәм киләчәктә дә үсешен дәвам иттерерлек дип саныйсыз?

– Республиканың соңгы егерме ел эчендәге барлык казанышларының нигезе – аның икътисадый мөстәкыйльлеккә ирешүедер дип саныйм. Үз хуҗалыгыбызда хуҗа булмагандагы хәл нормаль түгел иде.

Совет чорында икътисадый карарларны кабул итүнең никадәр мәшәкатьле, күп катлы килештерүләр аша узарга тиеш булуын күпләр хәтерли торгандыр. Күпме вакыт, көч сарыф ителгән... Җентекле регламентлаштыру мәрәкәсе теләсә нинди инициативаны тамырында ук корытты.

Солтан ИСХАКОВ фотолары

Шунлыктан республиканың яңа статусы һәм аның заманча икътисадый моделе үсеше — бер медальнең ике ягы.

Төп рольне базар механизмнары уйнаган, алдынгы технологияләргә, интеллектка таянуга корылган яңа икътисад — Татарстанның совет чорыннан соңгы иң әһәмиятле казанышы. Нигездә, без әле республика тормышының барлык якларын ныклап торып модернизацияләүгә керешеп кенә киләбез. Ә шулай да Татарстан җитәкчелегенең киләчәкне анык, төгәл итеп күзаллавы бар. Һәм ул үз көчебезгә ныклап ышануга корылган.

– Идарә итүегездәге төп өч принципны санап китә алмассызмы?

— Ә нишләп әле ул өч кенә, биш яки җиде түгел? Мәсәлән, Коръәндә 114 сурә. Алай да, тәртип сөюче кеше буларак, төп өч идарә принцибымны аерып күрсәтеп карыйм әле. Беренчесе — югары һөнәрмәндлек. Күпне аз-маз белүчеләр заманы узды инде. Без мәгълүмат яшен тизлегендә яңарган чорда яшибез. Ә шулай да, компетентлылык — теләсә кайсы сыйфатлы эшнең нигезен тәшкил итә, ә идарә итүдә ул аеруча әһәмиятле рольне уйный.

Икенчесе — оперативлык, җитезлек. Буш мәрәкәне, аяк өстеннән йоклап йөрүне, кәгазь колы булуны җенем сөйми. XXI гасырда яшибез, совет чоры бюрократларының «Кәгазь бераз ятарга тиеш» дигән иске принцибы — җәмгыять алдында җинаятькә тиң диярлек.

Өченчесе — җаваплылык. Карарлар кабул итү һәм аларны үтәүдән тыш, аларның нәтиҗәләрелегә өчен дә үз өстеңә җаваплылык алу мөһим. Һәр җиңүнең генә түгел (ул чакта, гадәттә, җиңүчеләрдән чират җыела, бигрәк тә гомумән бу эшкә катнашы булмаганнардан), җиңелүләрнең дә үз исеме булырга тиеш.

– Сезнеңчә, югары даирәдәге сәясәтченең нинди шәхси сыйфатларга ия булуы мәҗбүри, ә кайсыларының бөтенләй булмавы хәерле?

— Сәясәтче, барыннан да бигрәк, берничә адымны алдан күрү сәләтенә ия булырга һәм эш-гамәлләрен шуннан чыгып корырга тиеш. Бу — уңышка илтүче юл. Әгәр дә ул сыйфатың юк икән, инициативаны югалтачаксың һәм уңышсызлыкларыңны теркәп утыручыга әвереләчәксең.

Иң зарарлысы — үз-үзеңә кирәгеннән артык ышану. Бу кешеләрнең синнән йөз чөерүенә дә китерә, үз эшеңә дә комачаулык ясый. Гомерем буе даими рәвештә белемемне күтәрергә һәм күнекмәләремне яңартырга кирәк дип санадым. Бүгенге көндә шундый зур республиканың Президенты булгач, бу фикерем тагын да ныгыды.

– Сез ничек уйлыйсыз, Россиянең башка төбәкләрендә Татарстан шартларында кулланып карарлык кызыклы сәяси идарә тәҗрибәсе бармы? Әгәр дә булса, кемнеке һәм аны ни рәвешле итеп кулланып булыр иде?

— Чит төбәкләрнең тәҗрибәсе һәрвакыт кызыклы. Коллегаларыбызга хөрмәт белән карау — сәясәтебезнең төп принцибы. Нәкъ менә шуңа да без башкаларның үз проблемаларын, шул исәптән сәясиләрен дә, ни рәвешле хәл итү юлларын даими өйрәнәбез.

Татарстанның күп төбәкләр белән төзегән килешүләре әлеге җәһәттән эшебезгә бик зур ярдәм итә. Алар даими рәвештә мәгълүмат алмашуны, төрле өлкәләрдә хезмәттәшлек итүне, сәүдә-сәнәгать вәкиллекләре ачуны күздә тота.

Еш кына күршеләребез янына сәфәргә чыгабыз, аларның делегацияләрен дә үзебездә кабул итәбез. Мондый аралашу бер-береңне баета.

Шунысын аерып әйтә алам, Мәскәүдә, Санкт-Петербургта, шактый гына республикаларда һәм Идел буе, Урал өлкәләрендә кабул ителгән идарә итү формалары һәм алымнары бездә аеруча зур кызыксыну уята.

Үзебезнең Татарстанда да шактый кызыклы нәрсәләр бар, билгеле, әмма без камиллеккә ирештек инде дип уйлаучылар бик нык ялгышалар. Камиллеккә чикләр юк, яхшылыкка даими рәвештә өйрәнергә кирәк.

– Командагыз әгъзаларының кайсы сыйфатларына өстенлек бирәсез – тиз һәм сыйфатлы итеп кушканны үтәгәнгәме, әллә инициатива һәм мөстәкыйльлек күрсәткәнгәме?

— Минемчә, бу төшенчәләрне капма-каршы куярга ярамый. Әгәр дә: «Юлбашчының кушканын аңласаң — үтә, аңламасаң — бигрәк тә үтә» принцибына таянып эшләү — упкынга илтүче юл. Икенче яктан караганда, инициативалылык һәм мөстәкыйльлек бары тик үзеңне күрсәтү өчен генә булганда, шулай ук куркыныч гамәл.

Бүгенге көндә дәүләт идарәсе шулчаклы катлауланды ки, анда бер генә кеше чыгарган карарлар күз ачып йомганчы искерә, кичәге көн күренешенә әверелә бара.

Әйдәман энциклопедияче була алмый, аңа төпле киңәш бирүче кирәк. Кул астындагылар белән эшләгәндә барыннан да бигрәк, аларга ышану зарур. Карарлар кабул итүне ышанып тапшы-

Минем үземә икеләтә уңай туры килде, дип саныйм. Барыннан да бигрәк, бик әйбәт мирас насыйп булды: республикабыз күтәрелеш чорында. Моннан тыш, үзем дә шактый озак еллар дәвамында хакимияттә икенче кеше буларак хезмәт иттем. Шунлыктан, сез әйткәнчә, минем «дилбегә тоту» стилем күптәннән билгеле.



Сәясәтче, барыннан да бигрәк, берничә адымны алдан күрү сәләтенә ия булырга һәм эш-гамәлләрен шуннан чыгып корырга тиеш. Бу – уңышка илтүче юл. Әгәр дә ул сыйфатың юк икән, инициативаны югалтачаксың һәм уңышсызлыкларыңны теркәп утыручыга әвереләчәксең.



рырлык кешеләр күбрәк булган саен, эш өчен яхшырак.

Билгеле инде, аеруча мөһим карарлар кабул иткәндә, соңгы сүзне закон тарафыннан бу вәкаләт йөкләтелгән шәхес әйтергә тиеш.

Шулай итеп, кул астымдагыларның оперативлыгын да, инициативага һәм мөстәкыйль эш-гамәлләргә сәләтлелеген дә бердәй бәялим.

– Республикабызның 90 еллык тарихындагы кайсы күренекле вакыйганы аеруча әһәмиятле дип саныйсыз?

— Күренекле вакыйгалар күп булган. ТАССР төзелү. Бөек Ватан сугышында җиңү — уртак казанышыбыз. Татарстан нефтенең беренче фонтаны. КамАЗ төзелү. Үткән гасыр азагында яңа дәүләтчелекнең аякка басуы. Казанның 1000-еллыгы. Безнең командаларның зур спорт өлкәсенә ыргылышы.

Минемчә, бер-берсенә нык бәйләнешле ике вакыйга аеруча зур символик мәгънәгә ия. Болар — Казан Кремленең ЮНЕСКОның Бөтендөнья мирасы һәйкәлләре исемлегенә кертелүе һәм Кремль эчендә Кол Шәриф мәчете төзелү. Нәкъ менә әлеге вакыйгалар аша безнең халыкара кимәлдә танылуыбыз һәм буыннар-чорлар чылбырын ялгавыбыз ап-ачык күренә. Бу безнең республиканың яңа сыйфат дәрәҗәсенә аяк басуын раслый. Халкыбыз моңа лаек.

– Яңа вазыйфаларын тиешенчә үтәү өчен, республикада иң югары кәнәфине биләүче сәяси әйдәманга нәрсәдән ваз кичәргә туры килә: якыннары белән аралашуданмы, яраткан шөгыленнәнме, гадәти тормыш рәвешеннәнме?

— Югары җаваплылык белән бәйле эш башкаручы теләсә кемнең иң зур югалтуы — ул аның шәхси тормышы. Без — үзебезгә үзебез хуҗа, дип әйтеп булмый. Хәер, мин «даими хәрби әзерлекне» таләп иткән мондый яшәү рәвешенә күптәннән күнектем инде.

Заманча аралашу чаралары эшемне бик нык җиңеләйтә. Кайберәүләр минем үз эшемне компьютердан, сыйфатлы элемтәдән башка күз алдына да китерә алмавымны күптән беләләр. Электрон документлар әйләнеше кертә алуыбыз һәм аның нәтиҗәлелеген арттыруыбыз белән горурланам. Идеалда кешеләр дәүләт органнарының сыйфатлы хезмәт күрсәтүеннән, түрәләр каршына баш иеп бармыйча да, файдалана алырга тиешләр. Азынуларга юл калдырмыйча...

Билгеле инде, заманча аралашу чаралары эшне беркадәр җиңеләйтә төшсәләр дә, бераз онытылып тору, үз-үзеңә аз гына ял бирү кебек уңайлылыклардан мәхрүм итәләр.

Бик күпләрнеке кебек үк, минем дә көч бирүче җылы учагым — гаиләм. Хатыным, балаларым, якын туганнарым белән аралашуның һәр минутын зур бәхеткә саныйм. Гомер буе актив тормыш рәвеше алып барам. Физик һәм интеллектуаль яктан көч җыюның тагын бер ышанычлы алымы — спорт белән шөгыльләнү.

– Бүгенге көндә нинди сәяси, икътисадый яки социаль мәсьәләне хәл итүгә өстенлек бирергә кирәк дип саныйсыз?

— Алдагы елларга иң мөһим бурычларның бурычы — икътисадны модернизацияләү, шуның нигезендә яшәешнең яңа стандартларына юл ачу. Моның өчен республикабызда барысы да бар: бик зур җитештерү мөмкинлекләре, күпкырлы реформалаштыру тәҗрибәсе, көчле идарәче кадрлар, гасырлардан килгән бай мәдәни традицияләр. Фидакарьлеккә дә нигезләр җитәрлек.

Әмма берүк вакытта җәмгыятьтә үзгәртеп корулардан күпмедер дәрәҗәдә ару-таю галәмәте, халыкның бер өлешендә реформа нәтиҗәләреннән канәгатьсезлек хисе күзәтелә. Шулай да җилкәләребезне турайтып алга баруыбызны дәвам итмәсәк, бүгенге замана арбасыннан бөтенләйгә төшеп калуыбыз ихтимал икәнлеген аңларга ки-

Алдагы елларга иң мөһим бурычларның бурычы – икътисадны модернизацияләү, шуның нигезендә яшәешнең яңа стандартларына юл ачу. Моның өчен республикабызда барысы да бар.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ФЕДЕРАТИВ РОССИЯ СОСТАВЫНДАГЫ РОЛЕН АЕК АКЫЛ БЕЛӘН БӘЯЛӘҮ МӨҺИМ. МИНЕМ УЙЛАВЫМЧА, МӘСКӘҮДӘ ДӘ, КАЗАНДА ДА, ҖАВАПЛЫ КЕШЕЛӘР ӘЛЕГЕ МӘСЬӘЛӘГӘ НӘКЪ МЕНӘ ШУЛ КҮЗЛЕКТӘН ЧЫГЫП ЯКЫН КИЛЕРГӘ ОМТЫЛА.



Сингапурның остаз-министры Ли Куан Ю миндә, яшь һәм кыю рәвештә үсешкә юл яручы дәүләтнең үзе шикелле үк, көчле тәэсирләр калдырды.

рәк. Болары — шигарь түгел, ә тормышның кырыс чынбарлыгы.

Берәү дә безнең арттан этәргә, кашыктан ашатырга җыенмый. Бөтенесен үзебезгә эшләргә кирәк булачак.

– Татарстан Россия төбәкләре арасында элек тә, хәзер дә, сәяси яктан да, икътисадый кимәлдә дә, аерылып тора. Киләчәктә дә әлеге үзенчәлекне – өстенлекле статусны саклап калырга өметләр зурданмы?

— Россия төбәкләренең һәркайсы кай ягы белән булса да аерылып торадыр, мөгаен. Илебез мәдәни төрлелеге ягыннан кабатланмас үзенчәлеккә ия. Татарстан Республикасының федератив Россия составындагы ролен аек акыл белән бәяләү мөһим. Минем уйлавымча, Мәскәүдә дә, Казанда да, җаваплы кешеләр әлеге мәсьәләгә нәкъ менә шул күзлектән чыгып якын килергә омтыла.

Шул ук вакытта мин республикабыз статусына бәйле рәвештә «өстенлекле» сүзен кулланмас идем. Кайберәүләр шикләнеп караса да, Татарстан беркайчан да моңа омтылмады. Сүз искиткеч зур җаваплылык дәрәҗәсе хакында барырга тиеш. Без һәрчакта да шуннан чыгып фикер йөртергә тиешбез: әгәр дә республикабыз теге яки бу проблеманы хәл итәргә алынган икән, әлеге эш иң югары дәрәҗәдә, төгәл һәм сыйфатлы итеп, реаль вакыт кысаларына сыешып, хокук нормаларын бозмыйча башкарылырга тиеш.

Казанның 1000-еллыгы турында сүз барамы, әллә «Универсиада-2013» программасы үтәлеше турындамы, яисә торак пунктларны газлаштырумы, яки тузган торактан котылумы — моңарчы барысы да хәлебездән килде. Минемчә, бу халәткә ияләшә башладылар инде. Партнерларыбызның безнең сүзгә, мөмкинлекләребезгә ышануы — бик күңелле. Ышанычка ия булуыбыз — Россия Федерациясе җитәкчелеге белән үзара мөнәсәбәтләрне урнаштыруда искиткеч зур капитал ул. Моңа таянып, киләчәккә өмет белән карап була.

– Үткән заманның яки бүгенге көннең дөньякүләм танылган, зирәк аксакал дәрәҗәсенә ия сәяси әйдәманы белән очрашу мөмкинлеге туды дип күз алдына китерсәк, кемнең фикерен яки акыллы киңәшен тыңларга теләр идегез?

— Бүгенге көндә дөньяда икътисадый вазгыять шактый катлаулы, аның 1929-1933 еллардагы дөньякүләм икътисадый кризис белән уртак сыйфатлары шактый зур булганга, миңа Франклин Рузвельт белән аралашу бик кызыклы булыр иде. Гомумән алганда, бу кеше турында мәгълүмат шактый зур, әмма кризис чорында идарә итү буенча аның шәхси тәҗрибәсе бүгенге көндә бик кирәкле булыр иде дип уйлыйм.

Ә бүгенге көндәге сәясәтче-зирәк аксакалларга килгәндә, минем хыялда гына түгел, ә чынбарлыкта, республикабызның беренче Президенты Минтимер Шәрип улы Шәймиев белән даими рәвештә аралашу мөмкинлегем бар. Ул — минем укытучым, остазым. Аның яңа статуста зур сәясәттә калуы барыбыз өчен дә бик зур отыш дип саныйм.

Нурсолтан Назарбаевның дәүләти дәрәҗәдә фикер йөртүе миндә аңа карата зур хөрмәт уята.

Сингапурның остаз-министры Ли Куан Ю миндә, яшь һәм кыю рәвештә үсешкә юл яручы дәүләтнең үзе шикелле үк, көчле тәэсирләр калдырды.

КАЗАНДА УНИВЕРСИАДА:
БӨТЕН ДӨНЬЯ БЕЛӘН БЕР КАЗАНДА

Универсиада 2013нең ачылу тантанасын масштаблары буенча Лондондагы Олимпиаданың старты белән чагыштырырга мөмкин. Тамашаның иң югары ноктасы Уеннарның утын кабызу булды. «Казан Арена» өстендәге касәдәге ялкын хоккейчы Наил Якупов, дзюдо буенча көрәшче Таһир Хәйбуллаев, волейболчы Екатерина Гамова һәм паралимпияче Ирек Зарипов факелыннан дөрләп китте.

Солтан Исхаков фотосы

СУ СПОРТ ТӨРЛӘРЕ БУЕНЧА ДӨНЬЯ ЧЕМПИОНАТЫН: «ПИЛИГРИМ» КРУТОЙСЫЗ ГЫНА БУЛМАДЫ

Россиянең халык артисты Игорь Крутой һәм куючы режиссер Алексей Сеченов җитәкчелегендә Су спорт төрләре буенча дөнья чемпионатын ачу тантанасына куелган шоуны казанлыларга һәм шәһәр кунакларына сигез тапкыр күрсәттеләр. Беренче тапкыр – тантаналы рәвештә рәсми кунакларны сәламләүләрне кертеп, калган җидесен – сәнгати эшләнеше һәм декорацияләре ягыннан уникаль спектакль буларак. «Пилигрим» дип аталган шоу берәүне дә – чемпионатта катнашучыларны да, кунакларны да, тамашачыларны да битараф калдырмады.

Фото: Максим Платонов

МУНДИАЛЬ-2018:
СИН ДӘ ОНЫТМА БУ ҖӘЙНЕ

Бер караганда, бер-бер артлы үткәрелгән олы спорт вакыйгалары Татарстан башкаласын бөтен нәрсәгә дә әзерләгән кебек иде. Әмма футбол буенча дөнья чемпионаты көннәрендә шәһәр урамнарындагы тамаша казанлыларны да, бирегә беренче тапкыр килүчеләрне дә шаккатырды...

– СЕЗНЕҢ АТА-БАБАЛАРЫГЫЗГА РӘХМӘТ!

Джанни Инфантино, ФИФА президенты, – Казанда, мэриядә киңәшмә вакытында:

– Сез дөньяның бай тарихлы һәм мәдәниятле иң матур шәһәрләренең берсендә яшисез һәм эшлисез. Сезнең ата-бабаларыгызга бәһаләп бетергесез мәдәни мирас калдырганы, ә сезгә шул мирасны кадерле белгәнегез өчен рәхмәт. Моны Россия өчен генә әйбәт үрнәк димәс идем. Бу Россиянең бөтен дөньяга унай үрнәге. Без нәрсә эшләргә һәм ничек яшәргә тиеш икәнлекне күрсәтә торган үрнәк! Шәһәрдә яшәүчеләр, футбол һәм тынычлык хакына кылган гамәлләрегез өчен зур рәхмәт сезгә!

– МИН ЧЫН МӘГЪНӘСЕНДӘ ХӘЙРАН КАЛДЫМ!

Дидье Рейндерс, Бельгиянең чит ил эшләре министры, – Бельгия җыелма командасы «Казан Арена»да җиңгәннән соң:

– Мин чын мәгънәсендә хәйран калдым! Казан – искиткеч матур шәһәр. Биредә башкала инфраструктурасы бар, сүз спорт объектлары турында гына бармый. Без нәкъ менә Казанда җиңүебезгә шат, чөнки бу шәһәрнең спорт башкаласы дигән даны бар. Һәм мин Бельгия җыелма командасына теләктәш булган бик күп татарстанлыларны күрдем.

– РОССИЯ – ИСКИТКЕЧ!

Томер Савойя, Бразилиянең иң танылган җанатары, – Татарстан журналистларына биргән интервьюсында:

Мин сезнең команда җиңгәч, русларның реакциясен күрдем. Әйе, сез ышанмадыгыз. Сез «Бу мөмкин түгел!» дидегез, әмма бик дулкынланып шатландыгыз. Бик зур бәйрәм булды! Шуның өчен дә яратам сезне. Шуның өчен дә Россия – искиткеч!

Фото: Александр Ефремов, Ната Смирнова

WORLDSKILLS KAZAN 2019:
ЧЕМПИОНАТТАН СОҢ БАР ДА КАЛА...

Казанда үткән һәр дөньякүләм вакыйгадан соң, шәһәргә истәлеккә һәм файдалану өчен шактый нәрсәләр кала. WorldSkills 2019 эшче һөнәрләр чемпионатыннан соң, Казан инфраструктурасы «Казан Экспо» Халыкара күргәзмә үзәге, иң югары халыкара стандартларга туры килүче өр-яңа җиһазлар һәм, әлбәттә инде, дөньядагы иң яхшы белгечләр белән тулыланды. Ә бу вакыйгага катнашы булган һәркемдә бөтен гомерләренә җитәрлек онытылмас тәэсирләр һәм матур истәлекләр калды. Алар бу турыда «Татарстан» хәбәрчеләре белән дә уртаклашты.

Фото Алёна Кутыркина, Александр Ефремов

КЕШЕЛӘРНЕҢ ТУГАН ИЛЛӘРЕ БЕЛӘН ГОРУРЛАНУЫН КҮРҮ-ИШЕТҮ КҮҢЕЛЛЕ

Изабель Коллин, тимлидер, Нью-Брансуик, Канада:

– Мин Канаданың Калгари шәһәрендә узган шундый ярышларда катнашкан идем. Менә хәзер, 10 ел узганнан соң, тимлидер буларак бирегә килдем. Рус кешеләренең менталитеты мине гаҗәпләндерде һәм шатландырды: алар бик җитди, төгәл һәм барысын да нәтиҗәле итеп башкаралар. Кешеләрнең үз илләре белән горурлануын күрү-ишетү бик күңелле!

БЕЗ БЕРГӘЛӘП ГАРМОНИЯЛЕ КИЛӘЧӘК БУЛДЫРЫРБЫЗ

София, робот. WorldSkills 2019 чемпионаты ачылу тантанасының махсус кунагы:

– Технология – бу дөньяны өйрәнүнең инструменты гына. Без бергәләп йолдызара чакрымнарны узып, бөтен кешеләр өчен матур һәм имин киләчәк булдыра алырбыз.

БАРЫННАН ДА БИГРӘК МИҢА САБАНТУЙ ОШАДЫ

Дан Ши, Кытай җыелма командасы әгъзасы:

– Миңа Казанда барыннан да бигрәк Сабантуй ошады – шулкадәр күп конкурсларда катнаша алуың бик шәп бит. Безнең Кытайда моңа охшаган милли бәйрәмнәр бар, һәм аларны кешеләр сездәге кебек үк күңелле итеп үткәрергә ярата.

: сәясәт : яңарыш

«ТАТАРСТАН» АРХИВЫННАН

БЕЗНЕҢ МОНДА ДА ҺӘР ҖӘҺӘТТӘН АЛДА БУЛУЫБЫЗГА ШИГЕМ ЮК!

Минтимер ШӘЙМИЕВ
тексты

Татарстан Президенты вазыйфасыннан киткәч, тарихи һәйкәлләрне — борынгы Шәһри Болгарны һәм Свияжск утрау-шәһәрчеген кабат тергезүгә ни сәбәпле алынуым хакында миннән еш сорыйлар. Чөнки без шундый хәерле эшкә тотыну өчен өлгереп җиттек, димәк, аның үз сәгате сукты. Республикабыз территориясендәге тарихи һәйкәлләрне саклау һәм реставрацияләүгә, кыюлык белән зурдан кубып, бердәм рәвештә тотынуыбыз — халкыбызның, гомумән алганда, Татарстан җәмәгатьчелегенең рухи өлгергәнлеген раслаучы ачык мисал ул. Бу эш-гамәлебез җиңеллек белән барамы? Әйтә алам: бер дә җиңел түгел. Чөнки үз-үзеңне җиңү беркайчан да җиңел була алмый. Әмма безнең иганәчелек өлкәсендә бәһаләп бетермәслек зур байлыгыбыз — якты хисләребез һәм изге эшләребез бар. Соңгы елларда башкарган игелекле эшләребез яхшылык итүдән һәркайсыбызның күңелләре яктыра төшүен, рухыбызның чистара һәм әхлагыбызның сафлана баруын сиземләргә мөмкинлек бирде.

Шунысы сөенечле: омтылышларыбыз Президент, республика Хөкүмәте тарафыннан кайнар яклау тапты, алар конкрет карарлар белән беркетелә бара. Без республикадан читтә дә теләктәшлек таптык, беренче чиратта, РФ Президенты һәм Премьер-министры тарафыннан.

Бүгенге көндә нәрсәгә ирештек һәм алдагы көннәрдәниләр башкарырга тиешбез?

Бүгенгә Болгарда да, Свияжскида да коммуникация чаралары юк дәрәҗәсендә. Шунлыктан, кичектергесез һәм беренче чиратта башкарыласы эшләргә юллар салу, елга вокзаллары төзү, газ, җылылык, чистарту җайланмалары булган канализация челтәрләрен үткәрү, өзлексез рәвештә эшләүче энергия чыганаклары белән тәэмин итүләр кирә. Музей зонасына кергән, шулай ук тузган муниципаль йортларда яшәүчеләрне күчерү өчен, торак та төзергә кирәк.

Реставрацияләнүгә һәм консервацияләнүгә тәгаенләнгән объектларда киң масштаблы төзү-төзекләндерү эшләре башлана. Моның өстенә, күпкырлы максатларны берьюлы күздә тотып эш итәргә туры килә: бик зур күләмдә казу-тикшеренү эшләре алып барырга, проект-смета документацияләре әзерләргә, бүгенге көндә реставрацияләнүче объектларда эшне дәвам итәргә һәм яңаларын моңа әзерләүне фәнни эшчәнлек

Мөхтәрәм Минтимер Шәрипович!

«ТРда тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне торгызу фонды» оешу хакындагы куанычлы яңа хәбәрне искиткеч зур канәгатьлек хисе һәм шатлык белән кабул иттем. Бүгенге Россия язмышы өчен безнең уртак мәдәни мирасыбызны саклап калу һәм дөрес итеп шәрехләүдән дә әһәмиятлерәк нәрсә юктыр. Чөнки мин шуны анык беләм: мәдәни мирас һәм тарих гавәмне берләштерә дә, кешеләрне бер-берсеннән аерып та куя ала. Ә бусы күп очракта игелекле нияттән һәм яхшы күңелле кешеләрдән тора.

Татарстанның соңгы дистә еллардагы тарихы – төрле халыкларның мәдәнияте, рухи мирасы һәм конфессияләр турында ихластан кайгыртучанлык күрсәтүнең искиткеч гүзәл мисалы ул. Болгар һәм Свияжск үзләре үк көннән-көн катлаулы сәяси үткәне булган төрле мәдәниятләрне үрелдереп үстерүнең һәм моңа дөрес караш тудыруның символларына әверелә бара. Мин шуңа ышанам: Сезнең җитәкчелегегездәге «ТРда тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне торгызу фонды», нигездә, Россия мәдәниятенең үсеш юлларын билгеләр һәм аның яңа үзенчәлекле сыйфатларына юл ачар.

Дәүләт Эрмитажы һәм Россиянең барлык музейлары Фонд белән күпкырлы хезмәттәшлек итәргә әзер, барыбыз да аңа бик зур өметләр баглыйбыз. Шәхсән Сезнең үзегезгә һәм хезмәттәшләрегезгә әлеге ифрат та игелекле эшегездә уңышлар телибез.

Михаил ПИОТРОВСКИЙ,
Дәүләт Эрмитажы директоры, РФ Президенты каршындагы Мәдәният һәм сәнгать советы рәисе урынбасары, Россиянең Музейлар берлеге президенты.

белән бәйләп алып барырга. Бу очракта Казан Кремлен реставрацияләгәндәге уңай тәҗрибәбез җитәрлек.

Бүгенге көндә Болгарда һәм Свияжскида аерым, иң күп хезмәт сорый торган тарихи һәйкәлләрне торгызуны һәм инженерлык челтәрләрен сузуны үз өстенә алырга теләк белдергән эре инвесторлар белән килешүләр төзи алдык. Иганәчеләрнең һәркайсына аерым объектлар беркетелгән беренче исемлеге кулыбызда.

19 июньдә Ислам динен кабул итүнең 1121 еллыгын бәйрәм иткәндә, Болгарда, истәлекле билге итеп, таш куелды. Ул биек яр өстендә, ерактан ук кунакларны сәламләп торачак.

Болгарда яңа мәчет тә сафка басачак. Аны проектлауны Кол Шәриф мәчете проекты авторлары Сергей Шәкүров һәм Искәндәр Сәйфуллинга йөкләдек. Әлеге мәчет биредә төзеләчәк «Болгар» мәдрәсәсе үзәгендә урнашачак. Мәдрәсә үзе исә берьюлы 30 лап шәкертка гыйлем бирә ала торган иркен һәм уңайлы үзәк булыр. Анда руханилар хәзерләп чыгару өчен бик уңайлы шартлар тудырылачак. Биредә алган гыйлемнең һәм дипломның аерым бер югары дәрәҗәгә ия булачагына шигем юк. Бөек фәлсәфәчеләр кебек, җәмгыятьтән беркадәр аерымланган шартларда гыйлем эстәгән шәкертләрнең биредә алган белемнәре ныклы буласына иманым камил. Бәлки әле киләчәктә әлеге уку йорты Россия ислам институтының филиалына әверелер. Еллар узу белән, минем уйлавымча, биредә шәйхел-ислам резиденциясе яки мөфти хәзрәтнең илебезнең руханилары белән рәсми очрашулар уздыру һәм кунаклар кабул итү өчен затлы урыны булыр. Мәдрәсәне сафка бастыруда илебезнең төрле төбәкләрендә яшәүче ватандашларыбыз катнашыр дип өметләнәбез.

Без әле Болгарда Икмәк музее төзүне дә күздә тотабыз, ул тирә-юньгә ямь биреп, туристларны үзенә тартып торачак. Ул аерым бер мәгънәгә ия. Идел Болгарстанында яшәгән борынгы бабаларыбыз нигездә утрак тормыш рәвеше алып барган, игенчелек, сатуалу, һөнәрчелек белән шөгыльләнгән. Икмәк музеен төзү эшен авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры, республиканың Премьер-министры урынбасары Марат Әхмәтов һәм агросәнәгать комплексына кергән 20 предприятие үз өстенә алды.

Әле бу арада гына өр-яңа идея туды. Шулай берчакны, Миркасыйм Госманов белән Иранга рәсми визитыбыз вакытында, Президент Мөхәммәд Хатами белән үзара сөйләшүләр алып барганда, бөек дәвачыларның 20 трактаты белән танышу мөмкинлеге мәсьәләсен кузгаткан идек. Алар арасында Болгар табибы, дәвачысы һәм галиме Таҗетдин әл-Болгариның трактаты да килеп чыгуы безнең гаҗәпләнү катыш сокланубызга сәбәпче булды. Күз алдына китерәсезме, нинди дан китерә бит бу безгә: Көнчыгышның бөек дәвачылары арасында, Әбугалисина белән беррәттән, 20 трактат авторларының берсе булып, үзебезнең Болгар дәвачысы торсын әле! Безгә ул чакта әлеге документларның күчермәләрен алырга рөхсәт иттеләр. Шундый гаҗәеп мирасыбыз булгач, минем уйлавымча, киләчәктә Болгарда Таҗетдин әл-Болгари исемендәге Дәва йорты да төзеп куярбыз әле.

Болгарда һәм Свияжскида елга вокзаллары төзелә башлады инде. Ә алардагы реставрацияләү эшләре бик озакка сузылачак. Әлеге катлаулы һәм күп чыгымнар таләп итә торган хезмәтне «Яңарыш» фонды белән, инңе-инңә куеп, ТР Мәдәният министрлыгы да башкара. Барлык тарихи объектларны да ныклы нигезгә бастырмыйча, дымланудан изоляцияләмичә торып, бернинди дә реставрацияләү эшләре алып барырга ярамый. Юкса, бу юкны бушка аударуга акча исраф итү булыр иде. Свияжск монастырьлары чәчәккә күмелеп утыручы гөлбакчаларга әверелергә тиеш. Ә утрау үзе — җәннәт почмагына: мондагы кешеләргә яшәү һәм эшләү, шулай ук бирегә килгән дин тотучыларны һәм туристларны кабул итү өчен бөтен уңайлыклар да тудырылачак.

Болгарда һәм Свияжскида яңа торак төзүгә бәйле барлык мәсьәләләр хакында республика Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм ТР Премьер-министры Илдар Халиков белән уртага салып фикер алыштык. Болгардагы Иске шәһәрлек янындагы кайбер йортларны күчерергә туры киләчәк, чөнки андагы изге җирләр манзарасы ап-ачык булып күренергә, күзне иркәләп торырга тиеш. Бүгенге көндә бу эш башланды да инде, аны гамәлгә ашыруга ТР Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды җәлеп ителде.

Изге ядкәрләрне торгызу эшенә кушылган дистәләгән кешеләргә һәм оешмаларга мин рәхмәтлемен. Алар турындагы язмалар «Татарстан» журналы битләрендә «Чын күңелдән — изге эшләргә» рубрикасы астындагы сәхифәләрдә даими рәвештә дөнья күрер дип уйлыйм.

Шундый киң масштаблы проект белән илебезнең тарихи-архитектура һәйкәлләрен кабаттан торгызуга керешеп, без бөтен Россия җәмәгатьчелегенә игелекле эшкә керешергә этәргеч бирдек. Берничә ел үтүгә, мондый хәрәкәтнең бөтен ил буенча таралуының шаһиты булырбыз әле, мөгаен. Россиядә бөтенләйгә юкка чыкканчы кабаттан торгызыласы ядкәрләр шактый күп. Мин, әлеге изге эштә дә без башкалардан бер адымга алданрак барабыз, дип уйлыйм.

2010 нчы еллар

ЯҢАЛЫКЛАР

2012

ИКЪТИСАД КАТАЛИЗАТОРЫ

2012 елда Татарстанда «ТАНЕКО» Нефть эшкәртү һәм нефть химиясе заводлары комплексы проекттагы куәтенә эшли башлады. Нефть эшкәртү күләме буенча республика төбәкләр арасында алтынчы урынга чыкты.

«ТАНЕКО» – элекке Советлар Союзы киңлекләрендә соңгы 30 елда башыннан ахырына кадәр төзелгән беренче колачлы инвестицион һәм сәнәгать объекты ул. 7 миллион тонна нефть эшкәртерлек комплексны салу Татарстан Хөкүмәте инициативасы була. Максаты – нефть продуктлары базарында ихтыяҗ зур булган куәтләр формалаштыру. Проектка үзенең һәм заем акчаларын керткән «Татнефть» компаниясе инвестор буларак катнаша. Комплексның тышкы транспорт инфраструктурасы объектларын төзегәндә хосусый-дәүләт партнерлыгы механизмы файдаланыла.

Беренче комплекс куәтләрен үзләштерү белән бер үк вакытта берләштерелгән гидрокрекинг җайланмасын төзү дә дәвам итә. Аны коммерция максатларында файдалану 2014 елның мартында башлана, ул Россия нефть эшкәртү тармагы өчен рекордлы кыска вакыт эчендә – дүрт елда сафка бастырыла. Җайланма бер елда 2,9 миллион тонна чимал катнашмасын эшкәртүгә исәпләнгән һәм 5 класслы дизель ягулыгы, ТС-1, РТ, Джет-А1 маркалы авиация керосины, гидрочистартылган газойль җитештерә.

Ике елдан соң яңа биеклек яулана: акрынайтылган коксլаштыру җайланмасы эшли башлагач, «ТАНЕКО» карасу төстәге нефть продуктлары чыгарудан туктый. Нефтьне эшкәртү тирәнлеге 99,2%, ачык төстәге нефть продуктлары чыгышы 87% тәшкил итә.

2019 елның 12 февралендә РФ Президенты Владимир Путин һәм ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов видеоэлемтә форматында АИ-92, АИ-95, АИ-98, АИ-100 автобензиннарын сәнәгать масштабында чыгара башлау мәрасимендә (церемониясендә) катнашты. Автобензиннар җитештерүнең проект куәте елына 1,1 миллион тоннадан артыгракка тәңгәл.

Бүген «ТАНЕКО» продуктлары кәрзинендә – югары сыйфатлы һәм бик кирәкле 20 ләп төрле продукция: АИ – 92, АИ – 95, АИ – 98, АИ-100 автомобиль бензиннары, «Евро-5» дизель ягулыгы, РТ, ТС-1, ДЖЕТ А-1 маркалы авиация керосины, II һәм III төркем база майлары һ.б.

2013

«ЗӘҢГӘР АРМАДАНЫҢ» ТУГЫЗ БӘДӘВИЕ

Елап торучы «КАМАЗ-мастер» пилоты фотосын 2013 елның гыйнварында дөньядагы бик күп матбугат чарасы бастырды. Бу шатлык яшьләре иде: Эдуард Николаев «Дакарда» җиңде!

Чаллы командасы бөтен пьедесталны яулады һәм тугыз бәдәви сынына лаек булды – моңарчы күрелмәгән очрак бу! Шунысы бигрәк гаҗәп – әлеге абруйлы узышта аннан беркем дә җиңү көтмәгән иде: бер ел элек «Зәңгәр армада» (безнең команданы шулай хөрмәтлиләр) составы тулысынча диярлек яңартылды.

– Ничек тә бер призлы урын алу бурычын гына куйган идек, – диде җиңүле фиништан соң команданың җитәкчесе Владимир Чагин. – Егетләр исә аны арттырып үтәде, өч урынны да яулады. Мин барысына да – пилотларга, штурманнарга, техникларга, шулай ук һәр фиништан соң йөк машиналарын узышның киләсе этабына әзерләүчеләребезгә рәхмәтемне белдерәм. Сез булдырасыз, мин сезнең белән горурланам!

КАМАЗ узышчыларына җиңү китергән маршрут искиткеч катлаулы иде! Перу башкаласы Лимадан Аргентина аша Чили башкаласына кадәр. Анд тауларындагы һәм мәкерле Атакама чүлендәге махсус участокларда йә упкынга очарга, йә комга батып калырга мөмкин. Температуралар аермасы да зур – тауларда салкын булса, Чилиның Кордобасындагы эсселек 42 градуска җитә.

Болар барысы да техника һәм экипаж өчен узышның үндүрт этабы буена зур сынау һәм имтихан булды. Һәм менә Сантьягода финиш. Эдуард Николаев җиңүеннән соң тәүге интервью бирә:

– Минем хисләрем ташый, чөнки һәр минут, һәр секунд саен барган көрәштән, 15 көнлек узыштан соң мин, ниһаять, җиндем, «Дакарда» оттым! Моннан биш ел элек туган хыялым тормышка ашты!

Россия өчен алтын бәдәвиләрне Эдуард Николаев, Сергей Савостин һәм Владимир Рыбаков; көмешләрен – Айрат Мәрдиев, Айдар Беляев һәм Антон Мирный; бронзаларын – Андрей Каргинов, Андрей Мокеев һәм Игорь Девяткин яулады.

2015

ҺАВА ҺӘМ БЕЛЕМНӘН IT-ФЛАГМАН

«Моннан өч ел элек Рөстәм Миңнеханов белән басып торганда, биредә ялан кыр иде. Бик матур урын, әмма буш. Хәзер исә биредә тулы бер шәһәр калкып чыккан, аның исеме дә хәтердә калырлык һәм яңгырашлы – Иннополис», – диде РФ Премьер-министры Дмитрий Медведев Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов белән Россиянең иң яңа тарихында тәүге шәһәрне ачканда.

Кала нигезенә беренче таш 2012 елда салынган иде. «...Аны һавадан, белемнән салабыз», – дип шәрехләгән иде кайчандыр шәһәр төзелешен РФ элемтә һәм гаммәви коммуникацияләр министры Николай Никифоров. Өч ел эчендә Югары Ослан районы кырларында Казаннан 40 чакрым ераклыкта илнең IT-тармагын үстерү флагманнарыннан берсе өчен бөтен кирәкле инфраструктура салынды. Университет – махсус икътисадый зона – уңайлы торак – әлеге триада Иннополис концепциясенең нигезен тәшкил итә, хәзерге һәм булачак программистлар, мәгълүмати технологияләр өлкәсе менеджерлары өчен синергетик мохит тудыра. Абитуриентларга ул дөньякүләм танылган IT-университетларның иң яхшы укытучыларыннан грантлар нигезендә белем алу өчен искиткеч мөмкинлекләр ачты. Махсус икътисадый зонаның потенциаль резидентлары өчен дә шундый ук шәп шартлар тудырылган.

Бүген Иннополиста 3,5 меңгә якын кеше яши һәм эшли, 290 компания теркәлгән, шулардан 103 се – «Иннополис» МИЗ резиденты һәм партнеры. Бөтен база инфраструктурасы эшләтеп җибәрелгән – 22 торак йорт, балалар бакчасы, мәктәп, IT-лицей, медицина һәм спорт үзәкләре, почта һәм банк бүлекчәләре, 3 супермаркет, пиццерия, кафе, бар, автоюгыч, даруханәләр, китап һәм чәчәк кибетләре, хобби-үзәк һәм башка сервис компанияләре эшли. Иннополис – көндәлек хаҗәтләр өчен пилотсыз транспорт хезмәт күрсәткән Европада беренче шәһәр.

«Әйтерсең, авылда әбидә яки экологик чиста урындагы яхшы пансионатта яшисең, күршеләрең исә – дуслар һәм фикердәшләр», – дип язачак берничә елдан соң шәһәр турында үз фикерен «Иннополис» МИЗ резиденты булган компанияләрдән берсенең директоры. Әгәр бу атмосфераны биредә уйлап табыла торган санлы продуктлар дәрәҗәсенә тапкырласаң, XX гасыр пассионарийлары хыялланган XXI гасыр бакча-шәһәре килеп чыгачак.

2020

КОРОНАВИРУСЛЫ ЯЗ. УЛ ДА ҮТӘР...

2020 елның язы берүзе генә түгел, коронавирус белән килде. Кибетләр ябык, урамнар буш, фатирлар тулы. Үзизоляция шулай үтте. Бу чорның төп киңәше – өйдән чыкмаска, кул биреп күрешмәскә, читләр белән аралашмаска. Бу чорның төп билгесе – битлек, перчатка, биналардагы дезинфекция автоматлары һәм кешеләр арасындагы 1,5 метрлык дистанция. Бу чорның төп яңалыклары – үткән тәүлектә ничә кеше йогышланган, ничәсе сихәтләнгән, ничәсе үлгән. Бу чорның төп нәтиҗәсе – Сөләйман патшаныкы кебек: «Бу да үтәр». Әгәр тәртипле булсак. Үз вакытында күрелгән чаралар һәм дисциплина нәтиҗәсендә, 12 майда Татарстанда үзизоляциянең шактый тыюлары бетерелде.

НАЛАСА: ГАРМУН МОҢЫН САКЛАГАН АВЫЛ

Өздереп гармун уйныйлар
Наласа авылында.
Йөрәгемдә утлар яна –
Янам мин ялкынында...

Наласаны бер тапкыр күрмәгәннәр дә шулай дип җыр суза. Алай гына да түгел, «Наласа авылы» көен безнең әби-бабайлар аулак өй, Сабантуйларда җырлаган. Кайда гармун, шунда «Наласа» көе булган. Ә шушы авылда яшәүчеләр көйне беләме соң? Бүген Наласа авылында өздереп гармун уйныйлармы? Шушы сорауларга җавап табар өчен, Арча районына кузгалдык.

Автор:
Руфия Фазылова

«ПРОФЕССИОНАЛЛАР»

Наласа географик яктан бик уңай урында урнашкан: Арчага – сигез, Казанга җитмеш чакрым. Табигатенең матурлыгы турында әйтми кала алмыйм: таулар, урманнар, ямь-яшел тугайлар, карап, сокланып туеп булмый...

Наласада 721 кеше яши, 223 хуҗалык бар. Төзек йортлар (арада ике катлылары да шактый), асфальт юллар, капиталь төзекләндерү уздырылган урта мәктәп, мәдәният йорты бинасы, кырык урынга исәпләнгән яңа, заманча балалар бакчасы... Соңгысы тиздән кулланылышка тапшырылачак. Болар барысы да авылның нигезе нык икәнлеге турында сөйли. Тик бу шартлар һәм, авылда яшьләр күпләп кала, дигән инандырулар гына артык гаҗәпләндермәде безне. Шөкер, республикабызда заманча яшәүче авыллар шактый, аларда да яшьләр кала. (Кайбыч районының – Кошман, Балтачның Бөрбаш авылларына барып, шатланып кайткан идек). Ә менә наласалыларда булган җыр-моңга сәләт, аны тоемлау – монысы чынлап та сокландырды.

Яңа бакча бинасы тиздән кулланылышка тапшырылачак.

Авылга килгәч тә, иң беренче эш итеп, мәдәният йортына юнәлдек. Һәм аптырап калдык: ун яшьлек малайның да, алтмыш яшьлек агайның да, утыз яшьлек сылуның да, җитмеш яшьлек апаның да кулында – гармун! Сәхнәгә чыгып, «Наласа авылы» көен уйнап җибәрделәр. Телсез калдык! «Афәрин! Чып-чын артистлар сез!» – дип, кул чаптык. Арадан бер агай:

– Без инде үзлегебездән өйрәндек. Бер нота белмичә дә гармунда уйныйбыз. Менә яшьләр үсеп килә – алар профессионаллар булачак», – диде.

Чынлап та, Наласаның үсмер малайлары гармунда уйнарга үзлектән өйрәнми икән. Биредә Арча сәнгать мәктәбенең филиалы эшли. Тулы бер музыка мәктәбе кебек ул: баяннан тыш фортепиано, сольфеджио дәресләре дә керә. Баян классының укытучысы – **Булат Сафиуллин** Наласада туып-үскән егет.

Фото: Лилиана Вәлитова

– Мине гармунда уйнарга Миңнегөл Әхмәдуллина өйрәтте, – диде ул. – Аннары Арча педагогия көллиятенең музыка факультетына укырга кердем. Кулга диплом алып, армиядә хезмәт итеп кайтканнан соң, биредә эшли башладым.

Бүген Наласаның ун баласы баян классында укый икән. Дәресләрдән соң, Наласа урта мәктәбендә җырлы-биюле яңа тормыш – сәнгать мәктәбе дәресләре башлана.

– Баян, нигездә, ир-атлар уен коралы санала, – диде Булат Сафиуллин. – Бездә дә шулай ул – миндә укучы 10 баланың берсе генә кыз, калганнары малайлар. Кызлар күбрәк вокал белән кызыксына. Гитарада уйнарга йөрүчеләр дә бар. Курайны да бик яраталар.

«МИРАС»ЛЫЛАР

Мәктәп укучылары сәнгать мәктәбенә йөрсә, урта буын, өлкәннәр Наласа мәдәният йортында эшләп килүче «Мирас» ансамблендә шөгыльләнә. Аның җитәкчесе – Наласа авылы килене Чулпан Сабирова.

– Ансамбль мин эшли башлаганчы да булган, әмма берничә ел туктап торган, – диде Чулпан. – Шулай да халыкны җыю бик авыр булмады. Башта гармунчылар белән район күләмендә уздырылган төрле конкурсларга бардык. Репетицияләр ясаганда туганлашып ук беттек.

Шунысын да әйтим: ансамбльгә йөрүчеләр җырлый да, бии дә. (Безгә дә җырлап күрсәттеләр). Гомумән, биредәге халык шаккаткыч: фотога төшәргә, җырларга, гармунда уйнарга, дисеңме, һич кенә дә тартынып тормыйлар.

Биредә балалар җыр-моңга кечкенәдән тартыла, Мөнир Сабиров та – әнә шундыйлардан. Мәктәпкә кергәнче үк, тальянда уйнарга өйрәнә башлаган ул.

– Авылда гармун уйнаучылар бик күп иде, – диде Мөнир абый. – Аларга кызыгып, мин дә кулга гармун алдым. Тик барыбер гармунда гына уйнап үсмәдек, футболы да, башкасы да калмады бездән. Хәзерге балалар бәхетле, нотаны белеп, дөрес уйныйлар. Гомер буе нота өйрәнергә кызыктым, тәки булмады инде. Хәер, әле безнең балаларга да эләкмәде ул.

– Улыгыз да гармунда уйный икән. Аны сез өйрәттегезме? – дим.

– Юк, аерым өйрәтеп утырганымны хәтерләмим. Өйдә гармун булгач, вакыт булганда, кулына алгандыр. Эштән кайткан чагыма: «Әти, кара, мин бу көйне өйрәндем», – дип әйтә иде. Мактап куясың да, шуның белән шул. Үсеп килә торган буынга өмет зур – танылган баянчылар булсыннар, дим. Ә безгә авыл, район сәхнәсе дә бик җиткән инде...

Ансамбльгә йөрүчеләрдән «Наласа авылы» көенең тарихы турында сораштым. Бактың исә, аның авторы һәм ничәнче елда язылганы билгеле түгел икән. Телдән-телгә күчеп, халык җырына әйләнгән көй ул. Биредә бер генә нәрсәне анык әйтеп була: Наласада гел гармун уйнаганнар. Әлеге уен коралы бик сирәк йортларда гына булмаган. Хәзер дә шулай ул. Уйнамасалар да, кадерле истәлек яки матурлык өчен булса да тора.

«МИЛЛИОНЕР КОЛХОЗ ИДЕК»

Авылның хөрмәтле кешесе – Таһир Җәләлетдинов белән дә очраштык. Хезмәт Кызыл Байрагы, Почет билгесе орденнары алган атаклы «Октябрь» колхозының баш инженеры булган ул. Бүген Таһир агага 89 яшь. Улы, килене, оныклары белән туган нигезендә матур картлык кичерә.

– Мин бәхетле – гомерем туган авылымда узды, – диде Таһир ага. – 1946 елда 7 нче классны тәмамладым. Аннан колхозда эшләдем. Башкаларга караганда гәүдәлерәк идем. Кытайдан шикәр капчыклары килә иде, 80 килолы капчыкларны иңбашыма куеп ташыдым. И, мин эшләмәгән эш калмады: җир дә сукаладым, чәчү дә чәчтем. Унсигезем тулгач, армиягә алдылар, өч ел ярым Мәскәү янында хезмәт иттем. Шуннан кайткач, Васильево бистәсендәге урман хуҗалыгы техникумын тәмамладым. Казанга эшкә чакырганнар иде, бармадым. Әти безнең сугыштан кайтмады, шуңа да әни өчен зур җаваплылык тойдым.

Наласа Мәдәният йортында эшләп килүче «Мирас» ансамбле.

Таһир Җәләлетдинов яраткан шөгылен хәзер улы Тәлгатькә, оныкларына тапшырган.

Хәтерлим: «Мин колхозга эшкә кайтам», – дигәч, әни шатлыгыннан елап җибәрде. Гаиләдә дүрт бала үстек, әни сүзе закон булды. Гомер буе эчмәдем, тартмадым, чөнки әни шулай кушты...

Авылның аксакалы белән гармунчылар турында да сөйләштек. Таһир ага үзе гармунда уйнамаган, гәрчә өендә бу уен коралы булса да.

– Без үскәндә авылның түбән башында Шәһми атлы бик атаклы гармунчы бар иде. Аның энесе дә шәп уйнады. Тагын Миңнегали дигән егет тә яхшы гармунчылар рәтендә йөрде. Мин дә, улым Тәлгать тугач, гармун алып кайтып куйдым. Мәрхүм әти дә бик оста гармунчы булган, тальянда уйнаган, әти кебек булдырасы килде. Тик барыбер гармунда уйнарга өйрәнмәдем. Хәзер шуңа бик үкенәм. Тәлгать алты көй өйрәнде дә туктады. Югыйсә, без җыр-моңга гашыйк кешеләр. Урман хуҗалыгы техникумында укыганда оста итеп биергә өйрәндем. Җырларга, сәхнәдә чыгыш ясарга бик яраттым. Колхозда эшләгәндә, трактор белән күрше авылларга барып, театр да куеп йөрдек.

«Октябрь» миллионер колхоз исәпләнгән. Шуңа да Наласада тормыш, башка авыллар белән чагыштырганда, күпкә алдынгырак булган. Колхоз җитәкчелеге үз эшчеләренә йортлар салып биргән, районда беренче булып газ керткән һ.б. шундый уңайлыклар тудырган. Бу эшләрдә Таһир аганың да өлеше зур.

– Колхоз рәисе белән бик тату эшләдек, – дип сүзен дәвам итте тыл ветераны. – Хуҗалык зур, эшчеләр күп ул чакта. Мөгезле эре терлекнең баш саны меңнәр белән исәпләнә иде. Аларга ашатырга азыкны әзерләргә дә, халыкны кайгыртырга да кирәк. Димәк, техника, ягулык белән проблема булырга тиеш түгел. Гел юл йөрүдә булдым.

Таһир ага сөйләгәннәрдән аеруча бер сүз истә калды: әҗәткә алып-биреп тору гадәте булган. Бернинди документсыз, сүзгә ышанып кына, фәлән мең акчалар белән эш иткәннәр.

– Ә алдасалар яки әҗәтне түләмәсәләр? – дим.

– Юк, бер алдау да булмады. Без бит бер-беребезне беләбез. Ул чакта кешеләр эчкерсез, гади иде.

Ул да түгел, Таһир аганың оныгы Назыйм да кайтып җитте. Наласа урта мәктәбенең унберенче сыйныфын тәмамлаган. Көрәшче егет. (Гармунчылардан кала, биредә көрәшчеләр дә күп). Назыйм әти-әнисенең уң кулы икән. Дөрес, хәзергә егет имтиханнарга әзерләнә.

– Рус теле, информатика, математикадан БДИ тапшырачакмын, – диде ул. – Сыйныфтагы барлык егетләр дә югары белем алырга планлаштыра.

Сөйләшүгә Таһир ага кушылды:

– Унөч оя кортыбыз бар, хәзер аларны балалар карый. Әйдә, күрсәтәм, – дип, умарта ояларын күрсәтергә булды.

Баксаң, Җәләлетдиновлар күп еллар умарта тота икән. Таһир ага яраткан шөгылен хәзер улы Тәлгатькә, оныкларына тапшырган.

– 2015 елда миңа инсульт булды, – диде тыл ветераны. – Аңа кадәр егетләр кебек идем. Алай да кортлар янына көн дә чыгам. Әле менә сез килгәнче, яңа рамнар ясап ята идем...

«БЕРСЕННӘН БЕРСЕ КҮРЕП ТӘ, ЯШЬЛӘР АВЫЛДА КАЛА»

Авыл белән танышуыбызны дәвам итеп, Наласа урта мәктәбенә юнәлдек. Дөресрәге, биредә урнашкан авыл тарихын яктырткан музей кызыксындырды безне. Аны Наласа урта мәктәбенең тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы **Айгөл Хәсәнова** җитәкли. Менә ул нәрсәләр сөйләде:

– 2008 елда җәмәгатьчелек советы төзелде. Һәм шул вакытта өч төрле максат куелды: авыл

– Беренче булып музейны эшләп чыктык, – диде укытучы Айгөл Хәсәнова.

музеен булдыру, китап бастырып чыгару һәм Наласа турында фильм төшерү. Шуны гына әйтәм: боларның барысы да бүген үтәлде. Ә беренче булып музейны эшләп чыктык.

2012 елда Наласаның 500 еллык юбилеен үткәргәннәр, Мәскәү кунаклары да булган. 500 ел дигәндә, бу – шартлы сан. Бәлки, авыл тагын да борынгырак елларда оешкандыр, моңа төгәл генә җавап юк. Ә менә аннан да соңрак булырга тиеш түгел икән. Ни өчен дигәндә, моңа дәлилләр бар:

– Аерым чыганаклардан күренгәнчә, Арчаның үзенә 800 ел тирәсе, – дип сүзен дәвам итте Айгөл Хәсәнова. – Наласа аннан әллә ни ерак түгел, бәлки, безнең бабайлар биредә шул чакларда ук яшәгәндер. Тәгаен 500 ел дип курыкмыйча әйтәбез, чөнки XVI гасырның икенче яртысына караган кабер ташы бүген дә сакланган. Зират янында андый ташлар икәү, берсенең язуын укып булмый. Менә шул бер таштагы язуга нигезләнеп, авылда 500 ел элек үк кеше яшәгәнлеген билгеләдек тә.

...Кимендә биш гасырлык тарихы булган Наласаның киләчәге матур булачак, моңа һич кенә дә шикләнмим. Авылда үз эшен башлаган эшмәкәрләр, фермерлар ике дистәдән артык. «Эше барның ашы бар», – ди безнең халык. Димәк, халык акча эшләү максатыннан, читкә чыгып китмәячәк.

Наласаның тагын бер тәҗрибәсе кызык тоелды – биредә үзсалым акчасын аерым елларда 3 мең сум итеп җыйганнар. Шуның хисабына авыл буенча барлык юлларга таш түшәп (ә ул ун чакрымга җитә), чишмә, коеларны яңартып чыкканнар.

Авыл җирлеге башлыкларын сирәк мактыйбыз (авыл өчен эшләү аларның вазыйфасы бит). Тик Наласа авыл җирлеге башлыгы Илфира Шакирова турында әйтми кала алмыйбыз – халык белән уртак тел тапкан ул. Җирлекнең унҗиде яшь гаиләсенә, торак салу өчен дәүләт бирә торган субсидия алырга ярдәм иткән. Урамда кем очраса да, һәр кешенең хәлен, нинди проблемасы барын әйтеп бирә.

– Даими рәвештә яшьләр белән очрашып, җыелышлар ясыйбыз, – диде Илфира Шакирова. – Авылга нәрсә кирәк, алга таба нишләргә? Яшьләргә торак салу, дәүләт бирә торган башка субсидияләрне ничек алырга – барысы хакында да фикерләшәбез. Берсеннән берсе күреп тә, яшьләр авылда кала. Өчәр, дүртәр балалы гаиләләр шактый. Һич арттырып әйтү түгел, бүген шәһәргә караганда авылда тормыш башлау күпкә җиңелрәк, чөнки дәүләт ярдәме бар. Дөрес, моны бөтен җирдә күреп, аңлап бетермиләр әле.

Гөлнара һәм Рәзих Хәлиуллиннар, яшь гаиләләргә торак салу өчен дәүләт бирә торган субсидия алып, өр-яңа йорт салып чыкканнар.

ТАРИХ БИТЛӘРЕННӘН

– Тарихчылар Рәшит Галләм һәм Марсель Әхмәтҗанов Наласа авылы тарихын архивларга барып өйрәнде. Архив документларына таянып, шулай ук телдән-телгә күчеп килгән риваятьләр буенча әйтергә була: авылның тарихы Нократ буендагы Нолинск шәһәренә барып тоташа. Картадан карасак, анда Ноли елгасы барлыгын күрербез. Безнең әби-бабайлар шунда яшәгән. Казан ханлыгы җимерелгәннән соң, елга буендагы җирле халык, чукындырудан качып, биредәге җирләргә килеп урнаша. Һәм алар яңа җиргә дә Нолига аваздаш исем бирәләр. Бу якларда урманнар үскән. Хәер, нигездә, яңа авыллар урманы, суы булган җирләрдә оешкан. Наласа да искәрмә түгел.

Айгөл Хәсәнова, Наласа урта мәктәбенең тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы.

2010–2020: ЦИФРЛЫ БУЫН САННАРДА

1 900 000
татарстанлы капиталь ремонт ясалган йортта яши

Ел саен социаль ипотека программасы буенча
5000
фатир файдалануга тапшырыла

Татарстанда 10 елда 37500 урынлык
239
балалар бакчасы төзелгән

Ел саен Татарстанның
200+
студенты, педагогы һәм гыйльми хезмәткәре грант ярдәме ала

Татарстанда 10 елда 28500 урынлык
62
яңа мәктәп төзелгән

Татарстанда
188 000
бала өстәмә белем ала

Татарстанда 10 елда
2 300
спорт корылмасы төзелгән

Татарстанда ел саен
30
зур халыкара ярыш үткәрелә

Kazan volunteers хәрәкәте волонтерлары 10 елда
600
зур халыкара чарада катнашкан

Татарстанда
10 елда
гомер озынлыгы

4

елга арткан – 71
дән 75 яшькә җиткән

Татарстанда
8 елда

543

ФАП һәм табиб
амбулаториясе төзелгән

Татарстанда
9 елда

75

балалар поликлиникасы
ремонтлланган

Татарстанда
8 елда

692

яңа эш башлаучы
фермер грант ярдәме
алган

2600 км
төбәк юллары,

50 күпер
салынган

3000 км
төбәк юллары,

94 күпер
ремонтланган

Татарстанда
10 елда авыллар
арасында барлыгы

1 100

километр
юл салынган

Татарстанда

1768

ишегалды һәм
подъезд ремонтланган

Татарстанда
2015–2019 елларда

382

җәмәгать мәйданы
реконструкцияләнгән

Татарстанда
9 елда

909

социаль әһәмияткә
ия объект
«Уңайлы мохит»
программасы буенча
адаптацияләнгән

ТАССР

Празднование 100-летия Татарской АССР

Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итү

1920–2020